

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН
2021 МАЙ № 5
СӨЕМБИКӘ
ISSN 0869-1398
ПЛАСТИК ОПЕРАЦИЯЛӘР
чибәрлектән
чибәрлеккәме, әллә...
ФӘНИЛ ВАККАЗОВ
чәчәк
бүләк итмәс идем
осетин бәлеше
сере...
КАМЫРЫНДА
Ризәлә ИСМӘГЫЙЛЕВА:
«Тыңлаучы сине ихласлыгың өчен ярата».

Мин әни булдым, әни!

Мин әни булдым, әни!

Мин әни булдым, әни!

Шушы сүзне әйткән мизгелдә барысы да үзгәрә! Аралар тагын да якыная, җылына, күңелләр бер-берсен сүзсез дә аңлый... Бер үк кичерешләр аша узганнарның якынлыгы башка аның. Сүзләр, хәрәкәтләр, теләкләр бөтенләй үзгә төсмер ала. «Менә әни ни өчен ул вакытта шулай дигән, шулай эшләгән (яки эшләмәгән) икән», – дип уйлыйсың... Барысы да мәңгелекнең үзе кебек гап-гади, чөнки син – Әни! Ә Әниләр инде бер телдә сөйләшә...
Өр-яңа проект башлыйбыз. «Мин әни булдым, әни!» дип атала ул. Бер фоторәсемдә өч буын – әниегез, сез һәм кызыгыз (улыгыз): буыннар чылбыры шулай тезелә!
Җылылык, яктылык, нур бөркеп торган мондый фотосурәтләр сездә дә бардыр – кушылыгыз!


Фото: Анна Арахамия

Асия ЮНЫСОВА

КЫЗЫҢ ТУДЫ

Бу дөньяга кеше килде.
Ул – синең кызың.
Кабынды бүген күгеңдә
Яңа йолдызың.

Иртә язда пешеп төшкән
Татлы җимешең.
Бии-бии атлап китәр –
Синең йөрешең.

Синең шикелле көләр ул,
Көмешләр чәчеп.
Тарый алмый азапланыр
Бөдеркә чәчен.

Әни хәлен аңлар өчен,
Әни бул элек!
Әнә шулай дәвам итә
Җирдә кешелек.

■ Безнең гаиләдә бик матур бер гадәт бар. 1 Май бәйрәмендә төп нигезгә, әбиебез янына кайтабыз. Аның туган көненә барлык балалары, оныклары һәм оныкчыклары белән бергә җыелышабыз. Бер күрешү – үзе бер гомер, диләр. Быел бу традициягә әбинең тугызынчы оныкчыгы Амилә дә кушылачак, иншалла. Кызыбызда туганлык хисләрен кечкенәдән үк тәрбиялисебез килә.

Илүзә ЗАКИРОВА. Казан.
Фото: Гүзәл Сәлимова.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2021

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сюючбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Фото: Ксения Богданова

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Ризәлә Исмәгыйлева
Фото: Анна Арахамия

Мөхәррирләр
Чулпан Галиәхмәтова
Сөмбел Гаффарова
Фәгыйлә Шакирова
Верстка
Резеда Галиуллина
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәр
Ильмира Сөләйманова
Олег Сердюк

Формат: 225x290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 29.04.2021 ел.
Чыгу көне: 6.05.2021 ел.
Заказ Е-1346
Тираж 9965

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы
ПАП рәсми каталогы буенча:
Татарстанда П2204 (ярты еллык),
П8299 (берьеллык)
Татарстаннан читтә: П0279

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+



Фото: Анна Арахамия

9 МАЙ — БӨЕК ҖИҢҮ КӨНЕ

Гөлүсә БАТТАЛОВА

Ветераннар

Рәнҗемәгез безгә, ветераннар,
Гамьсез, мәнсез, кыйбласызлар, диеп.
Замананың саксыз җилләренә
Иңрисездер, чал башыгыз иеп.

Борчыласыз сез дә, ветераннар —
Яуда калган дуслар ни әйтер?!
Сугыш кичкән күңел үрсәләнә,
Көч табалмый нидер үзгәртер.

Толлар күз яшеме юкка булган?
Сугыш өзгән күпме гомерләр?
Ятим килеш олыгайган җанны
Кем юатыр? Кемнәр кадерләр?

Уйланасыз, ахры, ветераннар,
Тынычлыктан дөнья туйдымы?
Ата — улны, ана кызны белмәс,
Таш бәгырьле буын тудымы?

Кичерегез безне, ветераннар,
Өзмәгез тик өмет дөньядан.
Җир йөзендә Хәтер яшәгәндә,
Ваз кичмәбез әле кыйбладан!

Ышаныгыз безгә, ветераннар,
Хакыйкатьтән көчсез ялганнар!
Тарих шаһит: сез бит — кешелекне
Һәлакәттән йолып калганнар!

Соңга калмыйк, Сезгә — ветераннар,
Күрсәтергә кадер-хөрмәтне.
Еллар узган саен арта бара
Сез яулаган Җиңү кыйммәте!

Безнең тышлыкта



«Тәртип»нең уңыш сере шундадыр: беренчедән, халык сусаган җырлар, һәр тапшыруның алып баручысы итеп берәр күренекле шәхесне чакыру; икенчедән, радионы ачкан игаәчеләребезнең безгә бер башлангычыбызда да комачау итмәве.»

10 Үткән белән көткән арасы
Гөлнур Сафиуллина

Заман һәм без

6 Коточкыч матурлык
Чулпан Галиәхмәтова

«Миңа хәерхаһ юлдашлар очрады...» 16
Гүзәл Галиева



14 «Син ялгыз түгел...»
Гөлнур Хәсәншина



20 Рольләрем белән яшим...
Чулпан Галиәхмәтова

ЭЧТӘЛЕК

Татар дөньясы



22 Латыйфа оныклары
Раилә Хәялиева




26 «Бу – минем гимназиям!»
Лилия Гәрәева

Мәдәни тормыш



32 Ул чыннан да бәхетле
Сәмига Сәүбанова



37 Йөрәктә!
Роза Камалетдинова

Яшәеш

42 Тормыш арбасына җигелеп...
Рахман Шәфигуллин



44 Үзеңә ышанырга кирәк
Лариса Хәмитова



48 Биштәр асып... Дагстанга!
Гөлүсә Закирова

Хуҗабикә

58 Җәй буе чәчәктәге клумба

62 Лимфодренажлы массаж
Чулпан Галиәхмәтова



60 Осетин бәлеше

АКТУАЛЬ ТЕМА



Без – хатын-кызларның йомшак бер ягы бар: һәрвакыт матур булырга телибез! Йә кемгәдер тәэсир тудыру өчен, йә үзебез өчен. Юк дип бәхәсләшергә уйламагыз да. Һәрберебезнең күңел түрендә яши ул теләк. Чибәр булу – хатын-кыз психологиясе генә түгел, җәмгыятьнең нәфис затларга булган таләбе дә. Хатын-кыз һәм матурлык һәрвакыт янәшә йөрергә тиеш. Бу инде язылмаган канун. Ул гасырлардан шулай кабул ителгән. Әмма бер нәрсәне онытып җибәрәбез: чибәрлеккә бәя – субъектив. Һәр кешенең үз зәвыгы. Ә менә үз-үзеңне ничек бар, шулай кабул итә белү, кызганыч, һәркем өчен түгел. Андыйларга матурлык уколлары, пластик операцияләр ярдәмгә килә. Пычак астына ятучыларның тормышлары үзгәрәдерме-юкмы, әмма үзләре – тышкы кыяфәтләре үзгәрә. Һәм шуңа бәйле тормышка карашлары да үзгәрә. Бу – пациент өчен операция уңышлы килеп чыккан очракта. Ә көзгегә карагач, анда хыялдагы йөзне күрмәсәң...

Табиб – тылсымчы, пациент – төрлечә әвәләргә камыр түгел бит.

КОТОЧКЫЧ МАТУРЛЫК



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Матурлык артыннан – операция өстәлендә

«Леди Mail.ru» проекты сораштырулары Россиядә гүзәл затларның 70 проценты табигый матурлыгыннан үзе канәгать булмавын ачыклаган. Ике меңенче елларга кадәр илдәге хатын-кызлары үзләре теләгән гүзәллекне бизәнеп тудырса, 2009 елдан рәсми рәвештә пластик хирургия тармагы ярдәмгә килә башлады. Матурлык операцияләрен баштарак, нигездә, акчалы хатын-кызлар һәм шоу-бизнес йолдызлары ясатты. Хәзер инде ул киң массага таралды. Скальпель ярдәмендә матурлык эзләүче пациентлар арту – глобаль тенденция. Эстетик операцияләр ясау саны буенча беренче бишлектә – Бразилия, Япония, АКШ, Мексика һәм Көньяк Корея. Россия дә башка илләрдән читтә калмый. Бездә дә популярлаша. «Төп сәбәп – кешеләрнең гомер озынлыгы арту да», – ди федераль белгечләр. 10–15 ел элек пластик операция ясатканны яшерергә тырышсалар, хәзер хатын-кызлар нинди процедуралар кичергәнен, кемгә мөрәҗәгать иткәнен ачыктан-ачык сөйли. Бу тема җәмгыятьтә табу түгел. Матурлыкка омтылу да тәнкыйть утына тотылмый.

Казанда пластик хирурглар мәктәбе артык зур түгел. Пластик хирург белеме булган косметолог Эльвира Шәрифҗанова моны күп чыгымнар сорый торган һөнәр дип атый. Беренчедән, үз хисабыңа әледән-әле квалификацияне күтәреп торырга кирәк. Икенчедән, бу хезмәт бик күп энергияне ала. Өченчедән, пластик операция үткәрелә торган клиникалар катгый күзәтү астында. 2018 елда Россия сәламәтлек саклау министрлыгы мондый клиникаларда ярдәм күрсәтү тәртибенә кагылышлы яңалыклар кертте. Хәзер пластик хирургия үзәгендә тәүлек дәвамында рентген, анестезиология-реанимация бүлекләре, клиник-диагностик лаборатория һәм кан салу кабинеты эшләргә тиеш. Бу яңалыктан соң бик күп кечкенә клиникалар ябылып, эре үзәкләр генә калды.

Клиникалар азайса да, пациентлар саны кимемәде. Моны пластик хирург, медицина фәннәре кандидаты Руслан Муллин эстетик хирургиянең картаю билгеләре белән көрәшүдә ярдәм итүеннән тыш, тәнне дә үзгәртергә булыша алуы белән аңлата. Шуңа күрә пациентлар яше дә елдан-ел яшәреп бара. «Хатын-кызның гәүдәсенә хилафлык килгән урын юк, әмма ул рельефлы фигура тели. Миңа аңа липоскульптура ясарга тәкъдим итәм. Йә пациентның хәзер модада булган әчкә батып торган яңаклы буласы килә. Бу вакытта аңа биттәге «Биш» дип аталган төерләрен алырга кирәк булачак. Мондый операцияләр гомер өчен куркынычсыз, чөнки белгечләргә таләпләр югары, методикалар камилләшкән, материаллар сыйфатлы. Икътисадның классик законнары буенча туган хезмәтләр бу. Тәкъдимне бит сорау тудыра. Мондый төр операцияләр артык кыйммәт түгел, шуңа да пациентлар саны кискен артты», – ди хирург.

Эш тәҗрибәсе ике дистә елдан арткан табиб Муллин сүзләренчә, эстетик операция төрләренә сорау елдан-ел үзгәрә. Җәмгыятьтә хакимлек иткән мода тәэсир итми калмый. Ләкин блефаропластика (күзне һәм күз уемы формасын үзгәртү) һәм маммопластика (күкрәк формасын үзгәртү) классика булып кала. Хәзер липоскульптура (тән контурын матурлау) һәм абдоминопластика (корсакның эстетик пропорцияләрен кайтару) ясатучылар арткан.



Пластик хирург, медицина фәннәре кандидаты Руслан МУЛЛИН: «Кеше ЛЕГО конструкторы түгел. Шуңа күрә операция нәтиҗәсе пациент көткәнгә төгәл туры киләчәк, дип, бер табиб та гарантия бирми».

«Кәбестә яфрагы куй»

Ни өчендер нәкъ менә күкрәк хатын-кызларга тынгылык бирми. Әллә ир-атны үзенә каратып торган бердәнбер корал – күкрәк дип уйлап яшәүчеләр шулкадәр күп, әллә күпләр үз-үзләренә артык тәнкыйть белән карыйлар, һич аңлашылмый. Күпләр күкрәк үлчәмен зурайту йә кыз чагындагы күкрәген кайтару өчен пычак астына ята. Үлчәмне зурайту, димәк, тәнгә чит әйбер кертү дигән сүз. Ә аны организм ничек кабул итәсен бер табиб та анык кына белеп бетерә алмый. «Операция ул – һәрвакыт үз-үзеңне куркыныч астына кую, – ди, күкрәген зурайтып кире кечерәйткән Оля. Җаны теләгән елан ите ашаган, диләр андыйлар турында. – Минем күкрәгем өченче үлчәмле иде. Күз алдыгызга китерәсездер тулышып торган ике матур алманы. Ике бала имезгәннән соң алмаларым «шинде», асылынып төште, җитмәсә, ябыктым. Ими башлары да бер югарылыкта тормый иде. Күкрәкчәсез йөрергә яраткан кеше буларак, бу миндә дискомфорт тудырды. Үземне хатын-кыз итеп тоймый башладым хәтта. Ирем моңа әллә ни артык игътибар итмәде кебек, ә мин шәрә килеш көзгегә карый алмый башладым. Пластик операция – начар дип уйламыйм мин. Үзгәрәсең килә икән, үзгәр, гомер бер генә дигән принцип белән яшәүчеләрдән мин үзем. Шуңа озак интегеп йөрмәдем, хирург эзли башладым. Казандагы белгечләргә генә ышанмыйча, операцияне Мәскәүдә ясатырга булдым. Әлбәттә, күпкә кыйммәтрәк иде. Әмма бәясе мине кызыксындырмады. Бу адымым өчен битәрләсә дә, ирем акча бирергә ризалашты. Сайтлардан Мәскәү клиникаларын озак өйрәндем, форумнарда утырдым. Миңа хатын-кыз табиб кирәк иде. Таләпләремә туры килгән клиника таптым. Хирург үзе дә бик чибәр хатын иде. Бу – ышанычымны тагын да арттырды. Эстетик зәвыгы булган пластик хирург начар операция ясамас... Мәскәүдәге танышларым да белеште: клиника яхшылар исәбендә, диделәр. Онлайн-консультация уздырдык. Бөтен сорауларыма җавап алдым. Табибның белемле булуы сөйләшүеннән үк сизелә иде. Өч айдан операция билгеләде. Тыныч кына шул көнне көтеп яши башладым.

Әмма ике атнадан соң ук клиникадан шалтыратып, тиз арада килеп җитәргә куштылар. Мондый ашыгуны «табиб озакка укырга китә», дип аңлаттылар. Анализларымны бирдем дә, Мәскәүгә очтым. Икенче көнне бик яхшы кәеф белән клиникага килдем. Анализ нәтиҗәләрем гемоглобин түбән булуын күрсәтте.

Фото: www.pixabay.com



Картаюдан һәм тышкы кыяфәтнең камил булмавыннан курку эпидемиягә әйләнеп бара. 20 яшьтә үк эстетик клиникалар ишеген ачып керүчеләр саны арта.

Мондый анализ белән, гадәттә, операциягә алмыйлар... Табиб, мине җитәкләп, анестезиолог янына алып керде. Бик үтенеп сорагач, операциягә алырга ризалашты. Дөрес эшләмәгәнемне беләм, әмма бер килгәч операция ясатып китәсе килү теләге көчле иде шул... Ап-ак, чип-чиста стериль бүлмәдә операция бер сәгать ярым барды. Наркоздан бик озак аңыма килә алмый интектем. Бер генә көн ятасы клиникада ике көн яттым. Самолетка утырырга кушмадылар. Ирем Мәскәүдән машина белән килеп алды. Күкрәк ярты ел «өлгерә», диделәр клиникада. Шушы вакытта аеруча сакланырга кирәк иде. Авыртуны әйтеп аңлатып булмый... Тәндә имплант барлыгы белән акыл һич килешә алмый интекте. Операция җөйләренә дә даими дару сөртеп торырга кирәк иде. Шеше беткән саен, күкрәгем дә кечерәйде. Нәтиҗә мин көткәнчә үк булмады. Җитмәсә, бер күкрәгем кабат шеште. Табиб: «Кәбестә яфрагы куй, үтәр», – дип язып җибәрде. Килешү буенча, аннан өстәмә дәвалау таләп итә алмый идем. Ярты елдан соң тернәкләнеп беттем. Матур челтәрле күкрәкчә кигәндә сөенүләремне белсәгез. Мин хатын-кыз идем! Әмма бу шатлыгым нәкъ ел ярымга җитте. Йоклый алмый башладым, хәлсезләндем, һәрвакыт башым авырта, кулларымны көзән җыера... Интернеттан организмның имплантка җавабы шундый булырга мөмкинлеге хакында укыдым. Хирургым белән тагын элемтәгә кердем: «Аркаңны ныгыт, башыңны тикшерт, имплантларның гаебе юк. Ул матурлыкны мин алмаячакмын», – дип язып җибәрде. Кабат хирург эзли башладым. Бу юлы – Казаннан. Имплантларны алдырдым. Табиб операциянең бигүк дөрес башкарылмаган булуын әйтте. Дөреслек эзләп йөрергә телəгем юк иде инде. Бу хакта бары тик онытырга теләдем. Хәзер күкрәкләрем үземнеке. Бары тик бераз тарттырылган. Бу миңа бик зур сабак булды. Операция өстәленә ятканда хирургны туганың кебек белү кирәк һәм ул ышанычлы булырга тиеш икән».



Алсу ХАННАНОВА, психолог

Кешенең үзенә үзе биргән бәясе балачакта формалаша һәм гомере буе үзгәреп тора. Пластик операцияләр тышкы кыяфәт белән бәйле булган психологик проблемаларны хәл итәргә мөмкин. Мәсәлән, кешенең колаклары тырпаеп тора, ди. Аны балачакта гел «әрекмән колак», дип мыскыл иткәннәр. Бу аның гомере буена исендә калачак. Шуның аркасында комплекс килеп чыга. Эстетик операция ясаткач, әлбәттә, үзен яхшырак итеп хис итә башлаячак ул. Бу үзенә күрә бер этәргечле механизм кебек – анда үзенә ышаныч артачак!

Төрле фикерләр бар: кемнәрдер пластик операцияләр ясатуны үзеңне кабул итә алмау, ди. Шәхсән мин кеше тышкы кыяфәтен камилләштерергә тели икән, пластик операцияләр аңа ярдәм итәчәк дип уйлыйм. Ул – витамин кебектер. Витамин эчмичә дә яшәп була бит, әмма сыйфатлы витамин кабул итә башласаң, хәлең тагын да яхшыра. Организмга ярдәм иткән кебек, психикага да булышырга мөмкин. Әмма операция ясатып та проблемалар калырга да мөмкин. Монысы психологик яраларның никадәр тирән булуыннан тора.

Ток-шоу героинясы булмас өчен нишләргә?

Билгеле, мондый төр операцияләр чәч кистереп буяту кебек гади процедура түгел. Әзерлек җитди булырга тиеш. Дөньядагы матур хатын-кызларның берсе булган Анджелина Джоли кебек булам да Бред Питт кебек ир белән тормыш корам дип, бу адымга бару – юләрлек. Әмма хәзерге гаджетлар заманында юләрлек кылырга этәрүче факторлар да юк түгел. Шуларның берсе – инстаграм. Эстетик фотолар, гламур дөнья хакимлек иткән әлеге социаль челтәрләрдә утыручылар, селебрити-блогерларга кызыгучылар көнләп түгел, сәгатьләп арта. Инстаграм пластик хирургия дөньясына тәэсир итми калмый. Үзеңнең табигый матурлыгыңны кабул итә алмый йә тагын да камилләштерергә теләү максатыннан пычак астына ятарга телисең икән, иң элек клиника һәм пластик хирургны дөрес сайларга кирәк. «Окей, Google» йә социаль челтәрләр бу җәһәттән әллә ни зур ярдәмче була алмас. Анда бары тик нинди табибләр барлыгын гына ачыкларга була. Мактаулар, фотолар дөреслеккә туры килмәскә мөмкин икәнлеген истән чыгармагыз. «Белгеч эзләүдә иң ышанычлы чара – «сарафанлы радио». Хирург белән очрашкач, лицензия сорагыз, табиб

турында бөтен мәгълүматны җыярга тырышыгыз, шул вакытта ток-шоу героинясына кандидат булу ихтималы юкка чыгар», – ди Руслан Муллин.

Телевизордан барган төрле ток-шоулар бик еш кына пластик операция корбаннарына багышлана. Барысына да, билгеле, табиб гаепле. Әмма суд юлын таптый башлагач, әлеге корбаннар ярык тагарак алдында калуын аңлый, чөнки операция ясар алдыннан укымый гына, йә кечкенә пунктларга игътибар итми килешүгә кул куйганнар. Димәк, уен кагыйдәсен кабул итеп алганнар. Шуңа күрә юристлар килешүне җентекләп укырга киңәш итә. «Корбаннар» ике төргә бүленә: берләре – яңа тәннәреннән көткән тәэсир алмаганнар, икенчеләре – сәламәтлегенә зыян килүчеләр. Нәкъ менә соңгылары өчен «операция уңышсыз» булып санала. Аны да, табиб әйтүенчә, суд-медицина экспертизасы аша расларга кирәк булачак. Әлеге тикшерү генә сәламәтлеккә килгән зыян дәрәҗәсен ачыклый ала. Калган барлык очраклар да «Медицина хезмәте күрсәткәндә кулланучылар хокукы саклау турындагы» Россия Федерациясе законы буенча хәл ителә. Әмма моның өчен бик күп вакыт һәм нервы кирәк.

Табиб профессионал гына түгел, кешелекле, намуслы булырга тиеш. Бу бик мөһим. «Кеше ЛЕГО конструкторы түгел. Шуңа күрә операция нәтиҗәсе пациент көткәнгә абсолют туры киләчәк, дип, бер табиб та гарантия бирми. Ул үз күзаллавын пациентка җиткерәчәк. Намуслы табиб бервакытта да түгәрәк йөзгә нечкә борын ясарга алынмас», – ди Руслан Муллин.



Гүзәлия ШӘЙХРАЗЫЕВА, медицина юристы

Эстетик максат белән ясалган пластик операцияләр түләүле медицина хезмәте категориясенә керә. Түләүле медицина хезмәтләре күрсәтү Кагыйдәләре нигезендә медицина оешмалары килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта кулланучы алдында җаваплы.

Килешү төзегәндә пациентка медицина ярдәмен күрсәтү алымнары, аларга бәйле хәвеф-хәтәрләр, медицина катнашуы төрләре, аларның нәтиҗәләре буенча мәгълүмат бирелергә тиеш.

Бу пунктларның һәрберсе бик мөһим. Килешүдә процедурадан көтелгән нәтиҗәләрне төгәл һәм тәгаен итеп күрсәтергә кирәк. Мәсәлән, кирәкле параметрлар һәм пропорцияләр, үлчәмнәр, ягъни операциянең нәрсәгә китерәчәген җентекләп язарга. Еш кына килешүдә болар күрсәтелми, бары тик хезмәт күрсәтү атамасы гына языла. Кулланучының (пациентның) бурычы – моңа игътибар итү. Пациент килешүгә өстәмәләр кертергә хокуклы. Шулай ук һәр анатомик зонасын стандарт проекцияләрдә фотога төшерергә сорарга була. Гади итеп әйтсәк, операция «ясалганчы» һәм «ясагач» фотога төшерү. Бу очракта пациентның кулында операциянең көтелгән нәтиҗәләр бирмәгәнен раслаган төгәл критерийлары булачак. Соңыннан килешү төзелгән клиникага язмача дәгъва белдерергә кирәк.

Чибәрлектән ямьсезлеккә – бер адым

Чама дигән төшенчә дә бар бит әле. Эстетик медицинада чикләрне белмәсәң, матурлык бик тиз арада коточкыч ямьсезлеккә әйләнергә мөмкин. Пластик операция корбаннары фотоларын күргәнегез бардыр. Алар бит бер операциядән соң гына шул хәлгә төшмәгән. Анысы – вакытында туктый белмәү бәласе. Ә бит барысы да матур буласы килүдән башлана. Йөзе коточмалыга әйләнгән «мәче-хатын-кыз» Джоселин Вильденштейн да чибәрлеген тагын да камилләштерергә тели. Әмма... Бу ямьсезлекне ул үзе уйлап таба һәм үз куллары белән тудыра. 70 нче еллардан башлап пластик операцияләр өчен дүрт миллион доллар акча түгә. Ире – Африка миллиардеры – кыргый мәчеләр яраткан. Ул бик еш кына: «Иң матур күз аларда», – дия торган була. «Һәм миндә дә булырга тиеш», – дип, хатын иренә сюрприз ясарга уйлый. Мәче күзләр ясата. Ире генә моны бәяләми, яшь хатынга китеп бара... Ә Джоселин чикләрне югалта – әледән-әле операция өстәлենә ята. Бүгенге көндә бу ханымны берничек тә бәхетле хатын дип әйтеп булмый.

Матур буласы килү табигый инде ул. Хатын-кызларның социаль абруена, ирләрдән аермалы буларак, тышкы кыяфәт тә тәэсир итми калмый. Аристотель дә бит: «Матурлык теләсә нинди рекомендация хатына караганда яхшырак», дигән. Картаясы да килми. Тик картаю да – тормышының бер өлеше. Әйе, заманча медицина чибәр булырга, матур булып картаерга мөмкинлек бирә. Әмма бу адымга җитди итеп уйлап, очсызга кызыкмыйча, барысын да җентекләп тикшереп барырга кирәктер. Шулай ук пластик хирург Руслан Муллин сүзләрен дә онытмау зарур: «Кешене кабатланмас булуы һәм харизма матурлый. Без – көзгедәге чагылышыбыз гына түгел, күңелебез дә әле».



Фото: Анна Арахамия

ҮТКӘН БЕЛӘН КӨТКӘН АРАСЫ



Гөлнур
САФИУЛЛИНА

«Гомернең шундый рәхәт чоры – кыйбла инде тәгаенләнгән», – ди ул. Хәер, аның кыйбласы инде күптән аныкланган булган: «Тәртип»не саклап калу, яшәтү өчен бу кадәр көч түгәр идеме югыйсә?! Ана арыслан баласын яклагандай...
7 май – Радио көне, 19 май – Татарстан матбугаты көне. Бу сөйләшү шул уңайдан да. Республикадагы иң билгеле журналистларның берсе – «Тәртип» радиосының баш мөхәррире Ризәлә ИСМӘГЫЙЛЕВА белән журналистикада ул салган сукмак, узган юл, яулаган үрләр хакында сөйләшәбез. Дөресрәге, татар халкын «Тәртип»ле итү хакында.

Журналист булу теләге кайдан туды синдә? Моңа берәр этәргеч булдымы?

– Журналистикага килү юлым шактый урау минем... Яшел Үзән районының Күлбаш авылында, биш балалы гаиләдә туып-үстем. Әти-әнием гап-гади кешеләр дисәм, дөрес үк булмас. Икесе дә җиде генә класс белемле, әмма искиткеч гыйлемле, бары тик алга таба белем алу мөмкинлекләре генә булмаган. Әти мәрхүм алтын куллы иде. 62 яшендә үк китте ул безнең... Мин аның беркайчан ашыкканын, ачуланганын, ярсыганын хәтерләмим. Әни бик тырыш, җиңел куллы кеше. «Үссә – үсте, үсмәсә – юк» дип, җиргә төрткән орлыктан да җыеп бетергесез уңыш ала ул. Тегү-бәйләүгә дә оста, яшь вакытта чиккән, челтәрләп бәйләгән әйберләрен күрсәң шаккатарлык. Сүзгә осталыгын әйтеп тормасам да була.

Аллага шөкер, бик бай кеше мин. Һөнәрләре иҗат белән бәйле булмаса да, миннән күпкә яхшырак шигырьләр яза алучы (әмма, кызганыч, язмаучы) апам, бернинди музыкаль белемнәре булмаган килеш өздереп гармунда уйнаучы абыем белән энем, биегәнен күргән бер кеше: «Кайда укыдың?» – дип сорый торган оста биюче сеңлем бар минем! Безнең өйдә бер-береңә гади сүз белән генә җавап бирү юк иде. Гомумән, авылыбыз җор телле – чит кеше тыңлап торса, аңламаска да мөмкин. Дәү әти – әнинең әтисе, кеше турында нидер әйткәненңне ишетсә: «Хата булса, хатаны орма йөзгә, хатасыз бәндә булмас, хактан үзгә», – дияр иде. Икенче дәү әтием ике генә ел булса да Казанда мәдрәсәдә белем алган – бу да эзсез узмаган. Әтинең безне русчага ничек өйрәтүен генә күр: «Юл – дорога, сыер – корова, ат – лошадка, бүрек – шапка, борын – нос». Шигъри рифмалар миңа шул яктан килгән... Аз гына шуклансак, әни: «Берәү сине карап торса, «акыл дигән шәрифтер, күп кешедә зәгыйфьтер», дип әйтә инде, кызым», – дип оялта иде. Бер кунак китеп өлгермичә, икенчесе килеп керсә: «Аяк урынына – тояк, Гайнетдин

Акыллы кеше янында башын селкеп утырыр өчен генә дә күпме гыйлем кирәк журналистка?!

урына Шияп», – дип көлдерәләр иде. Аларның Тукай сүзләре, халык мәкальләре, хәдисләр белән сөйләшүен педучилищега кергәч кенә аңладым.

Кечкенәдән йә табиб, йә хәрби кеше булам дип үстем. Әнинең бертуган энесе хәрби иде, безгә пилотка, чалбар, күлмәкләрен җибәрә – миңа ул киемнәр шундый килешә кебек иде... Ярый, мәктәпне тәмамладым. Медицина институтына керә алмаячагымны чамалыйм, тик ак халат та бик киясе килә. «Керсәң, югарырагына кер, кермәсәң, башка җирдә вакыт уздырып йөрмә», – дип, әни медицина училищесына юлны ябып куйды. Кәеф төште... Классташларыма ияреп, документларны ветеринария академиясенә тапшырып кайттым. Барыбер табиб булам, имеш. Бу да ошамады... Тоттым да совхозга, яшелчә бригадасына эшкә чыктым. Минем холыкның да нинди икәнен беләләр: эти белән әни дәшмәде. Ә эчләре пошкан, күрәсең. Үзем укыган Карагуҗа мәктәбе директоры Илдар абый белән эти август ахырында кәбестә басуыннан килеп алды дисәм дә була. 3 нче класслар укытучысыз калган икән... Бертуган апам укытучы: ул мине өйрәтте, мин – балаларны. Педучилищега укырга кергәч кенә аларга күпме әйберне өйрәтеп бетермәгәнемне аңладым...

Училищены тәмамлауга, документларымны университетка, татар бүлегенә тапшырдым да, кияүгә чыктым һәм... укымадым. Декрет ялыннан соң эшкә, үзем укыткан 14 нче гимназиягә түгел, ә «Госмания» мәдрәсәсенә тәрбияче булып чыктым. Шәкертләр кайтып киткәч, ике катлы мәдрәсәне җыештырып та чыгарам. Авыл баласының шул бит инде аның – торыр җир кирәк. Бүлмә өчен дип ирем слесарь булып эшкә урнашты, ә хезмәт хакы аз. Идән юганга кимсендем дия алмыйм, әмма өйгә кайткач, «Дулкын» радиосыннан Дилбәр һәм Илдус Фәизләрне тыңлаганда: «Дөньяда бәхетле кешеләр бар соң», – дип уйлыйм. Идәнне бөтен кеше юа ала бит аны... Журналистиканың нәрсә икәнен белмим, әмма шигырь сөйләргә ярата идем. Район смотрларын алып бардым. Сәхнә артында бер малайның: «Тагын Левитан чыга», – дип әйтүен ишеткәч кенә алып барудан баш тарттым. Кыскасы, «алып баручыга конкурс уздырабыз» дигәч, тәвәккәлләдем... Нәкъ конкурс башланган минутка барып кердем «Дулкын»га. 16–17 кеше утыра, барысы да матур киенгән. Ә мин чыгарылыш кичәсенә алган костюмымнан. Соңрак башка күз белән карагач кына тынычландым: матур булган ул... Текст укытып карадылар, факстан килгән яңалыкны тәрҗемә иттерделәр, шигырь сөйләттеләр. Һәм шулкадәр кеше арасыннан мине сайладылар! Курыкканнарым! «Югары белемем дә юк, тәҗрибәм дә, әле эшем дә бар иде. Тагын берәр кеше алыгыз», – дим. Август башы иде ул. Мин ул айда 20 көн туры эфирга чыкканмын!

Илдус Фәизгә рәхмәт, үзе «Дулкын» белән арасын өзеп, эштән китеп бара, үзе миңа киңәш бирә: «Тавышың әйбәт, тик син бит сәхнәдә түгел, пафос белән сөйләмә. Һәркемнең күңеленә үтеп керерлек итеп, колагына гына әйткән кебек итеп сөйләргә – гипнозчы кебек булырга тиешсең», – диде. Белемем җитми икән, дидем һәм 25 яшемдә, читтән торып журналистика бүлегенә укырга кердем. Ирем укуыма каршы иде. Бала кечкенә иде бит... Холкым шундый: үсәр өчен миңа киртә кирәк. Һәм шул киртәне куючы миңа баскыч та куйганын аңламый. Тулай торакта яшәгән чагыбыз: өйдәгеләр яткач, ут кабызып утыра алмыйсың, коридорга чыгам да, дәфтәрләремне бәрәңге ящигы өстенә җәеп салам...

«Бер җылы сүз» дигән тапшыру башладым: тыңлаучылар бер-берсенә бер сәбәпсез җылы сүзләр әйтәләр. Хатлар ява! «Җәлил хәзрәт вәгазьләре» дигән китаплар чыккан чак: шулар буенча тапшырулар оештырам. Яраталар!

Ике елга якын эшләгәннән соң, «Татар радиосы»на күчтем. Дөресрәге, 70 кешелек конкурсны узып кердем мин анда. Тормышның яңа этабы башланды. 13 елга сузылды ул. Ә «Тәртип»кә килү... Күңел тартылуы булган инде ул минем. «Татар радиосы»нда эшләгәндә Алмаз Миргаязов белән еш кына «Угадай мелодию» уйный идек: кайсыбыз элеккеге җырларны яхшырак белә? Ул да минем кебек стена радиосы тыңлап үскән.

Кем әйтмешли, тарих дөрес язылырга тиеш, «Тәртип»нең тамыры тирәндәрәктер, дим мин. Чөнки инде 2002 елларда ук Камил Мансур улының чын күңелдән хыялланып: «Эх, халкыбызның әүвәлге җырларын, милли мирасын кире кайтарырга иде! Әгәр мөмкинлегем булса, «Тәртип» дигән радио ачып, тәртип урнаштырыр идем!» – дигәне хәтердә калган...

Халык өчен мөһим бу хыялны Марат Рөстәм улы тормышка ашырды дияр идем. «Тәртип»нең уңыш сере шундадыр: беренчедән, халык сусаган җырлар, һәр тапшыруның алып баручысы итеп берәр күренекле шәхесне чакыру; икенчедән, радионы ачкан иганәчеләребезнең безгә бер башлангычыбызда да комачау итмәве. Киресенчә, булыштылар гына: шәхесләрне чакырабыз һәм тапшыруда катнашкан өчен аларга берәр мең сум гонорар түлибез. 2014 ел бу! Кем күргән моны?! Халык көткән, тансык радио иде «Тәртип». Бер буын җырчылар беркайда яңгырамый башлаган иде бит: Зөһрә Шәрифуллина, Искәндәр Биктаһиров, Фердинанд Сәлаховлар... Алар эфирга кире кайтты. Радиода азан яңгырый башлады! Әйе, халык күңеленә гөрләп барып кердек без. Бүген дә шаккатып искә алабыз Ләйлә Ялалова белән. Ике кеше 10–15 кеше башкарасы эшне алып барганбыз. Шәхси тормышта да минем өчен шактый катлаулы чор булган ул. Ирем ул елны производствода имгәнде – лифт шахтасына егылып төште. Операция арты операция ясадылар: бер аягын кисәкләрдән җыйдылар. Ярты ел коляскада утырды, яңадан йөрергә өйрәнде. Бу хәлне кайнанам бик авыр кичерде: шикәре һәм кан басымы берьюлы күтәрелеп, аны табибларга йөртәсе булды. Ул елны олы улым 11 нче классны тәмамлады, кечкенәсе мәктәпкә керде. Иремнең эш урынында имгәнгән икәнен раслар өчен генә дә ике елга якын суд юлын таптадык..

Эшең барсын дисәң, тирә-юнеңне үзеңә фикердәшләр белән чорнарга кирәк.



■ «Тәртип»нең бүгенге коллективы: (сулдан-уңга) Алмаз Сәйфетдинов, Ләйлә Ялалова (Гыймадиева), Айсылу Лерон, Ризәлә Исмәгыйлева, Ләйлә Шаһиева, Айваз Садыйров.

Һәм шундый сынаулар аша аяка бастырган радионы ябарга дип хәл итәләр... «Тәртип»кә үз ешлыгын биргәч, сине башына яулык япкан, диделәр...

– Әйе, яптылар... Сәбәбен белмәдек. Иганәчеләр шулай хәл итте – ул эшләгән ешлыкны Мәскәүгә саттылар. Әмма без моның белән килешмәдек. Халык килешмәде... «Тәртип»не саклап калырга кирәк», – дип, ул көннәрдә 10 меңнән артык имза гына җыйдылар. Сөйләсәм, бик озак... «Тәртип» дүрт ел буе кунак форматында «Болгар» радиосында һәм... минем кухнямда эшләде. Бу авырлыкларны күтәрешкән гаиләмә – иремә, балаларыма рәхмәт. Кунакның кадере өч көн бит аның – «Тәртип»кә дә кайчан да булса башка чыгарга кирәк иде. Мин югарыга язган хатларның исәбе-саны юктыр... Күз яшьләремнең дә. Хатын-кыз бит инде... Өмет өзелә язган бер мәлдә: «Әгәр «Тәртип»кә аерым ешлык бирсәләр, башыма яулык ябар идем», – дидем шул. Бирделәр бит ешлыкны! Ишеттеләр! Документларны Илшат Әминов белән бергә әзерләдек. Президентка да бергә кердек. Ешлыкны алгач, яулык искә төште, билгеле. Тик... бәйлисе килә дә, килми дә... Аннан мин аны оныттым – эшкә чумдым. Ә бер көнне колагым сызлый башлады. «Ашыгыч ярдәм» хастаханәгә алып китте. Бернинди сәбәп тапмадылар. Аның каравы, мин таптым. Нәзер кебек әйтелгән булган бит... Инде яулыкны гомер буе бәйләгән кебек хәзер.

Тыңлаучы сезнең йөзләрне күрми, тавышыгызны гына ишетә. Әмма журналистның кәефе ничек икәне, аның йөзендә елмаю бармы-юкмы икәне эфирда чагыла дип уйлыйсыңмы?

– Елмаеп сөйләү бөтенләй икенче төрле ул... Тик елмайсаң да, кәефең булмавын якыннарың барыбер сизә. Әни, апалар... Ул тавыш тембрына чыга. «Дулкын»да эшләгәндә авырып киттем. Бер сәбәпсез... «Татарстан» радиосы дикторы Тәлгать абый Хаматшинның әйткән сүзләре искә төште шунда. «Сез, радио хезмәткәрләре, аңламыйсыз гына. Үзегезне күрмәсә дә, тыңлаучы энергиягезне ала. Шуңа күрә үзеңне ниндидер бер кысага кертергә, бөтенләй ачылып бетмәскә кирәк», – дигән иде ул. Мин моны еш сизәм. Дүрт сәгать эфирда эшләп чыгасың. Әйтерсең шахтада күмер чапкансың! Тик үзгәреп тә булмый. Тәлгать абый үзе дә үзгәрә алмагандыр... Тыңлаучы сине ихласлыгың, күңелеңне ярып салуың өчен ярата. Шул очракта гына ул сиңа ышана. Радио аша яңгыраган сүзнең көче исә зур аның. «Дулкын»да эшләгәндә шундый очрак булды. Котлау җибәрүче, кем кемне котлаганны гына күрсәтә, текстка «итне», гадәттә, син кундырасың. Бер ир-атны шулай юбилее белән котлаганмын. Аны дөньядагы бер яхшы кеше итеп мактаганмын. Ул, чынлап та, әйбәт кеше булган, тик соңгы вакытта салгалый башлаган. Радионы тыңлаганда ул бик оялган, хәтта елаган һәм... эчүен ташлаган. Милләтне саклап калу өчен дә иң кулай корал дип саныйм радионы. Радио гел тамчы кебек тамып тора һәм әкрен генә күңелләргә сеңә.

Иң кызык, иң кирәкле сүзләрне спикер «микрофон сүндерелде» дип уйлагач сөйли башлый, диләр...

– Нәкъ шулай! «Чакырылган кунак» тапшыруын без өчәр сәгать яздыра идек. Шәхесләр үзләре исән чакта, архивка аларны мөмкин булганча күбрәк сөйләтеп каласы килә. Илһам абый Шакиров белән дә тапшыру эшләдек шулай. Микрофонны сүндерүгә ул китте сөйләп, китте сөйләп... Микрофоннан куркучылар, аның алдында югалып калучылар да юк түгел. «Болгар» радиосында утырганда, ул тапшыруны туры эфирда алып бардым. Иркенәеп сөйләшә генә башлыйсың, вакыт бетә дә китә. Сүзнең иң тәмле җирендә! Кайбер кунакларны хәтта Әлфинур апа Хисамига алып кереп, эфирга сыймаган фикерләрен студиядә кабат яздырып ала идек. Аннан тапшыруның кабатлау чыгарылышында ул фикерләрне дә өстим.

Бүген һәркем үзенчә журналист. Социаль челтәрләрнең берсенә теркәлә дә, яза башлый...

– Журналистлар – башка камырдан алар. Аларга барысы да кызык, һәммә нәрсәдә гамьнәре бар. Укыганда, безнең группага дәрескә керергә укытучылар шүрли кебек тоела иде миңа. Көндезге бүлеккә конкурстан узмаган көчле яшьләр байтак иде арабызда. Укытучыга сорау яудыралар. Бертуктаусыз! Укып бетереп, «Тәртип»тә эшли башлагач, безнең хакта басылган беренче язмаларны кулыма алгач, йөз кат инандым – бөтен кеше журналист була алмый. Университетта укыганда бик күп нәрсәгә өйрәндем, әмма журналист булып туалар икәнен дә аңладым... Әдәби тел белән хатасыз язучылар бар, әмма чын журналист аның ун җөмләсен бер җөмләгә сыйдыра да бетерә. Ә инстаграмда бигрәк тә кыска-оста язу кирәк. Кызганыч, чын журналистлар гына бүген бик аз калып бара. Күпләренә сенсация гына кирәк.

Интервью алырга теләгән кешеләрең бармы?

– Минтимер Шәрипович белән сөйләшәсем килә. Рөстәм Нургалиевичның әнисе турында тапшыру эшләү теләге бар. Бер дигән шәхесләр тудырып, тәрбияләп үстергән ана хакында халык белергә тиеш дип уйлыйм. Ә җырчылардан, үзем дә белмим, нишләптер, Салаваттан

шикләнәм. 20 елдан артык радиода эшләп, тапшыруга чакырырга ничә мәртәбә талпындым, тик телефон номерына карап утырудан узган юк.

Ксения Собчак күптән түгел 17 ел төрмәдә утырган бер маньяктан интервью алды. Тамашачы икегә бүленде: кемдер журналист яклы, кемдер аңа кискен каршы... Ничек уйлыйсың, начар мисал белән халыкны тәрбияләп буламы?

– «Не судите, да не судимы будете», ди руслар... Язмышын, ул көнгә нигә төшкәнен, бу адымга нигә барганын белмичә, берәү турында да начар фикер әйтергә ярамыйдыр. Берәү дә анадан начар булып тумый бит. Каядыр башы бар бу фаҗиганең. Менә шуның төбенә төшеп карау, тормыш нигә аны шушы хәлгә китергәнен, кырыслатканын, хәтта явызландырганын ачыклау башкалар өчен, чыннан да, гыйбрәт була ала. Кеше ялгышларында өйрәнү дә кирәк кайчак...

Бала белән декрет ялында утырган чагым. Урамга һава суларга чыгуга, яныма гел бер эчкече хатын килә. И-и, сөйләшәбез моның белән! «Ку, нәрсәгә кирәк ул сиңа!» – диләр... Казан авиация институтын тәмамлаган булып чыкты ул, хәтта студентларга үзе белем биргән. Өендә бернәрсәсе диярлек калмаган – сатып эчкән, ә бер стена тулы китаплары исән! Журналист психолог та бит ул. Ярдәм итәргә өмет бар иде кебек, тик кинәт юкка чыкты...

Берәүне дә бернәрсә өчен дә гаепләмәскә яши-яши генә өйрәнәсең. Беркайчан ашыгыч нәтиҗәләр ясарга ярамый: иртәгә үзеңне ни көткәнен белмисең. Заманында җитәкчелек белән дә килешмәгән чакларым бар иде. Хәзер үзем шул урындыкта утырам менә.

Иң авыр интервью дип кайсысын атый аласың?

– Бәлки авыр түгел, җаваплы диярг әдер? «Татар радио»сына килгәч, «Язмыш» дигән тапшыру эшли башладым. Максатым – кеше язмышларының гыйбрәтле өлешләрен эфирда күрсәтеп, башкаларны зарланмаска өйрәтү иде. Аны бик тә Фәнис абый Яруллиннан башларга теләдем. Редакциябез исә җиденче катта – лифт кичен, бу тапшыру эфирга чыккан вакытта инде эшләми. Димәк, Фәнис абыйны студиягә китереп булмаячак... Юлын таптык – телефон аша сөйләштек. Нәкъ мин теләгәнчә җылы, гыйбрәтле әңгәмә килеп чыккан иде. Фәнис абый, шигырьләремне анализлап, әле һаман дөнья күрмәгән китабыма кереш сүз дә язган иде.

«Әйе» яки «юк» дип кенә утыручы әңгәмәдәшләр дә очрый, җавапларны сытып кына чыгаручылар. Әйе, авыр... Аның турында алдан өйрәнгәнеңне сөйләп чыгасың инде андый чакта.

Безнең эштә янып бетмәс, арып туктамас өчен каяндыр көч алу мөһим. Менә ул көчне кайдан аласың?

– Хәләл туйлар, никахлар үткәрәм, шулардан энергия алганымны күптән аңладым. Андый алып баручылар юк заманда ук тотынган идем бу эшкә. «Туган авылым»да көрәшче Мәдьяровлар үткәргән беренче хәләл мәҗлес истә – җырлап, уйнап, биеп туймадылар. Исерткеч эчемлексез табыннар күргән юк иде бит әле, шаккаттым... Алтын туйлар үткәрергә яратам! Күпме гыйбрәт аласың! Лиюдә исемле апа алтын туйларында: «Гомере буе кешеләрне бары яхшылык белән җиңдем. Оятларыннан үзләре миңа яхшылык эшләр дәрәҗәгә җиткерә идем аларны», – дип сөйләде. Болгардан иде ул, гомер буе урман хуҗалыгында эшләгән. Хуҗалар алышынып торган, ә ул гел үз урынында калган... Никах мәҗлесләре алып бару да көч бирә. Анда гел яхшы сүз, анда гел дога... Аннан елга бер булса да концерт алып барырга кирәк миңа. Сәхнәдә басып торганда энергиянең дулкын-дулкын булып килгәнен сизәм... Авыл да көч бирә! Бакча! Җир! Әмма үз өебез дә, бакчабыз да хыялда гына әлегә. Икебезнең дә туган авыллар шәһәргә якын, әниләр ялгыз булгач, ике авыл арасында йөреп олыгаеп киләбез... Гаилә дә бирә ул көчне. Язмыштырмы, балаларны тәрбияләп утырырга вакыт беркайчан булмады инде минем. Эшләдем, эштән соң тамада булдым. Әмма алар сине кабатлаганын, олы улым өйләнеп, туй ясаганда аңладым. Чын милли туй оештырдылар Инсаф белән Илсинә. Мин хыялланганча! Үзләре белеп! Болай гына яшәлмәгән, бик күп нәрсә аларга да күчкән икән... «Тәртип» радиосы туктап торган арада, хәләл мәҗлесләр оештыручы «Ихлас» бәйрәм агентлыгы ачкан идем. Тик ул эшләп китсен өчен, үз улымның туен күрү кирәк булган бугай. Никах-туй мәҗлесләрендә гореф-гадәтләребез киләчәккә тапшырыла, шуңа да аларга җитди карарга кирәк... Абыйсы үрнәгендә икенче улыбыз да үсеп килә. Берәү әйткәндәй, телиләрме-юкмы, әмма безнең өйдә сыйфатлы музыка гына тыңлыйлар. «Тәртип»тә яңгыраган теләсә кайсы җырга кушылып җырлап җибәрә ул да. Әйе, барысы да гаиләдән башлана. Өметләребезне, иншалла, төпчегебез дә аклар...

Үземне Алланың яраткан бер баласы дип саныйм. Юлларның бераз урау булуы бары тик үземнең тәҗрибәм җитмәүдән киләдер, акыл туплау, үсү өчен генәдер... Үткәнемә карасам да, бүген дә юлымда гел ярдәмчел кешеләр, зыялы олпат шәхесләр минем. Язмышка ышанам. Бернинди таныш-белеше булмаган авыл баласы, калага килеп, укып, татар телендә сөйләүче шундый радиоларда эшләсен әле! «Тәртип»нең яңадан халыкка кайтуы да – могҗиза. Алланың рәхмәте!



Кода-кодагыйларыбыз да, шөкер, үзебезгә тиң кешеләр.

PRESSA

«СИН ЯЛГЫЗ ТҮГЕЛ...»

– Лаеклы ялга чыккач, башта өч ел буе ялсыз, бәйрәмсез бала карадым: кечкенә кызымны һәм ике оныгымны. Берсен дәрескә озатам, икенчесен – музыка мәктәбенә, өченчесен – биюгә... Алар үсеп киткәч, кинәт бушап калдым. Ә мин гомер буе актив тормыш белән яшәгән кеше – күңелемә нидер җитми...

Әйе, Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры янында ул көнне Хөрия ханым тормышын үзгәртәчәк, аны бөтенләй башка юнәлешкә алып кереп китәчәк карарны кабул итә – «Көмеш волонтерлар» хәрәкәтенә кушыла. Көмеш, димәк, чәчләренә чал кергән волонтерлар. Әмма йөрәкләрендә яшәү дәрте янып торган!

Элек без волонтерларны спорт чараларында гына күрә идек, ә хәзер алар бөтен өлкәләрдә дә бар. Хөрия ханым да бер көнне мөмкинлекләре чикләнгән балалар белән мастер-класс уздырса, икенче көнне сугыш һәм тыл ветераннарының хәлен белергә чыгып китә, өченче көнне аны берәр өмәдә очратырга була, аннан – ярминкә оештыручылар арасында...

– Сине берәү дә мәҗбүриләми: көн саен да бара аласың, атнага, айга бер генә тапкыр да. Елга бер дә... Күпмегә көчең җитә – шулкадәр булышасың. Мин үзем барысына да өлгерергә тырышам! Холкым шундый... Волонтерлык дисциплинада тота. Беркая да барасы булмаса, өйдә эленке-салынкы гына йөрисең бит, аннары эшләрмен әле, дисең. Ә чыгып китәсе булгач, барысына да җитешәм: ашарга әзерләргә дә, юарга, җыярга да... Сәламәтлеккә дә файдалы әле ул: элегрәк кан басымы белән интегә идем, хәзер поликлиникага юлны онытттым. Анда йөрергә вакытым да юк, кирәге дә калмады... «Нигә дип бер тиенсезгә чабасың, сиңа нәрсә бирә инде ул?» – дип сораучылар бар. Бирә! Һәрхәлдә, биргәнемә караганда алганым күбрәк. Моны аңлау өчен кемгәдер ярдәм итеп, шул кешедән «рәхмәт» сүзе ишетеп карарга кирәк...

Кеше өчен иң авыр хис – ялгызлык хисе. Мине оныттылар, берәүгә дә кирәкмим дип уйлау. Андыйлар өчен иң зур ярдәм – хәл белү, аралашу, җылы сүз әйтү.

– Мин – Татарстанның «Җиңүнең көмеш волонтерлары» командасында. Безнең бурыч – яшьләргә патриотик тәрбия бирү, өлкәннәргә – сугыш һәм тыл ветераннарына игътибар күрсәтү. Без киләбез дә күңелләрендәге бушлыкны тутырабыз: сөйләшеп утырабыз, альбомнар актарабыз... Галина Михайловна Юркова бар менә. 16 яшьтән сугышка барып кергән. Йөри алмый, коляскада утыра ул бүген. Күп вакыт аңа Илдар белән икәү барабыз. Әйе, гаиләбез белән волонтерлар без... Бер баруда карыйм, Галина Михайловнаның розеткалары бушаган: Илдар аны ясап куйды. Кул юарга кергән иде, краны ага икән – төзәтте. Иттарткычы ватылган – анысын ремонтка илттек. Кулдан нәрсә килә, шуңа тотынабыз... Валентина Александровна – сугыш чоры баласы. Әнисе госпитальдә эшләгән аның, ә ул анда барып солдатларга концертлар куеп йөргән. Яралы сугышчылар кечкенә кызчыкка карап, үз балаларын сагынгандыр... Отар бистәсендә 91 яшьлек Фатыйма апа бар. Сугыш вакытында, әниләре үлеп, бер кочак бала ятим кала. Шәһәргә бер авыз русча сүз белмичә килә ул, фабрикада бригадир булып күтәрелә. Стахановчы! Гармунда уйный, әле дә җырлый. Тавышының матурлыгы!.. Күпме авырлык кичерсә дә, күңеле катылanмаган. Бәйрәмнәрдә хәлләрен белергә тырышабыз. Берсенә дә буш кул белән барганым юк. Пирог, берәр төрле кайнатма йә мандариннар алам... Әби шулай иде минем: үзебезгә берәү генә кирәк булганда да, «Күршеләр сорап керсә», дип һәрвакыт ике ипи алды. Һәм: «Артык ипиең юкмы?» дип керүчесе дә булды... Чын күңелдән эшлим. Башкаларны куандыру шундый рәхәт...

Кешеләрне куандыру өчен ниләр генә уйлап тапмый ул! Үзе кебек өлкәннәрне туплап, кич утырып бәйләү бәйли башлаганнар – күзлек савытлары кемдер өчен менә дигән бүләк. Ә курчаклар?! Аларын бөтен гаилә белән ясыйлар. Гап-гадиләр, әмма кемгә генә алып барсаң да, сөенеп кабул итәләр. «Кәефне күтәрә, рәхмәт!» – диләр. 8 Март алдыннан ире белән икәүләп үзләре кайгырткан өлкәннәргә лаләләр таратып чыкканнар. («Илдар минем бәхеткә булган... «Барырга кирәк», – дисәм, «Нигә», дип сораганы юк, машинага чыгып утыргач, адресны гына белешә», – ди ул.) Казанда якын туганнары юк: бу өлкәннәр белән аралашу шул бушлыкны да тутыра.

Әйе, берәүгә дә коры кул белән барып булмый. Бигрәк тә Балалар йортларында тәрбияләнүче балалар янына. Мастер-класс уздырыйм дисәң, бар да кирәк: кәгазь, картон, җилем, пластилин... Аларны рухи яктан үстерә, физик мөмкинлекләренә туры килә торган мастер-класслар сайлый ул: ике сәгатькә сузылган бәхетле минутлар гына бик тиз үтә... Төрле бәйгеләрдә катнашып, шуңа грантлар отарга тырыша Хөрия ханым. Өч елда – дүрт грант! Аз түгел!

...Март башында Россия Президенты Владимир Путин «Без бергә» Бөтенроссия хәйрия акциясендә катнашучылар белән очрашты. «Көмеш волонтерлар» исеменнән анда Казаннан Хөрия Халитова катнашты. Хәер, Казаннан гына түгел, өлкәннәр арасында Россиядән дә бердәнбер волонтер иде ул. Пандемия шартларында өлкәннәргә, мохтаҗларга, караучысыз калганнарга кайда, нинди ярдәм күрсәтелде – сүз шул хакта барды. Очрашуны видеоконференция аша кушылган Хөрия ханым чыгышы белән төгәлләделәр.

– Пандемия чорында яшьтәшләремнең күбесе өйдә генә утырды, тик мин алай булдыра алмадым, – дип сөйләде ул. – Саклык чараларын күреп, кемгәдер дару алып кайтып бирдем, кемгәдер су, азык-төлек... Танышларым «кайнар линия»гә түгел, нәкъ менә миңа шалтыраттылар. Елдагыча, барысын да Яңа ел белән дә котладык. Ирем Кыш бабай, кызым Кар кызы булып киенде, мин – гном. Илдар эштә көннәрдә үземә дә Кыш бабай булырга туры килде... Пандемия башлангач «Ярдәм фонды» мохтаҗларга азык-төлек наборлары әзерләп таратуны оештырды. Без шул ризыкларны пешереп тордык. Мин, мәсәлән, өчпочмак ясаштым – суган әрчедем. Яхшы эшкә тотынуыбызны сизде ахрысы – суган бер дә күзгә кермәде...

Хөрия ханымның бәйгедә җиңгән проектларының берсе – «Син үзең генә түгел» дип атала. Син ялгыз түгел... Кешене яшәтә, аңа көч, рух бирә торган сүзләр!

Гөлнур ХӘСӘНШИНА



2018 елның 8 мае иде ул. Опера театры бинасында ул көнне Бөек Ватан сугышы ветераннарын хөрмәтләделәр. Кызыбыз Алия, волонтер буларак, бөтен республикадан җыелган ветераннарга канәфер чәчәкләре бүләк итеп торырга тиеш иде. Әтисе белән без аны озата бардык. Театр алдында – бәйрәм рухы! Бер-бер артлы автобуслар килеп туктый. Алардан күкрәкләренә орден-медальләр таккан әби-бабайлар төшә. Һәрберсен барып кочаклап аласы, бүгенге тыныч көннәр өчен рәхмәт әйтәсе килә... Китә алмыйча, Илдар белән аларга карап, сокланып басып торабыз. Шул вакыт зур итеп язылган хәрефләр тарата башладылар. «Рәхмәт» һәм «спасибо» сүзләре икән. Көтмәгәндә миңа да «с» хәрефен китереп тоттырдылар. Мин – оештыручыларны, алар мине белми. «Волонтер түгелмен, кирәкми», – димәдем. Ике сәгать ярым шул хәрефне күтәреп басып тордым. Аны гел бер югарылыкта тоту бик җиңел түгел. «Арысагыз, башкалар белән алышыныгыз», – дигәннәр иде, барыбер хәрефне кулымнан ычкындырмадым. Шул көннән мин – волонтер...



Россия Президенты В. Путин белән очрашудан өзекне карар өчен, смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.

«МИНӘ ХӘЕРХАҺ ЮЛДАШЛАР ОЧРАДЫ...»



Бу – аның дөньясы. Адым саен сикәлтәгә, адым саен сынауга дучар булган дөньясы. Югалтулар белән чорналган... Әмма табышлар белән дә! Бер кулы белән алган язмыш, икенче кулы белән бирә дә тора: эчкерсезлек, киңкүңеллелек, ихласлык, сабырлык, шөкер итә белү... Барысы да аңа хас сыйфатлар! Тагын – сәләт! Анысы да язмыш бүләге! Сүз тәмен, сүз кадерен белү. Сүзләрдән сурәт коя белү. Җаннарга үтеп керү... Әңгәмәдәшем – язучы-прозаик, журналист Роза МУЛЛАНУРОВА-КАМАЛЕТДИНОВА. 1946 елның 16 маенда Әгерҗе районы Яңавыл авылында туган. Татарстан Журналистлар берлеге (1991) һәм Татарстан Язучылар берлеге (1995) әгъзасы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1996), Татарстан журналистларының «Бәллүр каләм» бәйгесе (2001), Татарстан Язучыларының Фатих Хөсни исемендәге бүләге (2019) иясе.



ТАМЫРЛАР Безнең нәсел Әгерҗе ягындагы иң зур авыл саналган Көчектә тармакланган. Әмма утызынчы еллар башында, аймактагы ун-унбишләп гаилә, ун-уникe чакрым ары китеп, яңа тормыш корырга ниятләп, дәррәү юлга кузгала. Бабайлар, озын-төз наратларны кисеп-турап, таза бүрәнәләрдән иркен йортлар җиткереп, яңа сала – Яңавылга нигез салган. Мин үскән йорт – урталыкта, Югары оч, Чүкечбаш, Түбән оч дигән урамнар тоташкан җирдә якты, зур тәрәзәләре белән көлеп, балкып тора иде. Безнең Габдулла бабыкай өч тапкыр өйләнгән. Ике хатыны да бер-бер артлы дөнья куйгач, аңа 15 яшьлек Маһинур атлы кызны димлиләр. Сөйләүләренә караганда, йөремсәк, аралашырга, сәүдәгә маһир ир була бабабыз, «Алтыга ал, бишкә сат, исемең булсын сәүдәгәр», дип көлеп сөйләвен әле дә хәтерлим. Яшь аралары зур булуга карамастан, әбекәй белән килешеп, тату гомер кичерәләр. Бу кадәресенә үзем шаһит, чөнки әби-бабай хозурында үстем. Унбер балалары булса да, мин белгәндә исәннәре дүртәү иде: фронт юлларын гизгән, яз саен яралары ачылып интектергән Лотфулла абыкай, ярты сәламәтлеген окоп казыганда җуйган әнкәем Сара, сеңелләре Мәрьям, Мәдинә апалар.

Безнең әткәй сугышта кулын куеп кайта. Әнкәй Идел аръягында туң җирне чокып, окоп казыганда суык тидереп, тиф йоктырып авылга көчкә кайтып егыла. Гомер буе саулыкка туймады ул, аборт тыелган заманда биш бала тапкан. Кайнанасы Мәрьям әбекәй вафат, Мулланур бабайның җилле чагы: читтән үткен яшь хатын алып кайта. Чирдән башы чыкмаган киленнең үги белән борчалары пешми. Ташландык иске бер йортны сипләп, яшьләр башка чыгарга мәҗбүр була. Ә атна-ун көннән, Бөек Җиңүне бәйрәм итүгә нәкъ бер ел һәм бер атна тулгач, мин якты дөньяга аваз салам. Ашар ризык булмагач, әнкәйнең күкрәгенә сөт төшми. Еларлык хәле калмаган нарасыйны Маһинур әбекәй: «Бала төс түгел икән сезгә, үзем үстерәм», – дип, алъяпкычына төреп алып кайтып китә.



БАЛАЧАК Бабыкай дөнья куйды, апалар кияүгә китте. Болын кадәр йортта әбекәй белән икәү калдык берзаман. Тормыш арбасын сөйрәү җиңел түгел. Кәҗә асрыйбыз – сөт савам, печән эзләп чабам. Каз-үрдәкне Янган күлгә куып төшерәсе, кичен барлап алып кайтасы, кыяр-кишергә су сибәсе, әрәмәдән утынга ярардай чыбык-чабык юнәтәсе бар. Эш-мәшәкатьнең бетәсе юк. Укырга да яратам. Кулга ни эләксә, шуны кача-поса укыйм! Берсендә укытучы Рәшит абый: «Фигаро тут, Фигаро там...» дип җырлап йөрисең генә калды», – димәсә, чит ил әдәбиятын, бәлки, кулга да алмас идем. Гарьләндем. Бомарше әсәрен ул үзе табып бирде. Ике йортка хезмәт


итәсең ич, диясе килгәндер. Чыннан да, тау астындагы Газзә чишмәсеннән, үзебезгә һәм «тегеләргә» – әткәйләргә потлы чиләкләр белән ун-унбишәр көянтә су ташыйм. Якшәмбе – ике йортта идән-сәке, кер юу, чишмәдә чайкап элү, бала-чагага күз-колак булу көне... Ике хуҗаның хезмәтчесе сыман бөтерелүемнән көлгән укытучым.



УКУ Класста сигезәү генә идек. Биш кыз, өч малай. Бүген сорамаслар әле, дип өметләнәсе юк, «икеле» өчен баштан сыйпамыйлар. Көн дә такта янында мәсьәлә чишәсе, ятлаган шигырьне сөйлисе – җавап тотасы. Әбекәй, «китап корты», дип әрләсә дә, татар теле укытучысы Рабига апа үз итә. Сынамакчы булдымы, көл җыю өмәсендә классыбызның җиңү яулавын сурәтләп мәкалә язарга кушты. Район газетасы «Ленин юлы»на җибәргән идек, басылып та чыкты. Иҗат дәрте уяну, чирканчык алу шуннан башланмадымы икән?.. Берсендә өч яшькә кечерәк, чәтертән, тиктормас сеңлем, җайсыз тоттымы, сөт чүлмәген төшереп ватты. «Син эттең, әнәйгә әйтәм, кирәгеңне бирә», – ди бу миңа. Әләкләшер дә! Акланcам да, беркем якламас. Түзмәдем: «Гәҗиткә язам сине!» – дип ычкындырдым. Кычкырып көлде: «Синме? Яза беләсеңмени?» Утырдым да яздым! Тик туганыңны хур итү юньле эшме – кыз образын малайга әйләндердем. Укытучы апа элек биргән адреска, редакциягә юлладым. Берәр ай үткәч, гәҗитне ачсам – «Безнең Илшат»! Хикәя! «Синең эшме?» – дип сорый Рабига апа. Кыяр-кыймас: «Мин...» – дим. Сеңлеңне ник хурладың димәсә? Ә ул: «Яшь ленинчы»га җибәр!» – диде! «Безнең Илшат» республика матбугатында да дөнья күрде. Һәм... канат куйды! Хикәя арты хикәя сырлыйм. Кайсы басыла, хәтта ничәдер тиен гонорар да килә. «Ялкын» журналында, «Яшь ленинчы», район газеталарында, «Тылсымлы китап» дигән күмәк җыентыкта дөнья күрде язмалар... Укырга кирәк! Ә авылда җидееллык мәктәп кенә. Әбекәй карт, әтәйдән дә ярдәм көтеп булмый: очны очка көчкә ялгап, бездән дә ярлырак яши алар. Мулланур бабай әткәйне үгетли: «Сыер саварга иренеп, әбисендә нишләп ята ул кыз? Фермага төшсен дә сыер саусын! Булышсын!» Өметем өзелә дигәндә, чит ояда үскәнгә мине сөйми, дип уйлаган, кырыс, усал күренгән әткәем бәхәскә нокта куя: «Укыйсым килә, дия бит, укысын!» Иж-Бубыйда укыганда, ачка киселеп, укуны ташларга торганда, әткәй килде. Директор Әхнәф Шәйдуллович чакырткан. Ике фронтовик, сөйләшеп-килешеп, ашханәдә ашау ягын хәл иттеләр... Районда чыга торган «Ленин юлы» газетасында Лена апа Гайнанова (Гаяз Исхакый иҗатын илгә кайтару, таныту өчен биниһая зур көч куйган галимә) эшли иде. Хикәяләремне җыеп, Язучылар берлегенә юллаган. Миңа – бала-чагага берлекнең әдәби консультанты Мөхәммәт Садри хатлар яза, киңәшләрен бирә. Ә тугызынчы класста укыганда Казанга – яшь язучылар семинарына чакырдылар. Укытучым Фәнилә Шакировна, Мәдинә апалар, үз гомеремдә кию түгел, тотып та карамаган үкчәле туфли, шифон күлмәкләрен кидереп, башкалага озатты. Энҗе апа Мөэминова белән бер бүлмәдә тордым. Саҗидә апа Сөләйманова, Әдип абый Маликовлар белән аралаштым. Саҗидә апа белән бер очрашу, аралашу үзе бер гомергә тиң икәнен аңлар өчен вакыт кирәк булды.



УҢЫШ Тормышым, иҗат юлым, шома, сикәлтәсез булды, дип мактана алмыйм. Әмма сынауларны узарга ярдәм итәрдәй, игелекле, яхшы юлдашлар очраган миңа. Университет тәмамлагач, китапханәдә, аннан дары заводында – Киров районында татарча чыга торган бердәнбер күптиражлы «Ленинчы» газетасында егерме елга якын редактор булып эшләдем. Ә туксанынчы еллар башында «Азат хатын» журналына – сәнгать һәм сәясәт бүлегенә эшкә чакырдылар. Ярты миллион тираж белән басыла, бар дөньяда татарлар яратып укый торган «Сөембикә» журналында, патша армиясендәге солдат сыман, төгәл егерме биш ел хезмәт иткәнмен. Кыйтгаларга таралып яшәгән халкыбыз, кеше язмышлары хакында күпме мәкалә, язмалар әзерләнгән! Казанны сагынып килгән читтәге кардәшләр журнал хезмәткәрләрен якыннан күреп аралашуны, рәсемнәргә төшүне дәрәҗә саный иде. «Ак калфак» татар хатын-кызлары оешмасына шул елларда нигез салынды. Күп көч куеп оештырган «Гыйффәт туташ», «Киленбикә» конкурслары зур театрларда узды. Казанда кызлар гимназиясе, татар балалар бакчасы ачуны «Сөембикә»леләр башлап йөрде. Баш мөхәррир Роза Туфитуллова җитәкләгән ул чараларның уртасында кайнап яшәдек. Журналистка хөрмәт, басма сүзгә ихтыяҗ, ышану зур булган чорда иҗат иткәнбез. Әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире буларак, халкыбызның талантлы, олуг затлары – Мөнирә Булатова, Сара Садыйкова, Шәхсәнәм Әсфәндиярова, Гөлшат Зәйнашева, Әмирхан Еники, Бакый Урманче, бөек рәссамның гомер юлдашы Флора Әхмәтова, Нәкый Исәнбәт, Гомәр Бәширов, Аяз Гыйләҗев, Шәриф Хөсәенов, Мөхәммәт Мәһдиев, танылган артистлар Зәкия Туишева, Наилә Гәрәева, Вафирә Гыйззәтуллина, Гөлсем Исәнгулова, Ания Туишевалар белән очрашулар, әңгәмә, интервью әзерләүләрем, Шәфика Котдусованың сеңлесе, якыннары белән очрашулар тәэсирендә туган истәлек-язмалар... Хәзер дә йөрәктә, җанда, кадерле алар. Укучылардан килгән хатларның: «Роза Мулланурова, Роза Камалетдинова язмаларын яратып укыйм» дип башлануына да ияләшәсең... Ләкин күңелне тырный торган төер – язылаcы әсәрләр җанны бимазалап торуы да хак. Китап арты китап чыгарырга батырлык, вакыт, әрсезлек җитмәгән.



МӘХӘББӘТ Гашыйк булу, ярату, мәхәббәт һәр йөрәккә көч-дәрман бирә торган олуг хис, дип ышанам. Сөю-сәгадәт бирәүне дә читләп үтми. Тик кадерен беләбезме бу изге хиснең? Мәхәббәт күктәге салават күпере кебек, күптөсле һәм төрле дип инанганмын. Тәүге олы мәхәббәтем Маһинур әбекәем булган. Аннан аерылып, Бубыйга укырга киткәч, ә ул бердәнбер улы, килене янына Тәбәрлегә күченгәч, сагынуга дәва табылмас төсле иде... Әтәй-әнәй кочагында үсмәсәм да, ятим түгел идем. Әнкәйне – Сара ханымны да әбиемнән ким яратмаганмын! Бу ачыш бит! Мәхәббәтнең өр-яңа төсмерен тоюга куануларым! Шагыйрь Тәүфыйк Камалиев

Фото: Анна Арахамия

белән очрашып, егерме яшьтә кияүгә чыккач, олы кызым Миләүшә тугач, мәхәббәтнең иң югары ноктасы гаиләм, сабыем икәненә инандым. Җиде елдан Гүзәлем дөньяга аваз салды. Яшь баланы көйләү-тәрбияләү, олысына игътибарны киметтеме, ул моңсуланып: «Әнкәй, мине дә шулай ык ярата идеңме?» – дип сорап куйды. Тетрәндерде соравы... Сөю, мәхәббәт хисенең зурлыгы-тирәнлеге хакында сирәк уйланабыз шул. «Бармак кына киселсен, һәммәсе авырта, барыгыз да тигез», – дия иде әнкәй дә. Гомер кичеп тә, балаларның, оныкларның кайсын артыграк, ныграк яратам соң, дигән сорауга җавап табалмам.



ДУСЛАР Үзем әллә кем булмасам да, дөнья бәһасе торырлык дусларым бар минем. Балачак дусларым Айсинә, Эльвира, Тәнзилә белән сирәк күрешәбез: ара ерак, авылга сирәк кайтыла. Кайтсам, Айсинә белән күрешми калмыйм. Иҗат таныштырган шәхесләрдән иң тәүдә, 6 нчы класста укыганда хатлар алышкан дустым Ләлә – язучы Ләлә Сабирова белән алтмыш ел буе сер бүлешеп, уй-фикер уртаклашып яшәвебез үзе гаҗәп хәл түгелмени?! Икебезнең дә хикәяләребез «Ялкын» журналының бер үк санында басылып чыккан иде. Күңел офыкларын киңәйтәсе, дуслар табасы килә. Тоттым да хат яздым. Җавап озак көттермәде. Аның белән университетта укый башлагач, тагын да ныграк якынайдык. Беренче курста ук танышкан Фирая Галиева (Зыятдинова) белән дә дуслыгыбыз гомерлек булган икән: аны югалткач, моны тирәнрәк тә аңлап, һаман сагынам... Ә Аксубай кызы Роза Зәйнуллина-Туфитуллова, студент чактан ук мине үз, якын иткән кешелекле, зыялы, зирәк акыллы дустым белән «Сөембикә» журналында бергә эшләдек. Затлы бу басмага мине ул – баш мөхәррир үзе чакырып китерде. Бер-беребезнең уңышына сөенү рәхәт. Адашымның «Язмыш җиле» романы татар дөньясын сөендерде. Ләлә дә җиң сызганып эшли, китаплары басыла. Шөкер, сафта әле без. Җилдәй җитез, кыю журналист Мәдинә Авзалова, якташым Филисә Хәкимова (без бер тамырдан!), Рәсимә Сибгатуллина... Җанга якын, кадерле дусларым исән булсын. Бергә булыйк!



АКЧА 8–9 яшьләр тирәсе идеме, күрше Бәдәр апага ияртеп, Көчек базарына, йомырка, май сатарга җибәрделәр. Артканга түгел, салым түләргә акча җитмәгәнгә! Сату итәрлек бүтән кеше булмагач, өйрәнә торсын дигәннәрме, иртәнге өчтә уятып, чыгарып җибәрделәр. Гөжләгән халык арасында, шау-шулы базар мәйданында әйләнеп-тулганып йөри торгач, адаштым. Бәдәр апа үз тауарын сату белән мәшгуль булгандыр, читтә аптырап, елап торуымны күреп, таныш түгел бер апа килеп эндәште. «Нәстә сатасың?» – дип кулегымны ачып карады. Кичтән язган өч-дүрт йомарлам акмай кояшта эреп, кыяфәтен җуя башлаган, йомыркалар да әллә ни мактанырлык түгел икән. Теге апа хәлемә кереп: «Син боларны базар бәһасе белән сата алмассың инде, бала, жәлләп, үзем алсам гына!» – дигәч, мин җир-күк сөенеп, әллә ярты, әллә чирек бәясенә бар байлыгымны биреп җибәрдем. Миннән сәүдәгәр чыкмасына нык ышанып, сату-алу эшләренә бүтән катыштырмадылар. Һәм дөрес эшләделәр. Бу өлкәдә барыбер әллә ни кыра алмас идем. Акчага табынмыйм, әмма буш кесә белән яшәү рәхәт түгелен дә яхшы беләм.



МАВЫГУ Күрәсең, мавыгучан мин. Укый башлаган китапны, ошамаса да, ахырына кадәр укып бетермичә туктамыйм. Үсмер чакта чигү, челтәр бәйләү белән мавыга идек. Читләрен челтәрләп кульяулыклар, мендәр тышы, тәрәзә кашагалары, алъяпкычлар чиктем. Әле дә исән кайберсе, килеп чыга да, күңелне рәхәт сагыш биләп ала. Яшьлекне сагыну бу... Кибеттә, базарда хәзерге сыман әзер, теккән киемнәр тулып ятмый иде. Тукымасы табылса, тегүчесе, кыйммәт сораса, акчасы юк... Алтынчы класста укыганда, Сабантуй алдыннан әбием сандыгыннан шәмәхә җирлеккә кош каурыйлары төшкән штапель тукыма килеп чыкты. Шулкадәр ошады, миһербанлы әбиемнең аны миңа бүләк итәсенә шигем юк иде. Матур күлмәк киясе килә, тегүче генә юк. «Азат хатын»нан өлге алдым да, үзем кисеп, тегеп кидем. Сеңелләр, туганнар да тегүемне үтенә иде. Туганлык хакы акча белән бәяләнми: тукыманың кайсын боздым, әмма барыбер матур кием тегеп, якыннарымны сөендерүдән ләззәт ала идем. Бакчада эшләү, чәчәк, гөлләр үстерү, Коръән серләренә төшенергә омтылу – болары да мавыгумы, әллә яшәү рәвешеме?



БАЛАЛАР 33 яшемдә тол калып, ялгыз башым ике кыз үстердем. Дүрт онык һәм онықчык – Хәйдәрем, Алсуның кызы Амелия сөйдергеч бөтие сыман. Җанга, бәгырьгә шулкадәр якын, кадерле, газиз, алар – миңа, мин аларга кирәк. Баларым – иманлы, татар җанлы. Шуннан артык ни әйтим? Хатын-кыз кабыгына менгәч кенә мактансын, диләр ич. Мактанырга иртәрәк, яшибез әле, димәк.



КУРКУ Бар ул курку. Алдакчылардан, карт-корыны төпсез чуманга утырту өчен телефонны корал иткән мошенниклардан курку... Әткәйләрдән күчкән кан хәтере искәртәме, миндә дә сугыштан курку яши. Куркусыз кеше кем буладыр, батырмы, гамьсез битарафмы? Белмим... «Аллаһы Тәгаләнең бөеклегеннән коллары арасыннан бары тик галимнәр генә курка», дигәнне дә ишеткән бар. Ягъни, надан кеше Аллаһтан курыкмый, тәкъва булсын өчен, адәмнәргә гыйлем эстәргә кирәк. Һәм дога укып ярлыкау сорарга...



ЯШӘҮ МӘГЪНӘСЕ Мин әдәбиятта яшәдем. Һаман да яшим. Язылмаган әсәрләр әле дә тынгы бирми. Яшәү дәрте сүнмәгән, димәк. Кеше язмышларын сурәтләгән әсәрләрем китап булып басылып чыгуын күрәсе иде. «Үлем – балыкчы көймәсе. Җәтмәгә эләккән балыкны суга салып тора. Балык йөзә. Әмма тартып алыр сәгать якын, бик якын!» Авторын күрсәтми генә язып куйганмын.

Гүзәл ГАЛИЕВА

РЕДАКЦИЯДӘН: *Элеккеге хезмәттәшебез Роза Габденур кызын гомер бәйрәме белән котлыйбыз! Яшәү дәртегез гел шулай ташып торсын, иҗат утыгыз янсын да янсын әле!*

КЕМ ГАЕПЛЕ?

Иремнең беренче никахыннан туган балалары бар. Алар зурлар инде. Бу балалар беренче көннән үк мине никтер кабул итә алмады. Моңарчы әтиләренә килеп, булышкалап йөргәннәр, хәзер килеп күренгәннәре дә, шалтыратып хәл белешкәннәре дә юк. Ирем бу хәлгә бик борчыла. Гаебем булмаса да (алар инде миңа кадәр үк аерылышкан), үземне кыен хис итәм. Бәйрәмнәргә табын әзерләп, чакырып та карадык, төрле сәбәп табып, килмәделәр. Әниләре бармаска, йөрмәскә куша булса кирәк. Миңа нишләп карарга икән? Әниләре белән сөйләшимме, балалар беләнме? Әтиләре моны авыр кичергәнгә эчем поша. Мондый хәл бер безнең гаиләдә генә түгелдер инде, мәсьәләне башкалар ничек чиште икән?

Исемем редакция өчен генә.
Казан шәһәре.

Искәндәр СИРАҖИ,
журналист, язучы

– Бу очракта, мөгаен, балаларның эгоистлыгы турында әйтү дөресрәктер. Ата-ана алар өчен генә яшәргә тиеш дип беләләр, ахрысы, болар. Югыйсә әти-әнисе күптән аерылышкан, бу хатын-кызның бер гаебе дә юк, ул гаиләне җимереп килмәгән. Ничек булса да, әтиләре инде аларны үстергән, балалар кечкенә чакта ук аерылышсалар, алиментын түләгәндер, башкача ярдәм иткәндер. Аның үз тормышын көйләргә дә хакы бар. Балалар өчен дип кенә яшәргә тиеш түгел ул. Ә тегеләрнең шуны аңлыйсылары килми. Сәбәпләре төрлечә булырга мөмкин: әтине бу хатыннан көнләү дә, аның байлыгы чит-ят хатынга кала дип уйлау да...

Хат авторына борчылмаска, тыныч кына яшәргә киңәш итәм. Аның оялырлыгы юк. Һәркемнең үз бәхетен төзергә хакы бар. Картайгач, ныклы тыл кирәк. Балалары фикеренчә, ул ир картлыгын ялгызлыкта уткәрергә, ә балалары аның үлгәнен көтеп утырырга тиеш идеме әллә? Бераздан алар үзләре дә моны аңлар әле. Аңламасалар, ул инде аларның проблемасы.

Лилия МУЛЛАГАЛИЕВА,
Татарстанның атказанган артисты

– Мин бу хатын-кызны бик яхшы аңлыйм. Без танышканда иремнең беренче никахы инде таркалган, ә улы кечкенә иде әле. Үзе дә бик акыллы бала булгангадыр, безнең мөнәсәбәтләр баштан ук җылы булды. Ул безгә еш килә иде. Әле дә шулай. Миңа улым шикелле ул. Намусым чиста, аларның гаиләсе минем аркада җимерелмәде. Ләкин... балага әтисенең ни өчен хәзер башка хатын-кыз белән яшәвен тулысынча аңлатып бетереп булмыйдыр. Һәрбер бала үз әтисе һәм үз әнисе белән бергә яшәгәндә генә бәхетле була. Алар аерылышсалар да, балаларның әтиләренә хакы бар, аларның хокуклары яңа гаиләдә туган балаларныкы шикелле үк.

Мин балаларыбызның аралашып, бер-берсен туган күреп үсүләрен бик телим. Ә инде хатка килсәк, ир кеше үзе сөйләшеп хәл итәргә тиештер дип уйлыйм. Хатын-кызның, ни эшләп карыйм икән, кем белән сөйләшим, диюеннән бер файда да юк.

Белгеч фикере



Ләлә БӘҺРАМШИНА, психолог

– Хат авторы, ирем борчыла, дип язган. Ә ни өчен борчыла ул? Балалары белән аралашулар сирәгәйгән өченме, әллә балалар ярдәм итмәгән өченме? Иң элек шуны ачыкларга, һәм шуннан соң балаларга үзеңнең нәрсә теләгәнеңне ачык итеп әйтергә кирәк. Балалар – безнең көзге, дибез. Хат авторы үпкәләмәсен, димәк, бу балалар әтиләреннән кайчандыр үзләре дә шундый үрнәк күргән.

«Әниләре тыя булса кирәк», дигән сүз белән килешүе авыр. Кечкенә балаларны гына тыеп була, ә монда сүз инде балигъ булганнар турында бара. Аларга, аралаш, аралашма, дип боерып булмый.

Балалар белән яки аларның әниләре белән сөйләшеп карарргамы, дип сорый автор. Әгәр дә ул диалог кора белсә, минемчә, бу хәл килеп тә чыкмас иде. Әниләреннән ул балаларның сирәк килү сәбәбен сорашыр, ә балалардан әниләренең хәлен белешер иде. Бәлки, анда берәр хәл булгандыр, шуңа күрә балалар әтиләре белән сирәк күрешәдер.

РОЛЬЛӘРЕМ БЕЛӘН ЯШИМ...



Яңа бинада яңа тормыш белән яши башлаган Г. Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театрындагы яшьләр труппасы – үзе бер дөнья. Алар калыплашмаган, күзләре янып тора, һичшиксез, талантлылар. Югары дәрәҗәдәге профессиональ спектакльне сәхнәгә чыгарыр өчен йокламыйча, ашамыйча эшләргә әзерләр. Шуларның берсе – театрның визит спектакле «Кәҗүл читек»тә, гомумән, соңгы елларда чыккан күпчелек премьераларда төп рольдә уйнаган уйчан фәлсәфә иясе – Булат ГАТАУЛЛИН.

Булат, син – Казан егете. Рус балалар бакчасына йөргәнсең, аннан соң рус мәктәбендә укыгансың. Ә үзең камил дәрәҗәдә татарча сөйләшәсең?

– Сере бик гади аның: өйдә бары тик татарча сөйләштек. Безне беркем дә татарча гына сөйләшегез, русча сөйләшмәгез дип үстермәде. Өйдә үз телебездә сөйләшү – язылмаган, әйтелмәгән бер канун иде. Без гаиләдә өч бала үстек, үзара да бары татарча гына сөйләштек. Телебез сакланып калуга каникулларны авылда уздыру да тәэсир итми калмагандыр. Апас районы Сатмыш авылына дәү әнием белән дәү әтием янына кайта идек.

Ничек уйлыйсың, актер булып китүеңә нәрсә сәбәпче?

– Сәнгать әһелләре дөньясында үсмәдем, әмма тирә-ягымда сәнгатьне яратучылар иде. Җәй көне авылда кичләрен капка төбендә концерт куя идек. Бөтен авыл җыела. Дәү әти гармунда уйный, дәү әни белән әнием җырлыйлар, мин биим. Бик күңелле иде ул вакытлар. Мәктәптә укый башлагач биюгә йөрдем, музыка мәктәбендә балалайка сыйныфында укыдым. Шуңа күрә сәнгать буенча китүем дә бик табигый. Җитмәсә, абыем да театр училищесын тәмамлаган иде. Өйдә көләбез инде: «Апа самолет төзи, без сәхнәдә җырлап йөрибез», – дип. Тугызынчыны тәмамлауга, музыка көллиятеме, әллә театр училищесымы дигән сорау алга килеп басты басуын. Мин театрны сайладым, чөнки ул барысын да берләштерә: бию дә, җыр да, музыка да анда...

Син театрда инде дүртенче сезон уйныйсың. 20 дән артык роль тудыргансың. Ә визит карточкаң – «Куян Эдвард».

– Мин – бик бәхетле актер, чөнки рольләрем төрле, үземне яңача ачкан режиссерлар белән эшлим. Актер өчен моннан да зур куаныч юктыр. Әйе, Куян Эдвард миңа ябышып калды шул. Ул минем беренче премьерам, беренче зур ролем. Бөтен актерның да беренче роле шулай янәшәсендә йөриме икән ул?! Минеке һәрвакыт үзем белән.

(*Көлә.*) Бу ролемне бик яратам. Башта ничек елап укыган булсам, хәзер дә сәхнәдә елый-елый уйныйм аны. Дөрес, өч ел элек булган Эдвард-Булат белән хәзерге Эдвард-Булат – икесе ике төрле. Ул вакытта тормыш тәҗрибәм дә булмаган, рольне тоемлап кына эшләгәнмендер. Бер ел эчендә остазым Тәслимә апа (*Тәслимә Хәләф – Татарстанның халык артисты. – Г. Ч.*), дәү әнием белән дәү әтием вафат булды. Аларны югалту мине тетрәндерде. Актер бит ул тормыштагы яраларын сәхнәгә алып менә. Хәзер миңа ул рольне уйнавы авыррак. Элек без аны көнгә өчәр тапкыр уйный идек, хәзер бер спектакльдән соң да бик озак һушыма килә алмый йөрим... Эдвардны уйнап чыкканнан соң, биш минут стенага терәлеп басып торам. Сәхнәдә чыгып бетмәгән эмоцияләремне – күз яшемне чыгарып бетерәм. Шуңа да карамастан, бик яратып уйныйм. Уйнаган саен үскәнемне аңлыйм.

Спектакльләрдә син, нигездә, йә үсмер егетне, йә баланы уйныйсың: «Кәҗүл читек»тә – Миңнегали, «Мио, минем Мио»да – Мио, «Озын-озак балачак»та – Кендек... Бу рольләр күңел халәтеңә туры киләме?

– Кыяфәтем дә шундыйрактыр инде. (*Тыйнак кына елмая.*) Миңа беркайчан да үз яшемне бирмиләр. Күңел халәтем дә шундыйдыр. Һаман бала роле бирәләр дип кимсенгәнем юк. Образларым яшь булса да, аларның эчке дөньялары бик бай. Шулай да берәр явыз образ да уйнап карыйсым килә. Әле барысы да алда!

Хыялда йөрткән ролең бармы?

– Бөтен теләгем – оста режиссер белән югары дәрәҗәдәге профессиональ спектакльләр чыгару. Әгәр дә образ мине яңа яктан ача ала икән, теләсә нинди роль уйнарга алыначакмын. Эзләнә торган рольләр ошый. Бу образны йөз тапкыр тудырганым бар, хәзер уйныйм да чыгам, дип эшләү миңа кызык түгел. Авырлыклар яратам. (*Елмая.*) Мин – идея кешесе!

Булат, син Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетында халык театры режиссеры курсында укыйсың. Димәк, киләчәктә Булат Гатауллиннан спектакльләр караячакбыз.

– Тәслимә апа: «Режиссер – үсеп җиткән актер», – дип әйтә иде. Килешәм. Минем әйтер сүзләрем бар. Алдагы көннәрдә куелыр, Алла бирса.

Кариев театры репертуарында бер актер берничә роль башкарган спектакльләр байтак. Актер өчен бу бик авырдыр?

– Җиңел түгел, әмма спектакльне яратасың икән, ул авыр булып тоелмый. «Хикмәт әкиятләре»ндә, мәсәлән, барыбыз да берничә рольгә кирәбез. Йөгереп керәбез дә тиз генә костюм алыштырабыз. Әле бит соңга калмыйча, музыка тактына туры китереп, сәхнәгә чыгып җитешергә дә кирәк. Ардыра, әмма ул рәхәт ару.

Булат, син театр белән янып яшисең. Телеңдә – гел спектакльләр, театр, труппадашларың...

– Без барыбыз да шулайдыр. Театр бит ул ансамбль. Бөтенебез бер тарафка карап эшләмәсәк, спектакль барып чыкмый ул. Соңгы елда куелган спектакльләр ансамбльле, шунысы сөендерә. Ничә ел «Тантана»да «Иң яхшы балалар спектакле» номинациясендә җиңү яулыйбыз. Бу шәхси җиңүгә караганда, күпкә көчлерәк сөенеч. Кариев театры – минем йортым. Башка театр турында хыялланмыйм да. Тәслимә апага рәхмәт. Ул сәхнәне яратырга, бөтен җаныңны биреп эшләргә өйрәтте.

Булат, ә кызлар...

– (*Көлә.*) Кызлар күп инде ул, әмма күңелемә ятканын тапмадым әле... Шәхси тормыш хәзергә икенче урында...

Текст: Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА.
Фото: Анна АРАХАМИЯ. Видео: Фәнис САДЫЙКОВ.
Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.






ЛАТЫЙФА ОНЫКЛАРЫ



Раилә
ХӘЯЛИЕВА

Алар үзләрен зур горурлык белән «Латыйфа оныклары» дип атап йөртә. «Гадәттә, кадерле кешеләрен соңгы юлга озатканда, ашын уздырганда гына бөтен нәселе җыела. Ә без бу гадәтне үзгәртергә булдык. Нигә соң әле Латыйфа дәү әнине бергә җыелып күңелле итеп искә алмаска?!» – диләр.











Фотолар: Рушан Хәялиев һәм гаилә архивыннан

Латыйфа әби

Латыйфа Нигъмәтҗанова Яшел Үзән районы Муллаиле авылының затлы нәсел кызы була. 19 яшендә Борындыкта яшәүче Гарифуллага хатын булып килә ул. Бу авылга беренче тапкыр аяк басканда Гарифулланың инде бер тапкыр өйләнгән булуын да, ике баласы белән тол калуын да белми әле. Чаршау артында килен төшкән хөрмәткә май чыжлый, нидер пешә, булышырга кергән күрше хатыннар чыш-пыш килә. Әниләрен югалту ачысыннан өзгәләнгән ике кечкенә балага: «Хәзер әниегез кайта», – дип әйтеп куялар. Латыйфа өйгә кереп, бишмәтен элгечкә элүгә, әллә каян гына теге ике бала йөгереп чыгып: «Әни кайткан!» – дип, Латыйфага таба атыла… Чаршау артындагы хатыннар балаларның юлларына аркылы төшеп, кире алып кереп китәләр китүен дә, әмма ул арада Латыйфа барысын да аңлап өлгерә… Ә Гарифулла үзенең тормыш хәлен бераз соңрак аңлатырмын дип уйлаган була, күрәмсең. Яшь-яшь кызның ике балалы иргә килүенә дә шикләнгәндер. Бу хәлдән соң кыз: «Әйдә, Гарифулла, утырып бер дога кылыйк та, аннан кайтыр юлга кузгалырмын, тормышны болай ялганнан башлап булмый», – ди. Киенеп, ат чанасына таба атлый. Ул да булмый, артыннан теге ике бала йөгереп чыгып: «Яңа әни, син дә безне калдырып китмә!» – дип, аның аягына сарыла… Күңеле түзми, балаларны кочаклап елый да, язмышым шулдыр, дип, йортта кала кыз.

Озакламый Гарифулла белән Латыйфаның Мөнирә исемле кызлары туа. Аннан тагын дүрт малай дөньяга килә. Күп балалы гаилә гомер буе дус-тату яши. Уллары өйләнгәч, төп йорт матчасына өч бишек элеп, өч киленнең бергә торган чаклары да була әле. Алар һәрвакыт бер йодрык булып яшиләр. Өйләре дә бер урамда бер-бер артлы урнашкан. «Без мәктәптә укыганда һәр класс саен апабыз, абыебыз яки туганнан туганыбыз укый иде. Бер-беребезне якын итеп, ярдәмләшеп, тату үстек», – дип искә ала ул чакларны Латыйфаның бер оныгы Чулпан Камалиева.

Уллар, киленнәр, оныклар, туганнар… Нәселне бер йодрык итеп туплап торучы – зирәк акыллы Латыйфа дәү әни була. Киленнәр дә аңа елыша, балалар да аның итәгендә үсә. Ул акрын гына тормыш җаен җайлый, нәсел ныклыгын кайгырта. Алай гына да түгел, авылдашлары да төрле йомыш белән аңа килә. Кемдер сәдака китерә, кемгәдер күз тигән… Үзе дини, үзе тормышчан була ул. Балаларны туган җиргә, табигатькә гашыйк итеп үстерә, Борындык үзәннәреннән какы, кузгалак җыя, зирәк теле белән ут уйната.

Бүген инде Латыйфа әбинең оныклары – үзләре дәү әти, дәү әни. Бишенче буын балалар йөгерешеп йөри, кайсының теле ачыла, кайсы әнә яңа тәпи киткән. Латыйфаның онык-оныкчыклары бүген 150 гә тула! Алар ел саен: «Ул-кызларыбыз берберсен күреп, белеп үссен», – дип, гаилә бәйрәмен уздыра. Һәрберсе җырга-моңга сәләтле, шуңа да, җыелып туган авылларында концерт куялар, Рамазан аенда авыз ачтыралар.

Киленем – күрше кызы

Без бүген Латыйфа әбинең бер оныкчыгы – Кайбыч районы Борындык авылында яшәүче Энҗе һәм аның тормыш иптәше Ранил гаиләсендә кунакта. Бу гаиләне күптән беләм. Һәм бик яратам! Дуслыктатулык, ихтирам һәм чын гаилә җылысы яши аларда. Әнә бит Энҗенең әти-әниләре – кода-кодагыйлар да килгән. «Без һәрвакыт бергә, шушы составта инде», – дип көлешәләр үзләре. (Шаяру, көлешү бу гаилә әгъзаларына хас гадәт!) Энҗеләр кайнана-кайната белән бергә яшиләр, өч бала тәрбияләп үстерәләр – Рәфинә, Рөстәм, Радель.

– Бер елны, мәктәптә укыганда, Казанга Республика көненә Кайбычтан делегация булып бардык. Мин татар кызы киеменнән Президентны чәкчәк белән каршы алдым, ә Ранил татар егете киеменнән зур башак бәйләмен күтәреп торды. Шул чарага бару якынайтты бугай инде безне, җиде ел очрашканнан соң, туй иттек. Татар кызы белән татар егете кушылып, чын татар гаиләсен төзедек!

// Энҗе: «Гаиләдә бары тик татарча гына аралашабыз! Чит телдәге сүзләрне кушып сөйләүгә дә каршы мин. Шәһәргә киткәч авыр була, рус телендә сөйләшсен, диючеләр белән дә килешмим. Безнең буын да татарча сөйләшеп үсте, шәһәрдә югалмадык бит әле, югары белем дә алдык! Тел – гаиләдә сакланырга тиеш, әти-әни баласын татарча фикер йөртергә өйрәтергә бурычлы дип саныйм».

– Энҗе – безнең урам кызы ул, күз алдында үсте, – ди Мәдинә апа. – Киленем дип тә кабул итә алмыйм, гел үз кызым кебек, бик тату яшибез, Аллага шөкер. Бала тудыру йортында да әнисе – хәзер инде кодагыем белән бергә яттык. Ул Энҗене тапты, мин – икенче улым Илнарны. Язмышы шулай булгандыр инде, 16 яшендә Илнар улымны бөтенләйгә югалттык…

– Безнең якта гореф-гадәтләрне төгәл саклыйлар. Шулай да кияүгә чыгар алдыннан килен кеше үтәргә тиешле гадәтләрне китаплардан укып, барлап куйдым. Һәм, беләсезме, нинди кызык әйбергә тап булдым? Киленне капка төбеннән балмай, икмәк каптырып, мендәргә бастырып каршы алулары юкка гына түгел икән бит. Мендәргә басып узганнан соң, килен буласы кеше аны алып – кагып, үзе белән өйгә алып керергә тиеш. Мендәр – киленнең тормышка җайлашуын, пөхтәлеген, эш мәлен сынау өчен куела икән. Шулай иттем дә! – ди Энҗе кайнанасына елмаеп. – Белмәгән эшемне шыпырт кына, үзенә сиздермичә Мәдинә әнидән өйрәнәм. Бик сабыр ул безнең, гаилә җанлы. Аерым утырып чәй эчкәнебез дә юк. Табынга һәрвакыт гаилә белән бергә утырабыз. Балалар да шуны күреп, йорт җанлы булып үсә. Иң әйбәт тәрбия – үзең үрнәк күрсәтү дип уйлыйм.

– Башта ук Энҗегә авылда каласыбызны әйтеп куйдым, – дип сүзгә кушыла Ранил. – Ул каршы килмәде. Бердәнбер малай булып калгач, әти-әнине ташлап китә алмый идем инде... Авылны яратам! Табигатен, балыкка йөрүләрне... Хәзер бит авыл тормышы да шәһәрнекеннән ким түгел!

Ранил Кайбыч хастаханәсенең «Ашыгыч ярдәм» бүлегендә фельдшер булып эшли. «Узган ел зур сынау булды, улымны һәр көнне күзенә карап каршы ала идем: авыру йоктырмаганмы, хәле бер көеме... Авырга туры килде аларга. Җәйге челләләрдә дә махсус формалар киеп эшләделәр. Бөтен гаилә белән көч биреп, аңа таяныч булырга тырыштык», – ди әни кеше.

Энҗе белеме буенча музей хезмәткәре. Олы Кайбыч авылындагы Галия Кайбицкая исемендәге музей директоры булып эшли, аннан соң «Кайбыч ягы» музеена күчә. Латыйфа әбисенең чалымнары да сизелә үзендә: чая телле, матур җырлый, бик кыю ул. Ә иң мөһиме – нәсел җепләрен сакларга тырыша, туганнар бердәмлеген кайгыртып яши!

Бердәм өйдә бәрәкәт була!

Заманча татар гаиләсенең ныклыгы – нәсел көчендә, әби-бабай нәсыйхәтенә нигезләнгән булуында. Миңгалиевлар гаиләсе ике яктан да бәхетле!

Ранилнең әти-әнисе – туган җиргә тугры калган авыл хезмәтчәннәре. Мәдинә апалар мәктәпне тәмамлаганнан соң, классташлары белән бер атнага Волгоград шәһәренә сәяхәткә барып кайталар да, класслары белән колхозда калалар. 38 ел буе терлекчелек тармагында эшли ул. Бүгенге көндә «Татарстан Республикасының атказанган терлекчесе» исеменә лаек булган. Равил абый белән дә колхоз эшендә танышалар, яшьлектә матур гаилә коралар.

– Безнең вакытта туйлар өчәр көн уза иде. Беренче көнне яшьләр белән кызыл туй була, икенче көнне парлылар килә, өченче көнне кода-кодагыйларны җыясың. Бер атнадан кыз ягы туй ясый. Ул арада яшьләрне тугантумача чәйгә ала. Ике нәсел шулай дуслаша, туганлаша. Әй кызык вакытлар бар иде! – дип, яшь чакларын искә ала Мәдинә апа. Ул әле һаман да кояш белән бергә эшкә китә, тормыш иптәшен озатып калган Равил абыйны исә ишегалдында маллары, атлары көтә. Терлек-туарны күп асрыйлар. Оныклар да хезмәт тәрбиясен күреп үссен дип тырышалар.

Энҗенең әтисе Рамил абый төп Борындыкныкы. Рәмзия апаны Арчага – дус егетенең туена шаһит булып баргач күреп ала ул. «Егете юк!» – дип тә кисәтеп куйгач, тәвәккәлли... Ничек итсә итә, унбер ел шәһәрдә эшләгән, Казан шәһәре Советы депутаты булган Рәмзияне ике ай эчендә авылга алып кайта! Рәмзия апаның әтисе: «Кызым авылда яшәсә, авызы тулы икмәк булыр!» – дип, яшьләргә үзенең фатихасын бирә.

Рамил абый яшьтән үк җыр-моңга гашыйк, оста гармунчы. (Колхозда эшләсәләр дә, әтисе Габделрәшит – тальянчы, әнисе Рауза җырчы була. Заманында авылдагы бер мәҗлес тә, бәйрәм дә алардан башка үтми.) Ә Рәмзия апа – читекчеләр нәселеннән! Дәү әтисе Хәбибулла Арча аяк киеме фабрикасында читеккә тегелә торган бизәкләрне иягенә пычак терәп кисә торган оста кисүче булып саналган. «Безгә дә хезмәт дәресләрендә чигүләрне, чүәк ясый торган бизәкләрне ясарга өйрәтәләр иде. Тотынсам, аларны әле дә эшли беләм», – ди Рәмзия апа.

Нәсел тальяны

Рамил абый сөйли: «Миңа 7–8 яшьләр булгандыр, әти белән нидер эшләп йөрибез. Шунда үзе дә гармунчы булган бер абзый бер төргәк тотып килеп керде дә:


– Бу – сезнең нәсел тальяны, – диде.

– Әти төргәкне сүтеп җибәрде. Аннан пычак белән юнып эшләнгән һәм гармун телләре куелган ике агач кисәге килеп чыкты. Тальян кисәкләренең бик борынгы икәне күренә иде.

– Күпмегә бирәсең? – диде әти.

– 25 сумга.

– 25 сум?! Ике агач кисәге өченме? Күзем маңгайга менде. Ә әти сатып алды ул тальян кисәкләрен. Гармун төзәтүчене бик озак эзләгәннән соң гына таптык. Казанның Фучик урамында яшәүче бер бабай алты ай ясады аны. Һәр теле кулдан эшләнгәнгәме икән, ул тальяннан бөтенләй



үзгә моң чыга. Башка гармуннар, хромкалар да аңа кушылып уйный алмый. Соңрак белештек, 1814 елгы тальян булырга тиеш ул. Гарифулла бабайның туганы Хикмәтулладан калган. Тальян – төп йортыбызның бизәге, гаиләбезнең ядкаре. Әти төсе итеп саклыйбыз. Бер генә бәйрәм дә шул тальяннан башка узмый. Киләсе хуҗасы – Энҗенең улы Рөстәм булыр дип уйлап куйдык. Тизрәк үсеп җитеп, уйнарга гына өйрәнсен!»

Рамил абый җилкенеп тальянын уйнап җибәрә. Их, җыр-моңны юлдаш итеп, матур яши белә бу гаилә! Әнә бит 2017 елда гаилә традицияләрен барлау максатыннан оештырылган «Төп йорт» фестивалендә чыгыш ясау өчен Энҗе белән әтисе инде онытылып баручы «Ярмәк вагы» биюен өйрәнгәннәр! Фестивальдә дүрт буын – кечкенә оныктан башлап, тәсбих тартучы дәү әниләре Раузага кадәр (бүгенге көндә инде вафат) катнашкан ул чакта. Биюне әле бүген дә онытмыйлар. Юбилейләр, бәйрәмнәрдә гел бии аны кода. Әтисенә Энҗе кушыла, уртага Рәфинә чыга... Безгә дә биеп күрсәттеләр. Һай, гаҗә-ә-әп!!!

Туган җир һәм туган тел хакында

Икенче елга мәктәпкә барырга әзерләнеп йөргән Рөстәмнең башында дәү әтисенеке кебек күркәм түбәтәй, өченче класста укучы Рәфинә – калфактан, бер яшен тутырган Радельгә дә кечкенә түбәтәй тапканнар!

– Авыл балаларының да русча сөйләшүе гадәти хәлгә әйләнеп бара. Тик мин бу хәл белән килешә алмыйм! – ди Энҗе. – Туган телгә кагылсалар, ярсып чыгам. Рәфинә белән татарча шигырьләр укыйбыз, ул аларны төрле чараларда сөйли, бәйгеләрдә катнаша. Ягымлы итеп туган телдә сөйләшүен укытучысы да хуплый. Гаиләдә бары тик татарча гына аралашабыз! Чит телдәге сүзләрне кушып сөйләүгә дә каршы мин. Шәһәргә киткәч авыр була, рус телендә сөйләшсен, диючеләр белән дә килешмим. Безнең буын да татарча сөйләшеп үсте, шәһәрдә югалмадык бит әле, югары белем дә алдык! Тел гаиләдә сакланырга тиеш, әти-әни баласын татарча фикер йөртергә өйрәтергә бурычлы дип саныйм.

Тагын бер мәсьәлә бар: туган җирен яратсын өчен, балага аның ямен, матурлыгын күрсәтергә кирәк. Кичләрен, бераз эш беткәч, берәр кая чыгып керергә яратабыз. Йә күрше авылдагы чишмәгә барабыз, йә Чулпан тавына менәбез. Ә безнең шомырт урманы! Урман чәчәк аткан вакытта авылга шомырт чәчәге исе тарала. Аның тәмлелеге, аның хуш исе! Кич белән чыгып кат-кат иснәп керәм мин аны. Җиләккә, мәтрүшкәгә йөрибез. Безнең авыл янында Зөя елгасы ага. Язын авылны су баса. Суның алгы тәрәзәдән кереп, арткы тәрәзәдән агып чыккан чаклар да булган. Борындык халкы бу күренешкә ияләшкән, җайлашкан инде ул. Су тулы урамнардан көймәгә утырып, гармун уйнап йөрүләре дә гадәти хәл булган элек...

Гаилә, авыл тарихын бөртекләп җыеп саклый Миңгалиевлар. Әнә диварда үзләре ясаган гаилә гербы эленеп тора. Ранилнең 30 яшьлек юбилеена балалар белән бергәләп ясап бүләк иткәннәр аны. Латыйфа әбинең тагын бер тынгысыз оныгы – Олы Кайбыч авылында яшәүче Рушания апа Лотфуллина төзегән, Гөлшат апалары ярдәме белән ике метрлы рулонга бастырылган шәҗәрә агачы да бар аларның. Ун буын кергән анда! Киштәдәге фотолардан җәйгә кунакка кайткан балалар арасында кечкенә Латыйфа елмая – Энҗенең сеңлесенең кызы ул, исемен ерак әбиләре хөрмәтенә кушканнар...

Без Энҗе белән сөйләшкән арада кодагыйлар аш бүлмәсенә күчкән икән. Көлешә-көлешә чәй эчәләр. Кайбыч районында һәр авылның үз кушаматы булганын ишеткәнем бар иде. Борындыкларны «Балан катыгы», дип атыйлар. Чөнки Борындыкның уңган-булган хуҗабикәләре генә балан катыгы ясый белә!

– Юка, балан катыгы, балан бәлешен пешерәбез инде без, – ди Мәдинә апа. – Электән калган гадәт шундый. Балан өлгергәч, тәлгәшләп җыеп кайтасың да, мунча себеркесе кебек бәйләп элеп куясың. Салкыннар төшкәч, баланны тәлгәшеннән коюы җиңел – уып кына аласың. Баланны



Нәселне бер йодрык итеп туплап торучы Латыйфа дәү әни шушы була инде.

әйбәтләп юып элеккеге чуеннарга тутырабыз, аз гына су өстибез һәм мичкә төчетергә куябыз. Балан куе кызыл төскә кергәч, мичтән алабыз да, арыш оны белән бутыйбыз, аз гына шикәр комы салабыз һәм пыяла банкаларга тутырып, салкынча урында саклыйбыз. Менә шул балан катыгы була инде... Балан бәлешен шуның белән пешерәләр бездә. Без яшь чакта әле тагын Борындыклар кипкән алма онын тарттырырга йөриләр иде...

– Кодагый, мин юканы, табынга юка астына куеп чыгара торган мич кабартмасын монда килен булып төшкәч кенә татып карадым...

Рәфинә оныкк, бирелеп китеп, дәү әниләре сөйләшкәнне тыңлый, аларның сүзләрен сеңдерә. Радель әтисе кочагында татлы йокыга талды, Рөстәм дәү әтисенең кунакка килгәндә дә үзеннән калдырмаган кыңгыраулы яшел гармуны тирәсендә бөтерелә...

Ә мин яңадан Энҗенең сүзләрен искә төшерәм. «Гаилә ул – җылы учак! Гаилә никадәр нык булса, аннан килгән җылылык та шулкадәр көчле була. Әби-бабай, әти-әни – йортның тоткасы, ә балалар, оныклар – аның көзгесе! Безнең гаиләнең асылын бер матур мәкаль ачып бирә: «Тату туганнар – таштан койма корганнар».

Латыйфа оныклары менә шулай яши.



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Видео: Рушан Хәялиев.

«БУ – МИНЕМ ГИМНАЗИЯМ!»





Түбән Кама шәһәренең Бакый Урманче исемендәге 2 нче гимназиясе 825 балага исәпләп төзелгән. Бүген исә биредә 1155 бала белем ала. Югыйсә 1992 елның 7 октябрендә ачылган бу бина искитмәле заманча ремонты, яңа җиһазлары белән дә мактана алмый... Шартлар начар булмаса да (сыйныф бүлмәләре якты һәм җылы, кыршылган стеналар биредә, гомумән, юк), бу җәһәттән, бәлки, яңа төзелгән мәктәпләр белән ярыша да алмыйдыр ул. Ләкин аны башкалардан аерып тора торган бер үзенчәлеге бар, ул – милли гимназия! Монда мохит үк башка.

Милли гимназия дигәч, кемдәдер каршылыклы фикер туарга мөмкин. Нигә яшерергә, белемне рус телендә алса, балам күбрәккә ирешер, дип уйлаучылар да бар бит. Кемнедер нәрсәгәдер инандырганчы, әлеге уку йорты белән якыннан танышыйк әле. Нәтиҗәләрне соңыннан үзегез ясарсыз.

Шәһәрдәге иң зур мәктәп. 2 нче татар гимназиясен шулай дип тә атарга була. Мәктәпнең тулы мәйданы гына да 1 мең квадрат метрдан артык. Шунда ук дүрт остаханә, өч спорт залы, ике бассейн, ашханә... Боларга өстәп алма бакчасы, теплицалары... Айгөл Нильсон кызы ГАЯЗОВА гимназия белән 2016 елдан җитәкчелек итә. Моннан күп еллар элек кулына Казан дәүләт университетының татар филологиясе факультетын тәмамлавы турында диплом тотып, нәкъ шушы мәктәпкә беренче тапкыр эшкә килә ул. Татар теле һәм әдәбияты укытучысын укучылары да, коллектив та бик тиз үз итә. Ләкин яшь әнигә башка мәктәпкә – өйләренә якынрак булганына күчәргә туры килә ул вакытта. Тагын егерме елдан кабат шушы гимназиягә эшкә чакыргач, дулкынланып та, каушап та кала. Бу юлы инде аңа меңнән артык укучы, ике меңгә якын әти-әни, йөз егерме кешедән гыйбарәт коллектив белән җитәкчелек итү бурычы йөкләнә. Каушап калуына аптырарлык та түгел.

Эшне бинаны матурлаудан башлый ул. Татар гимназиясе башка мәктәпләрдән һич кайтыш булырга тиеш түгел, дип саный директор ханым. Моның кадәр зур бинаны капиталь төзекләндерү өчен, әлбәттә, ярдәмнең зуррагы кирәк. Киләчәктә ул максатка ирешәселәренә дә ышана алар, әлегә исә холлдагы яшел оазислар, үз куллары белән ясалган уңайлы почмаклар, коридордагы китап киштәләре, ачык төсләргә буялган диварлар – мәктәпне ямьле һәм уңайлы итә.

Бер елда – 13 медалист. Узган ел гимназияне әнә шуның кадәр укучы медаль белән тәмамлаган. Айгөл Нильсоновна быел да әлеге күрсәткечтән түбән төшмәсләренә ышана. Бу факт үзе үк күпне сөйли түгелме? Димәк, иң көчле педагоглар коллективы эшли монда. Шулай булмаса, 2017 нче уку елыннан башлап, һәр елны гимназия олимпиада нәтиҗәләре буенча Түбән Кама муниципаль районында 1–2 нче урында, ә республика күләмендә иң яхшы 30 мәктәп исемлегендә торыр идеме?! Юктан бар



Лилия
ГӘРӘЕВА

Баласын беренче класска алып килгәндә әти-әни мәктәпне нинди критерийлар буенча сайлый? Беренче урынга яхшы ремонт, шәп җиһазларны, уңайлы шартларны куямы? Әллә укытучыларның профессиональлегенә һәм өстәмә белем бирүче дәресләр исемлегенә мөһимрәкме? Бәлки, ул миллилеккә, традицияләргә өстенлек бирәдер?













Фото: Анна Арахамия

булган күрсәткеч түгел, педагогларның тынгысыз хезмәте, үз предметына карата балада кызыксыну уята белү осталыгы салынган бу җиңүләргә.

Балаларга 74 педагог белем бирә. Аларның яртысыннан күбесе – югары категорияле, икесе – Татарстанның атказанган укытучысы исемен йөртүчеләр. Ләкин Айгөл ханым кемнедер аерып күрсәтү ягында түгел. «Берсен әйтеп, берсен калдырудан куркам. Бездә үз эшен, ә иң мөһиме – балаларны яратучы педагоглар эшли, – ди ул. – Балаларны яратмасаң, мәктәптә озак эшләп булмый».

Без аның белән килешәбез. Укучылар белән укытучылар арасындагы дуслык һәм ышаныч хәтта безгә – мәктәпкә бер генә көнгә килгән кунакларга да сизелерлек. «Абый-апа», дип эндәшүләрендә, яраткан укытучысы белән тизрәк яңалыкларын бүлешергә ашыгуларында, якын итеп киңәш сорауларында чагыла ул.

– Бездә «биш»ле алу өчен бик тырышырга кирәк, – ди Айгөл ханым. – 4,50 балл ул әле «дүрт»лек кенә дигән сүз. Ә балаларыбыз, чынлап та, тырышлар. «Өч»леләр журналга сирәк куела. Начар билге куеп, баланың укуга булган теләген сүндерү ягында түгел без.

Бер олимпиададан – 10 җиңүче! Моңа ышануы кыен, ләкин бу чын. Быел физик тәрбиядән республика күләмендә узган олимпиадада катнашкан ун укучының унысы да бер үк көнне призер булып кайткан. Инде Россия күләмендә узачак олимпиадага әзерләнәләр. Без килгән көнне дә укучылар Казанга – белемнәрен сынарга барырга тиешләр иде. Үз эшенә бирелгән педагоглар дибез икән, нәкъ менә Илдар Булатов кебекләрне мисалга китерергә кирәктер.

– Мәктәпкә иң беренче килеп, иң соңыннан китүче кеше ул, – ди Айгөл ханым аның турында. – Әле ишегалдындагы спорт мәйданчыгында, яңгырлы көнне спорт залында алар. Мәш киләләр. Илдар Фәритовичның балалар белән олимпиада, ярыш, спартакиадалардан кайтып кергәне юк. Узган ел ГТО фестивалендә республикада беренче урынны яулап Анапага бардык. Төрле номинацияләрдә откан медальләр саны белән Россия буенча 8 нче урынны алдык. Гимназия укучысын баскетбол буенча Казанга олимпия резервы мәктәбенә укырга чакырганнар икән – бу да укытучының күрсәткече түгелме?!.

Андый ярышларга ник бу кадәр игътибар, дип аптырагансыздыр? Олимпиадада яулаган җиңүләр имтихан нәтиҗәләренә өстәмә баллар өсти. Югары уку йортларына укырга кергәндә кайчак бер балл да роль уйнарга мөмкин. Менә шуның өчен дә бар мөмкинлекне файдаланып калырга тырышалар гимназиядә. Директор әйтмешли, колакларыннан тартып үстерәләр, бары нәтиҗәсе генә булсын.

«Иң яраткан дәресебез – хезмәт!» – остаханәдә выжылдатып нәрсәләрдер ясаучы егетләр шулай ди. Технология дәресләре бик мавыктыргыч уза бирәдә. Марат



Айгөл ГАЯЗОВА, Түбән Кама шәһәренең Бакый Урманче исемендәге 2 нче гимназиясе директоры:
«Зур коллектив, җәмәгатьчелекнең игътибар үзәгендә булган милли гимназия белән идарә итү җиңел генә түгел. Авыр чакларда миңа яраткан язучым Фәнис Яруллинның сүзләре канат куя. Бер шигырендә ак юл ярып күктә очкан самолет образын китерә ул. Бу самолет аерым мәгънәгә ия. Ак юл – яхшы эш, ә һавадагы самолет – биеклек символы. Самолет гел очышта булганда гына юлын дәвам итә ала. Мин дә үзебезнең гимназиябезне шул самолетка тиңлим. Ниятебез – яхшы эш белән биеклеккә күтәрелү».





Марат МОРЗАХАНОВ, технология укытучысы: «3D принтер бездә икәү. Берсен үзебез укучылар белән ясадык, икенчесен сатып алдык. Балаларга модельләштерү, проект ясау, программалаштыру белән шөгыльләнү бик ошый. Дәрестә заманча һәм традицион технологияләрне кулланабыз. Аларның икесе дә кирәк дип саныйм».

Марат ФӘЙРУШИН, җырчы: «Гимназиям күп нәрсәгә өйрәтте. Беренчедән, саф татарча дөрес итеп – әдәби телдә сөйләшергә; икенчедән – дисциплинага. Иҗат ягыннан килгәндә, гимназиябездә бик яхшы бию ансамбльләре эшли. Мин җиде ел бию белән шөгыльләндем. Андый гимназияләр күбрәк булсын иде».

Азат НӘҖМЕТДИНОВ, «Кыстыбый» кафелар челтәре директоры: «Белем һәм мохит – тормыштагы ике төп якорьлар. Белем бирү ягыннан 2 нче гимназия Түбән Камада иң көчле мәктәпләрдән санала. Математик фикер йөртмәсәм дә, математика классында укыдым. Чиреккә «өчле»ләр дә чыккалады. Институтта укыганда гына гимназиянең никадәр төпле база биргәнен аңладым. Кешенең нинди мохиттә үсүе дә бик мөһим. Ул киләчәктә кайсы юнәлештә барасыңны билгели. Мәктәпне күптән тәмамласак та, күңелдә җылы хис булып әле дә саклана».



Айнур ГАЛИЕВ, тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы: «Укучыларны кызыксындыру өчен дәрес сөйләү генә җитми, төрле чаралар, кинофильмнар да кулланабыз. Тарих һәм җәмгыять белеме дәресләре баланың дөньяны күзаллавын формалаштыра. Җәмгыять белеме дәресләрендә тормышта булган ситуацияләр турында сөйләшеп, аларны анализларга тырышабыз. Күп нәрсә үзгәрә, бер генә әйбер үзгәрә алмый: укытучы үз эшен һәм балаларны яратмаса, аның урыны мәктәптә түгел».



Илдар БУЛАТОВ, физик тәрбия укытучысы: «Бала организмы бары хәрәкәттә генә тиешенчә үсә һәм камилләшә ала. Безнең укучыларыбыз физкультура дәресләренә теләп йөри. Киләчәкләрен спортта күреп, шул юнәлештә югары белем алган егет-кызларыбызның да булуы минем өчен горурлык».

Морзаханов җитәкчелегендә ниләр генә ясамыйлар. Әйтик – тузан суырткыч. Гадине түгел, ә сәнәгатьтә куллана торганны – көчлене, икешәр фильтрлыны! Бөтенроссия олимпиадасы призеры Илшат исә кулланылган пластикны эшкәртә торган шредер уйлап тапкан. 10 нчы сыйныф егете Нияз әнә үзе ясаган электрон скрипканы кулына ала. Дөрес, әлегә ул аларны ясый гына белә, уйнарга исә соңрак өйрәнәчәк. 3D принтер, чүлмәкче түгәрәге (гончарный круг), тимер һәм агач эшкәртү станоклары – бу остаханәдә булмаган әйбер юк бугай... Айгөл Нильсоновнаның эш өстәлен бизәгән үгез сынын да укучылары шундый принтерда үзләре иҗат иткән.

– Киләчәктә кем булырга хыялланасыз соң? – дип кызыксынабыз бу уңган егетләрдән.

Инженерлар, технологлар булырга телиләр икән. Физика белән дә мавыгалар. Егет кеше кулына кадак,

чүкеч кенә булса да тота белергә тиеш. Бу балалар мәктәп партасыннан ук җитмеш төрле һөнәргә өйрәнеп чыгачак. Марат Әхмәтович кебек укытучыларда укып, башкача булырга мөмкин дә түгел.

«Яшь чик сакчылары». Мәктәпнең взводы әнә шундый горур исем йөртә. Мондый хәрәкәтне без бары Түбән Камада гына күрдек. Укучы егетләр башлангыч сыйныфтан ук хәрби әзерлек уза. Иминият нигезләре фәнен укытучы Дамир Корбанов әйтүенчә, мондый әзерлек армиягә баргач бик ярдәм итәчәк аларга. 11 нче сыйныф укучысы Рамил Сәлимгәрәев строевойга беренче тапкыр җиденчедә укыганда баскан. Хәзер взвод белән үзе командалык итә. «Тәртипкә һәм дисциплинага өйрәнәбез. Армиядә кирәк булачак чыныгу алабыз. Автоматларны инде күзне йомып та сүтеп җыябыз. Телəге һәм сәламәтлеге булган егетләрнең берсен дә кире бормый Дамир Наилевич», – ди ул. Гимназия взводы дүртенче ел рәттән шәһәрдә узучы «Парад алымнары һәм җыр» бәйгесендә беренчелекне бирми.

Энәдән-җептән төшкән хәрби киемнәргә киенгән егетләр дөп-дөп басып, строевой адым белән каршыбыздан җырлап уза. Ай-һай, килештерәләр, чын солдатлар диярсең. Бәлки, менә шушы патриотик тәрбиянең дә нәтиҗәседер – гимназияне тәмамлаучылар арасында хәрби академияләргә кереп укучылар да бар. Берсе хәтта хәрби-ракета академиясен сайлаган. Барысы да түләүсез бүлекләрдә укый! Андый уку йортларына керүнең авырлыгын һәм бюджет урыннарының чикләнгәнлеген исәпкә алсаң, гимназия биргән белемнең никадәр тирәнлеген чамалавы кыен түгел.

Биологлар, физиклар, социологлар. Киләчәктә кем булырга теләүләренә карап, югары сыйныфларда укучыларның профильле белем сайлау мөмкинлеге бар. Химия-биология юнәлешеме ул, социаль-икътисадныкымы, математика-физикамы – баланың теләгеннән һәм сәләтеннән тора. Тугызынчыны тәмамлаган укучыларның 70 проценты гимназиядә кала икән. «Балаларны унга-унбергә алып калып, без үз өстебезгә гаять зур җаваплылык та алабыз. Димәк, без аларга югары уку йортларына керә алырлык әзерлек һәм белем бирергә тиеш. Укучыларыбызның институтларга бюджет урыннарына кереп укуы безнең өчен дә горурлык», – ди Айгөл ханым.

Гимназия үзе урнашкан микрорайонга гына түгел, бөтен шәһәргә, хәтта районга хезмәт итә, хәтта якын-тирә авыллардан да килеп укыйлар.

– Бездә балаларга да, әти-әниләргә дә бик уңай, – дип, моның серен ача директор ханым. – Беренчедән, мохит. Чын татар мохитенең атмосферасын бары шунда эләккәч кенә аңлыйсың. Яшермим, безгә татарча белмәүче балаларны да алып киләләр. «Татарча белмисең», – дип, кире борабыз икән, без бит тагын бер татар баласын югалтабыз. Ә бездә ул татар телен азмы-күпме өйрәнәчәк, халкыбызның мәдәниятен, тормышын күңеленә сеңдерәчәк. Җырлар, әкиятләр, биюләр аша булса да аңа барыбер йогачак алар.

Алмаз, Айсылу һәм Ралифка ияреп, гимназия буйлап экскурсиягә кузгалабыз. Бер сәгать эчендә генә барысын күреп тә булмас. Алай да... Биология дәресендә укучыларның миләүшә чәчәкләре утыртканнарын (узган ел Бөек Җиңүнең 75 еллыгына 75 төп миләүшәдән композиция әзерләгәннәр), физика кабинетында югары класс укучыларының кечерәкләрне физика фәне белән таныштыруларын, башлангычларның вулкан аттыруларын тамаша кылабыз. Юл уңае спорт залында каратэ дәресен карап чыгабыз (гимназия укучылары өчен ул дәресләр бушлай!). Сәләт клубы белән танышабыз. Ике музейга сугылабыз. Туган якны өйрәнү – этнография музеенда 320 экспонат арасында Гаяз Исхакыйның әтисе 1907 елда хаҗдан алып кайткан таш комган белән агач савыт-саба да бар. Татар гимназиясендә саклансын дип, туганнары бүләк иткән. Дан ордены кавалеры Рифкать Гайнуллин мемориаль музеенда гимназия укучыларының «Үлем үзәне»ннән үзләре табып кайткан сугыш ядкарьләрен барлыйбыз...

– Без XXI гасыр баласын укытабыз. Бу балалар – үзгә. Алар инде болай да күпне белә, һәр яктан мәгълүматлары җитәрлек. Безнең бурыч – аларның сәләтләрен күреп, шуны мөмкин кадәр үстерү. Сәләтсез балалар юк, аны вакытында күреп, үстерә белүче укытучылар гына кирәк, диләр. Кайсы мәктәпне алсак та, төп проблема – кадрлар. Ә бездә һәр фәннән укытучылар бар. Шушы гимназияне тәмамлап, яшьләр үзебезгә үк эшкә кайта, – ди Айгөл ханым. – Университетта укучы кызыбыз каникулда балаларга кытай телен өйрәтә башларга теләвен белдерде. Бүген менә беренче дәресләре булырга тиеш. Соңыннан да ул курсларны онлайн форматта булса да дәвам итүләрен телим.

Янәшәдә – сәнгать мәктәбе. Димәк, балаларга музыка, сынлы сәнгать, хореография, театр сәнгате буенча өстәмә белем алу мөмкинлеге бар. «Бездә әти-әниләр өчен дә бик уңайлы», – дигәндә, Айгөл ханым моны да күздә тота. Дәрестән соң баланы шәһәрнең башка читендәге музыка мәктәбенә илтергә кирәкми – барысы да бер бинада. Мәктәпкә иртән килгән бала кичкә кадәр нәрсә беләндер мәшгуль, гел күзәтү астында.

Сәнгать мәктәбендә укуның балаларга йогынтысы зур – үзләрен иркен тоталар, каушамыйлар, активлар.

Сәхнәдә затлы костюмнардан ут өертеп татар егет-кызлары бии! Айгөл Нильсоновна пышылдап өлгерә: «Костюмерларыбыз да үзебездә!»

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Ирек Наскаев җитәкчелегендәге бу бию коллективы ел да Федераль Сабантуйны ачып җибәрүдә катнаша икән. Кайларда гына булмаганнар – Әстерхан, Владивосток, Чиләбе, Төмәндә...

...Гимназиянең үз алма бакчасы бар. Тиздән шау чәчәккә күмеләчәк ул. «Узган ел коронавирус аркасында балалар мәктәпкә килә алмады. Алмагачлар чәчәк аткач, видеога төшереп, укучыларыма җибәрдем, – ди Айгөл ханым. – Исләрендә калсын. Гимназия күңелләрендә гел шулай аклык булып саклансын. Кая гына барсалар да: «Бу – минем гимназиям!» – дип, горурланып әйтсеннәр».

Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай премиясе лауреаты, Россия Федерациясе Дәүләт премиясе лауреаты Ренат Харис укучыларыбыз өчен, беренче чиратта, үзенчәлекле шагыйрь, популяр җырлар авторы буларак таныш, әлбәттә. Шулай ук аның музыкаль әсәрләр өчен либреттолар язуын да («Шагыйрь мәхәббәте», «Сөембикә» опералары, «Кыйссаи Йосыф» балеты, «Алтын Казан» мюзиклы), рәссам-график булуын да («Шигырь язган каләм белән...» китап-альбомындагы картиналарны сокланып карыйсың!), сәясәтче, күренекле җәмәгать эшлеклесе икәнен дә яхшы беләләр.
Бу көннәрдә Ренат Харис 80 яшьлек юбилеен билгеләп үтә. Шагыйрьне гомер бәйрәме белән котлыйбыз! Иҗат уңышлары телибез!



Ренат ХАРИС

КӨМЕШ НУРЛАР ҖЫЯМ...

Хатын-кыз кодрәте

Әй, хатын-кыз, синең кодрәтеңә
җитә алмый Җирдә һичнәрсә...
Суфилар да гөнаһ иясенә
әйләнәләр, әгәр тибәрсәң....

Җир йөзендә иң зур савап, гөнаһ
синең катнашында ярала...
Әй, хатын-кыз, үзең саваплы бул –
суфилыктан, зинһар, арала!

Сөембикә арияләре

(Р. Ахиярованың «Сөембикә» операсыннан)

Беренче ария

Күк капусы!
Нигә ачылмыйсың,
ник сузмыйсың ярдәм кулыңны?
Ник, Ходаем, авыр сәгатемдә
күрсәтмисең туры юлыңны?

Тагын торам юллар чатында мин.
Сайлый алмыйм берсен,
аптырыйм –
кара төндә юлны күреп булмый,
ә көндезен йолдыз яктыртмый...

Күк капусы!
Нигә ачылмыйсың,
нигә бирәр киңәш бирмисең?
Кылыч, балта айкап, җилә-җилә,
ил өстенә кабат афәт килә,
утлы сөю күкрәгемне телә,
йөрәгемнең ихтыярын бүлә –
әллә исән калам, әллә үләм...
Әллә үрти язмыш, әллә көлә!..
Ник хәлемне минем күрмисең?
Ник хәлемә минем кермисең?..

Соңгы ария

Күк капусы! Иксез-чиксез гөмбәз!
Миңа ачылмадың никтер син...
Бәхеткә дип туган дала кызын,
тәхет биреп, газап чиктердең...

Аһ, азатлык! Синең матурлыкка
ашкынмаган йөрәк сирәктер!..
Бер ак болыт була алсаң иде!..
Йә күгәрчен булу кирәктер?!.

Күк капусы! Ачыл! Минем йөрәк,
аккош булып, сиңа ашкына –
бер яшисе килә рәхәтләнеп,
бәрелгәнче яшен ташына.

Зарланмыйк

Зарланмыйк әле –
зарлану
яшәүнең ямен эчә,
аның исерткеч агуы
кан тамырына күчә.
Аң чуала,
җан кернәнә,
хис кия кара күзлек...
Тел сүзлекләр дөньясында
иң мескен сүзләр эзли.
Кыскасы:
зарланып яшәү
бәхетсез итә безне...

Бу дөньяда...

Очрашыйк әле, дускаем,
күрешик әле ешрак –
белмибез бит, безне алда
нинди көн көтеп тора.
Утырыйк та чәйлик әле,
хәл-әхвәлләр сорашыйк:
ни күрә безнең күзлекләр,
ни ташый безнең кашык,
кая атлата башмаклар,
нәрсәләр кыса тынны,
кая өнди телевизор
һәм кесә телефоны...
Даруларын барлый-барлый
бу гаҗәеп заманның,
бераз гына мактыйк аны,
бераз гына яманлыйк,
искә төшерик яшьлекнең
гөнаһларын, савабын –
бу дөньяда иң кирәге:
иркен сүз, тәмле табын...
Очрашыйк әле, дускаем,
мактышыйк һәм мактаныйк –

үзебезне тагын йөз ел
яшәргә лаек саныйк!

Туган телдән башлана

С чего начинается Родина?
М. Матусовский

Туган телемнән башлана
Туган илем минем өчен.
Туган телем – минем рухым,
Туган илем – минем көчем!

Иртән иң беренче сүзне
ишетсәм башка бер телдә,
сискәнеп китәм, әйтерсең,
яшимен мин чит-ят илдә.

Туган илемнең исеме
Туган телем исеменнән!
Алар бер булудан туа
горурлану хисе миндә!

***

Җырлый ир, җырлый хатын-кыз...
Ләкин олы аерма –
хатын-кызлар җырламыйлар,
хатын-кызлар сайрыйлар!

Дөньядагы барлык хиснең
тавышы хатын-кызда –
сөюен сайраганда ул
җәннәт кошын да уза.

Ә нәфрәтен җиткергәндә
сайрау аһәңе аша,
теле тамырлары белән
янартауга тоташа.

Ә серләрен уйлаганда
аңа кирәкми сүзләр –
хатын-кызның күзе җырлый!
Серләрен шуннан эзлә.

Бәхет шатлыктан ярала

Дус-ишләрем килде миңа
шатлыгымны бүлешергә –
табыныма ямь өстәргә,
җырлашырга-биешергә.

Бер-беребез хөрмәтенә
җылы сүзләр кызганмадык,
бергә узган гомерләрнең
киләчәген күзалладык...

Дус-ишләрем китеп барды
якты, матур уй калдырып,
«Бәхет шатлыктан ярала!»
дигән сүзгә инандырып.

Ак кайгы

Кар коела. Ап-ак мамык шәлен
җилгәрәдер, ахры, фәрештә.
Әни искә төште...
Ап-ак кайгы
күптән очты инде гарешкә...

Аның иңнәренә мин кайчандыр
ак кар төсле мамык шәл салдым.
Шул шәл бизәкләре бизи кебек
кар бизәге сарган күз алдын.

Якты тынлык сара күңелемне
ак кар сарган кебек тирәкне...
Һәр кайгы да, исебезгә төшеп,
җәберләми икән йөрәкне...

Ник карыйсың?..

Лилиягә

Синә карамыйча, кемгә карыйм?!
Син – беренчел кешем дөньяда.
Син гомерем кебек шундый иске,
син бүгенгем кебек өр-яңа.

Күз төбеңә яткан җыерчыклар
эләктерә күзем нурларын.
Юк ла, алар җыерчыклар түгел,
язылачак шигырь юллары.

Рәеш көлмәк

Моңлы шатлык аның төс-килбәте...
Әллә җиңгән,
әллә җиңелгән?!
Ничә еллар инде шулай тора
яшәү белән үлем чигендә.

Кайсысыннан котылган икән ул?
Арынырга әллә телиме?
Ничә еллар инде форсат көтеп,
рәеш көлмәк тора эленеп!..

Кояш яктысына сирәк чыга,
тән җылысын татый бик сирәк...
Кем яңара – алга таба бара,
кем өр-яңа килеш искерә.

Ачкан саен кием шкафын ул
җилфердәтеп куя итәген...
Кайчакларда сизәм: мин үзем дә
моңлы шатлык кебек икәнмен...

Мәхәббәт бер генә

Мәхәббәт турында сөйләшмик –
тәмен дә, төсен дә бетермик,
сөйләшү, күңелле булса да,
күңелгә куаныч китерми.

Ул хисне беркем һәм беркайчан
аңлата алмаган әйбәтләп.
Төпченә башласаң, мәхәббәт
әйләнә дә куя гайбәткә,

мәңгегә гайрәтең чигәрлек
мең төрле «имешкә» төренә...
Һавасы, дөньясы, җаны күк
кешедә мәхәббәт бер генә.

Без сулыйк, без күрик, без эчик
берсүзсез иң серле тылсымны,
өлешләп өләшкән чакта да
гомергә җитәрлек булсын ул!

Серле йолдыз

Мәхәббәтем канатланды минем,
сөеклемә таба юл алды.
Ләкин аңа барып ирешмичә
галәм киңлегендә югалды.

Нигә-нигә телем әйләнмәде,
белгертергә йөрәк хисемне?!
Хәзер инде йолдызларда бугай
сөйгәнемнең нурлы исеме.

Көмеш нурлар җыям учларыма,
яңгыр тамчыларын җыйгандай.
Бәлки, алар хәбәр йөртәләрдер
серле йолдыз тулы җиһаннан.

Ул да карар әле йолдызларга,
бер нур керер әле күзенә
һәм аңлатыр кайнар хисләремне
мин әйтәсе килгән сүз белән.

Нигә-нигә телем әйләнмәде,
белгертергә йөрәк хисемне?!
Хәзер инде йолдызларда бугай
сөйгәнемнең нурлы исеме.

Шагыйрь ялвара

Акылны хисле, ә хисне
акыллы итү серен
ул тумыштан белә инде,
укып-өйрәнеп йөрми.

Шагыйрь хисләрдән көчлерәк,
тирәнрәк һәм ярсурак...
Ләкин Ходайга ялвара
күңдәм, назлы яр сорап...



Сәмига Сәүбанова хикәяләре – хатын-кызларның күңел көзгесе кебек. Кайнар хисләр дә, ярату да, ялындыру-назландырулар да, эчтән яну-көюләр дә, әйтелмәгән сер дә – бар да сыйган ул хикәяләргә.

75 яшьлек юбилее көннәрендә, игътибарыгызга язучының өр-яңа хикәясен тәкъдим итәбез.



Сәмига СӘҮБАНОВА

УЛ ЧЫННАН ДА БӘХЕТЛЕ

(Хикәя)

Шикләнерлек берни дә юк иде. Элеккегә караганда ешрак ашыйсы килүенә дә аптырамады.

Сәрия элек тә тамаксау иде. Башкалар кебек тазарудан курыкмады. Алар нәселендә ашаганга карап артык авырлык җыю булганы юк иде әле. Киресенчә, аның тәненә бераз ит кундырасы килә. Чөнки ул үзе ябык: коры сөяктән генә торган кызлар да, үзе дә ошамый. Күлмәкләре тараеп киткәндәй булгач: «Яңа кием алырга җай чыкты», – дип сөенде.

Тик киемнәр тагын да тарайды. Шунда аның күңеленә шом төште. «Әллә? Булмас... Алай тиз генә бала буламыни?» – дип үзен юатты ул.

Әлбәттә, саклану чаралары турында ишеткәне бар иде барын. Тик беренче кайнарлануны үзең дә сизми калганда, андый нәрсәне кулланыйк дип әйтергә башка киләмени? Ни эшләгәнеңне үзең дә белми калганда?..

Ай, бер дә кирәкми иде, кирәк түгел иде башны югалтырга.

Ләкин туасы җан ярамаганга карап тормый, үкенеп тә, елап та утырудан файда юк. Хәзер нишләргә? Балам бар дип Исламга тагылыргамы? Кыз уңайсыз хәлдә калды. Аның әле укыйсы бар, бала булгач, нинди уку инде ул? Матур итеп киендереп алып чыккан, бер мәшәкате дә сиңа тимәгән кеше баласын гына сөю күңелле ул, анысы да еламаган чакта гына. Ә үзеңнең елак, көйсез баланы ни эшләтергә? Дөрес, гел елак та булып тормас, үсә төшкәч бераз җиңеләер дә, аңынчы ничек түзәргә? 24 сәгать буе янында булырга, ул үссен өчен әллә ниләр эшләргә кирәк.

Аңардагы үзгәрешне бүлмәдәше Әнисә үзеннән алда ук сизенгән иде. Ә инде хәлне аңлап алгач:

– Әти кешегә хәбәр итәргә кирәк, – диде.

– Мин бит аның кайда хезмәт иткәнен дә белмим... Әниләренә мин сезнең улыгыздан авырлы диимме?

– Егетнең үзенең мөгезеннән алырга кирәк. Үзең дә инде... Еракта хезмәт итәме?

– Белмим...

– Ярар, табам мин аның кайда хезмәт иткәнен!

Дусты тәки адресын тапты. Егет Камчаткага ук җибәрелгән булып чыкты.

– Хат озак бара икән, болай булгач. Әллә телеграмма сугарга микән? Кайтырга берәр сәбәп табып? Әнисенең хәле авыр дисәк?

– Андый телеграмманы табиб раслаган булу кирәк. Почта әйбәт эшли, көн саен бер хат җибәр. Сагынам диген. Зарланма, куанган бул. Командирыңа язам дип тә өстәрсәң нәтиҗәсе булмаса.

Анда мондый хәлгә бик җитди карыйлар. Сиңа унсигез тулмаган бит әле. Ә бу бик җитди статьяга керә.

Язды хатны кыз. Аптырап, чарасызлыктан язды. Егетне яратып түгел, күрәсе дә килми иде хәзер. Ул китте дә котылды, ә аны нинди кыен хәлгә калдырды. Гаилә тормышын шушылай башларга җыенган идемени ул? Әллә беркемгә дә әйтмичә төшертергә микән? Карындагы яңа яралган җан иясенә карата аңарда бернинди дә җылы хис, ярату юк, ул аның өчен вакытсыз чыккан бер сызлавык сыман тоелды.

Җавап озак көттермәде.

«Армиягә китәр алдыннан Хөллия белән никахлашкан идем шул инде, кызганыч... Ул да бала көтә. Баланы ятим итмәскә тырышырмын... Фамилиямне дә бирермен...»

Бу хатны укыгач, кыз берара ни уйларга да белмәде. Ышаныргамы, ышанмаскамы? Ышаныр иде, Хөллия Исламнан биш яшькә зуррак, җитмәсә, яңа гына ирен җирләгән иде. Шундый хәсрәт булганда ничек инде кияүгә чыгарга була? Мондый чагында башка ир турында уйлап була микән?

Үзеннән олырак кызларга өйләнүчеләр бер Ислам гынамыни? Аның әнисе әтисеннән ун яшькә зуррак әле. Әнисе һәрвакыт:

– Бал ачымас, кыз картаймас, – дияргә ярата.

Әнисенең сүзләрендә хаклык та бар. Андый гаиләләр тотрыклы, хатыннары гаиләдәге юк-бар җитешсезлек булган саен күкерт кебек кабынмый, иргә ярый беләләр. Сәрия көндәш булырга тиешле кешесенең бер генә кимчелеген дә таба алмады. Бүгенге хәленә ул үзе гаепле, беркем түгел! Аннан соң гашыйк та түгел иде бит әле ул егеткә.

Тик менә бала... Аны кая куярга, ничек котылырга? Дөрес, җае бар инде, бер ул гынамыни шул юлны таптаган?

Кыз шулай уйласа да, туасы җанга караганда үзе кызганычрак иде аңа. Бәхетсезлек көтмәгән яктан килә шул.

Исламның хаты баштагы мәлдә генә башка суккан кебек булды. Өйләнәм дигәндә дә хәл барыбер үзгәрәсе юк, моңарчы тигез генә барган тормышы барыбер башка якка борыла. Сөйләрләр дә туктарлар дип күңелне юатудан да фәтва юк. Киресенчә, ялгыз аналарның абруе ирле кешеләргә караганда зуррак та әле. Киявен дә тизрәк таба алар – туфрагыңның уңышлы булуын раслаучы дәлил бар чөнки. Ир кеше өчен нәсел калдыру бик мөһим. Ә матурлыгына, яшьлегенә кызыгып алган товарыңның эче нинди була бит әле. Шуңа күрә матурлар утырып тора, ә бирнәле кызлар гаилә кора.

Тик нинди акчага яшәргә? Мәшәкатен исәпләсәң – анысы да чутсыз. Әти-әни җилкәсенә инде бала белән дә кайтып утырыргамы? Дөрес, үз сөягең үзеңә якын дигәндәй, ата-ана баласы өчен соңгы ризыгын да бирер. Тик мондый тормышны күз алдына китердемени ул? Уйнап кына кочагына кергән иде егетнең. Уеннан уймак чыгу шушы була микәнни? Андый ир бер генә хатынныкы буламыни? Алар нәселе хатын-кыз мәсьәләсендә галәмәт киң күңелле, чибәрләр бер генә кешенеке була да алмыйдыр. Ниенә кызыкты икән Хөллия? Шул ире үлү кайгысыннан иләсләнсә генә инде...

Кызда аңа карата көнләшү хисе юк иде. Бу җәһәттән тотнаксыз Исламны да гаепли алмады. Ир-ат заты аучы белән бер, җай чыккан саен кармак салып карый, аларның тәмле теленә җебеп төшмәскә кирәк, дигән иде әнисе. Тәмле теле дә булмады бит әле. Ислам урынына башка егет белән дә шушы хәл булуы мөмкин иде бит. Тиешсез вакытта уянган гормоннар сәбәпче!

Кыз көзге каршына килде. Артык үзгәреш сизелми иде әле. Тик үзгәрмичә кала алмас. Туп йоткан шикелле кабарыр-кабарыр да һәм...

– Ярар, баш ярылып күз чыкмаган! Әнә группада кызлар исен иснәргә ашкынып торучы күпме егет бар. Берәрсенә күз кыссаң, аяк астында таш булырга ризалар! Хәзер бала сигез айдан да, җиде айдан да туа... Кияүгә чыкмыйм, бала кирәк түгел дисәң, башка чаралары да бар. Башны гына эшләтергә кирәк. Беләсең килсә, моннан бизнес ясыйлар хәзер!

Сәриянең күзе маңгаена менде.

– Нинди бизнес?

– Яңа туган балаларны алырга берничә елга чират сузылган! Синекен кулга да тидермәсләр! Генетикагыз икегезнеке дә шәп! Бәяңне генә куя бел!

– Баланы сатаргамы?

– Әйбәт гаиләгә урнаштыру дип атала бу. Әтиле-әниле итү. Ирсез бала белән нишләмәкче буласың? Идән юудан башкага ярамыйсың бит хәзер! Панельгә чыгам дисәң генә... Анда да конкурентлар җитәрлек...

Баланы кемгә дә булса бирүдән битәр, үзенең бу халәтен яшереп булмаячагы, барыбер беленәсе, әти-әнисе алдында җавап тотасы һәм мондый чакта була торган җайсызлыклар куркыта иде кызны. Акчага дип шулхәтле михнәт чигеп кем өчендер бала табу кирәкме соң? Баласын саткан дигән хурлыгын кая куясың?

Чарасызлыктан Сәриянең башы түнде. Көтмәгәндә килеп чыккан бу бәладән ничек котылырга дип баш ватты. Мондый очракта таблеткалар бар, тик аны озакка сузмый эчәргә кирәк, дип сөйләгәннәре колагына чалынганы бар барын. Башында андый уй булмагач, моңа игътибар да итмәгән. Ул шул турыда Әнисәгә әйтте.

– Син нәрсә? – диде кыз. – Аны эчеп төшмичә калса? Гарип туса? Бөтенләй кысыр калуың бар! Атаң-анаң бар, әбиең-бабаң да картлар түгел. Шулхәтле кешегә бер бала күпмени?

Әнисәнең теләсә нинди көтелмәгән хәлләрдә дә төшенкелеккә бирелми торган сыйфаты бар, һәм аның шундый булуына кызыгып та, сокланып та карый иде. Тик бу юлы аның ачуын гына китерде ул.

– Ярар, анаң үлгән кебек кыланма. Бу хәлдән бик җайлы чыгу юлы булыр кебек. Зөбәйдә Хәйретдиновнаның бала алырга җыенганын ишетмәдеңме әле?

– Кем әйтте?

– Сөйләшкәннәрен ишеттем. Тиз генә бирмиләр, чират берничә елга сузылган, дигәч, әллә фатир турында сүз бара микән дигән идем. Бала чираты турында әйтә икән!

– Үртәп торма, ичмасам!

– Юк, мин чын әйтәм.



* * *

Әнисә шунда ук Зөбәйдә Хәйретдиновна белән очрашып хәлне аңлатты. Хатын моңарчы балага узар өчен нинди генә дәвалар узмаган, яңа туган бала алыр өчен озак чират торасы булганга кәефе кырылган, һәм әллә балалар йортыннан карарга микән дип уйлап, төпле фикергә килә алмый азапланган мизгелләре иде.

Әнисә алып килгән яңалык аны сөендерде дисәк, аз булыр. Тормыш шулай ул: инде беттем дигәндә генә кемдер аяк астына җәймә дә китереп сала.

Сәрия төркемдәгеләр арасында акылы белән дә, чибәрлеге белән дә аерылып тора, тәртипле гаиләдән. Егеткә дә мутлыгыннан башка тел тиярлек түгел, әйбәт нәселдән – сәламәт, башлы бала тууына шикләнмәскә була.

Бу тормышның гадел булмавын да әйтер идем! Кирәкмәгән кешесенә бирә, ә аңа юк! Кайчак әнә иреннәреннән сөт кипмәс борын кияүгә чыкмыйча гына да бәби табарга җыенган студентларыннан көнләшү кебек хисләр барыбер үзен сиздерә. Аларның бәби үстерер вакыты түгел, белем ала торган чаклары гына бит! Туачак балаң белән алдагы көн ышанычлы булсын өчен, акчалы эшең яисә юньле ирең булу кирәк. Бала булсын өчен, ире белән күпме табибларга күренде алар, икесендә дә бу яктан гаеп тапмадылар, ә Ходай Тәгалә барыбер бирмәде...

Кыз китергән хәбәр сүнгән өметләренә канат куйды. Уйламыйча, ялгыш адым ясый күрмәсен берүк.

– Күзгә-башка күренеп йөрмәссең, дәресләрне үзләштерергә кыен булмас, интернет бар. Ә имтиханнарны бирдерүне үз өстемә алам, – диде ул.

– Тулай торакта яшәгәч, яшереп булмас шул...

– Ул яктан да тыныч бул. Сеңлем бер елга чит илгә командировкага китте. Дустың белән шунда күчәрсез. Борчылма, барысы да әйбәт булыр.

Сәрия бу бәладән котылам дисә, Зөбәйдә озакламый бала сөю бәхетенә тиенәсен уйлап, канатланып йөрде.

Берәү дә сизмәс дип уйлаганнар иде. Тик кыз язган хатны Ислам белән бергә армиягә киткән авылдашы Әнвәр дә укыган булып чыкты. Тиз арада әтисе авыр хәлдә дигән телеграмма юнәтеп кайтып та җитте.

Ул Сәрияне бала чагыннан ук ярата, тик егет өчен кыз буй җитмәс алиһә кебек, яшерен генә көя-саргая, аңа яшерен генә соклана иде.

Бу хис шулай гомерлек сер булып калыр иде, тик Исламның кызга язган җавабы аны беркем дә көтмәгән адым ясарга этәрде.

Әнвәр поездан төшү белән туп-туры институтка килде. Сәрия аны күреп чак артына аумады.

– Мин сине алырга килдем, – диде егет, хәл-әхвәл алышканнан соң.

– Кайда?

– Кайда булсын, авылга инде.

– Әллә өйдәгеләр белән бер-бер хәл булдымы?

– Юк, барысы да тәртиптә.

Тик күңеле нәрсәгәдер шикләнде әле. Өйдә берәр гайре хәл килеп чыкмагандыр бит. Нишләп аны Әнвәр алырга килгән, башкалар түгел? Әтисе белән әнисенә берәр хәл булса, аны алырга килердәй туганнары да бар бит. Кичә генә күршеләре Хәтирә апаны очратты, ул да бер сүз әйтмәде. Ә монда мең чакрым арадан кайтучы егетнең аңа, аның гаиләсенә ни катнашы бар?

– Юк, мин беркая да китмим.

– Ник?

– Кич үзебез киләбез, диделәр.

Кыз башына беренче килгән фикерне әйтте. Егет тә аптырап калмады.

– Мин дә яңа гына вокзалдан төшкәч үземнекеләр белән сөйләштем. Анда синең әниең дә бар иде. Үзем белән сине алып кайтырга куштылар.

Юк, монда нидер бар. Тик торганнан гына бер сәбәпсез армиядән җибәрмиләр бит. Бик җитди сәбәп булса гына... Моны раслагандай, корсагында нидер тыпырдап алды. Бер тапкыр, ике... Юк, аның теләсә кемгә ияреп кайтырга хакы юк. Кайткач, нәрсә дип аклансын ул? Андагы үзгәрешне шунда ук күрәчәкләр!

– Кайтмыйм! – диде ул. – Нишләп әле мин сиңа ияреп кайтырга тиеш? Укуым кала, имтиханнарым! Отпускада шухыр-мухыр өчен миннән башка да кызлар җитәрлек!

– Мин шаярырга кайтмадым. Синең белән шухыр-мухыр килергә дә уйламыйм. Мин өйләнергә кайттым.

– Өйләнсәң соң. Миннән башка булмыймыни?

– Булмый шул.

– Синең туеңда минем ни эшем бар?

Алар шулай тарткалашып торганда, Әнисә килгәне күренде.

– Бәрәч! Танымыйча торам. Баерсың, – диде. – Әллә Казанга күчерделәрме?

– Армиядән качып кайткандыр әле! Дезертир!

– Дезертир түгел мин. Бигрәк әйбәт булды әле синең дә очравың! Өйләнергә кайттым мин. Син шаһит булырсың.

– Туйга дигәндә, урындагы хаста да терелгән. Кайтабыз! Нигә кайтмаска? Шулай бит, Сәрия? Ихтирам итеп туйга чакырып торганда... Кәләш кем?

– Кайткач күрерсез.

– Ну астыртын да үзең! Тымызык күлдә корт уйный, дип тиккә әйтмиләрдер. Без беләбезме кәләшне?

– Беләсез, кәнишне.

Сәриянең туй түгел, үзен дә күрәсе килми шул. Тик Әнисә башкача хәл итте.

– Болай зурлап алырга килгәч, кайтабыз! Персональный машина беләнме?

Әнвәр якында гына торган җиңел машинага кулын изәве булды – тегесе килеп тә җитте.

– Рәхим итегез, кызлар!

Кызлар Әнвәрнең сыйныфташы Хәкимне күреп алдылар. Теләсә дә утырды Сәрия машинага, теләмәсә дә. Әнисәнең теле телгә йокмый.

– Син кияү егете ягыннан шаһит буласыңдыр инде, – диде ул. – Ә мин кем урынына булырмын.

– Кәләш ягыннан шаһит инде.

– Ә Сәрия?

– Аңа да эш табылыр.

Сәрия аларның сүзенә катнашмады. Тәрәзә ачык булса да, бензин исенә көчкә чыдап, ник кайтырга риза булганына үкенеп кайтты. Ләкин төшеп калып та булмый,

ни чарадан бичара түзә, аларның сөйләшкәннәре дә бер колактан керә, икенчесеннән чыга. Әнисәнең шаһит буласы егетне ошатканы сизенә.

Еракта авыл күренде.

– Менә авыл, ичмасам! Мондый авылга килен булып төшсәң дә ярый, – диде Әнисә.

– Фәрештәнең амин дигәненә туры килсә, калуың да бар. Буйдак егетләр күп бездә.

– Миңа теләсә нинди кирәкми. Баскан урында ут чыгара торганы булсын.

– Андые да бар. Ну болай син иң үшән ирне дә утлы табага бастырырга охшаган.

– Песи кебек тә була алам. Сыйпап торсалар...

Әнвәрләр өе күренде. Аларның капка төбендә берничә кеше әрле-бирле йөренә иде. Капканы киң итеп ачып куйганнар.

– Әнә безне әллә кайчан көтәләр инде, – диде егет.

Машинадан төшүгә, аларны әйләндереп алдылар да өйгә алып та кереп киттеләр. Кемдер аяк астына мендәр китереп салды, кемдер авызына бал-май каптырды. Кыз аны-моны аңышмыйча тартышты, балны да, майны да капмаска тырышты, мендәрне читкә этте, тик ике егет – Әнвәр һәм шаһит булырга тиешле дусты аны ике яктан күтәреп диярлек өйгә алып керделәр.

Өйдә табын корылган, мулла түр башында утыра, тагын кемнәрдер... Кызның башы әйләнде, күз алды караңгыланды, ризык исеннән укшыйсы килде. Иңеннән кемдер кочып алды шунда. Борылып караса – әнисе!

– Әни, бу нинди кәмит?

– Кәмитне без түгел, син ясагансың, кызым. Күпме яшереп йөрергә җыендың?

Ислам эше генә бу! Ул да кайткан! Тик нишләп күренми үзе? Башта ук шулай дип булмыймыни?

Ул берни аңламыйча Әнвәргә күтәрелеп карады.

– Куркыныч берни дә юк, – диде егет. – Киткәндә белгән булсам, никах укытып, язылышып китәсе идем. Безнең нәселдә баласыннан баш тарткан кеше юк.

Калганы төш кебек кенә булды. Мулла никах укыды, кияү егете кызга һушына килергә дә ирек бирмәде, никах уку белән авыл советына язылышырга алып китте. Сәриянең үзе белән документлары булмавына да исләре китмәде.

– Кем икәне маңгаена язылган инде, документсыз да беләбез.

– Бердәнбер улыбызны туйлап өйләндерәсе килгән иде дә, яшьләр ашыга шул, – диде Әнвәрнең әтисе. – Ә болай берьюлы ничә куян – расходы да әз, бирнәсе дә шәп. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтле кешесенә генә эләгә бит бу!

Шунда гына кызның аңына барып җитте. Төш түгел икән бу, өн икән!

Ниһаять, кияү белән кәләш ялгыз калды.

– Нинди театр булды бу? – диде кыз, ни уйларга да белмичә.

– Син – минем хатыным, ә мин – туачак баланың әтисе.

– Аның әтисе ...

– Хәзер минеке... Дөресен әйткәндә, мин әле моның чын булуына һаман да ышанып җитмим...

– Көтмәгәндә...

– Кемгә ничек... Мин сине бәләкәй чактан бирле яраттым.

– Нигә алданрак белгертмәдең?

– Кыюсызлыктан инде. Син кем дә, мин кем... Бер башка озын... Безнең якка борылып та карамый идең...

– Бигрәк бәләкәй идең...

– Безнең нәсел егерме бишкә хәтле үсә. Беләсеңме, мин ике дә уйлап тормадым. Әтиләргә телеграмма белән чакырып кайтарырга кушып хат яздым. Ничек инде сине авыр хәлдә калдырыйм?

Кызның буасы ишелде. Башын егетнең иңенә куеп, күз яшьләренә ирек бирде. Карап торганда гына ябык кебек тоелган икән, бер дә алай түгел икән. Көч тә, гайрәт тә бар икән үзендә. Хәер, кем ничек күрә бит, берәүләр өчен беләктә, берәүләр өчен йөрәктә...

Егет иреннәре белән кызның чәчләренә кагылды.



Рәсем: Наталья Васильева



– Мин арыдым. Син дә... Әни кешегә ял кирәк.

Ул аны сак кына караватка салды.

– Син йокла. Мин идәнгә ятармын.

Кыз карынындагы баланың башка кеше өчен булуы белән килешкән иде. Хәзер ике ут арасында калды. Моны ул Әнвәргә әйтә алмый, мәңге риза булмаячак, авыр чакта ярдәм кулы сузган Зөбәйдә апасы да кызганыч иде. Хәзер аны гаиләгә бәйләп куйдылар, уку турында уйлап та булмаячак. Бәби табасы кешене кем инде чит-ят арасына җибәрсен? Укуын дәвам итсә, җаен да табар иде әле, бала үлде дип котылырга да була. Аннан соң аерылачак та үз дигәненчә яши башлаячак әле ул. Кәлүш киеп мал-туар асрарга, бушка колхоз эшенә йөрергә һич риза түгел, киләчәген алай күз алдына китерми иде. Ярар, хәзер аңа уйларга ирек бирмәделәр, барысы да томан эчендә кебек булды. Бу әле аңа гаилә камыты киде дигән сүз түгел. Әнвәргә нәрсә, ул отпускасы бетү белән армиягә китә, ярый әле китә, ул булмагач аны тотучы юк, булса да, беркем дә бәйләп тота алмый. Сәрия шулай уйлады. Хәер, Әнвәрнең әти-әниләре үзләре дә яшьләр, ике тәкә башы бер казанга сыймаган кебек, кайнана да бер өйдә ике хуҗабикә булуын теләми, ул шундук:

– Кияүгә чыктым дип, ир җилкәсендә ятарга уйлама, укуыңны тәмамла, улым кайту белән аерым яшәрсез, – диде.

Шуның өчен генә дә рәхмәтле ул аларга.

Зәбәйдә Хәйретдиновна да Сәрия өчен шат иде.

– Син үз кызым кебек булып беттең инде, – диде ул. – Укуың өчен борчылма, кирәк чагында булышырмын.

Туй балдагы, туй күлмәге кию турындагы хыяллары томан кебек таралды да бетте. Ә туйга хәтле була торган очрашулар, озатышулар, күктән йолдызлар санаулар... Юк, аның тарафыннан уйланмаган эш булды бу, аның ир хатыны буласы килми. Барыбер җаен табачак! Әтисе әйтмешли, ансат кына, расхудсыз гына өйләнергә уйлаган! Кайтканын да көтеп тормаячак, аерылырга гариза бирәчәк. Ә бала? Үстерсен Зөбәйдә, теләгенә ирешсен. Ә ул әни булырга әзер түгел әле.

Кыз елый-елый Зөбәйдәгә хәлне аңлатты. Ә ул аның иңнәреннән кочты, чәчләреннән сыйпады.

– Синдә йөкле хатыннарда була торган депрессия, – диде ул. – Кулыңа сабыйны алу белән шушындый уйларың өчен үзеңә дә оят булачак. Аның әтисе бар бит әле.

– Ул әтисе түгел.

– Закон буенча әти. Ә мин... Ходай Тәгалә минем дә ялваруларымны ишетте. Минем дә балам булырга тиеш. Икәүләп бергә бала арбасы тартып йөрисебез бар әле! Син әле нинди бәхеткә тиенгәнеңне аңламыйсың, кызый. Әйтү түгел, күңелеңә дә китермә мондый уйларны. Ул барысын да аңлый, ишетеп ята хәзер.

Укытучысының бу сүзләре кызны айнытып җибәрде.

– Шулай ул күк капусы: төрле кешегә төрле вакытта ачыла. Бөтенләй ачылмавы да бар.

Октябрь бәйрәме якынлашты. Курсташлар бәйрәмгә өйләренә кайтырга җыенды. Тик Сәрия генә кая кайтырга белмичә аптырап калды. Хатларында Әнвәр үзләренә кайтырга кушып яза. Ә аның үз әти-әнисе дә бар бит әле. Карынындагы бала аңа чит түгел иде инде. Ул аның өчен җаваплылык тоя башлаганын сизде, бу җаваплылык куркытты да.

Кемгә кайтырга? Үзләренә кайтыр иде, кешенең авызын яба алмыйсың, яши башламас борын кайнаналарын санга сукмый, диярләр. Һәм алар хаклы булачак. Ә Әнвәрләргә? Анда ни эшләр ул? Сәрия тулай торакта калырга булды. Ниятен Әнисә хуплап бетермәде.

– Безгә кайтыр идек тә, чыдый алырсың микән? Бәйрәм алдыннан халык күп, алты сәгать буена этелеп-төртелеп кайтасы. Андый чакта автобуста энә төшәрлек тә урын булмый.

– Бәйрәм вакытында бездә дә шул хәл. Шуңа кайтмаска булдым инде.

– Зәбәйдә апа белән киңәшсәк?

– Мондый вакытта нинди юлга чыгу? – диде Зөбәйдә. – Берүзең калу да ярамас. Нәрсә булмас? Безгә килерсең. Урын иркен.

– Мин сезгә беркем түгел...

– Юк сүз сөйләмә. Син минем укучым. Монда укыган чакта синең өчен мин җаваплы.

Шулай килештеләр. Тик бәйрәм алдыннан бүлмәләренә Әнвәрнең әтисе килеп керде.

– Берәр хәл булдымы әллә? – диде кыз куркынып.

– Кышкы юлга чыкмасын дип үзем килдем... Оныгыбызны без сакламый кем сакласын?

Кызның тамагына төер тыгылды. Күзеннән яшьләр атылып чыкты. Ул чит ояга йомырка салырга җыенган кош хәлендә иде. Ишеткәне бар, кәккүкләр шулай итә дип.

– Мин анда берүзем... нишләрмен соң? – диде ул. – Мин бит...

«Сезгә беркем түгел», димәкче иде, тик ул сүзләр әйтелмичә күңелендә генә калды.

– Ничек инде берүзең? Син хәзер безнеке инде. Улыбыз кайтканчы, синең өчен без җаваплы. Синекеләр дә кайтканыңны дүрт күз белән көтә.

* * *

Чит гаиләдә ничек яшәп китәрмен дигән уй кайту белән юкка чыкты. Биредә аны үз кызлары кебек якын иттеләр. Кайнанасына булышмакчы булганда да, аны эшләтмәделәр.

– Синең эшең – сау-сәламәт бала табу.

– Сез эшләгәндә миңа тик тору уңайсыз...

– Нинди сүз ул тик тору? Ә бала күтәрү? Ул эш түгелмени?

Бәби тапкач укуны ташларга туры килмәсме дигән борчуы юкка булды. Зөбәйдә апасы сүзендә торды, ул имтиханнарын алдан ук тапшырды. Берничә ай аерма белән аның да кызы туды.


...Әнвәр армиядән кайтканда, аның улы Кодрәт тәпи йөреп азаплана иде. Әнвәр аны баш очына күтәреп сикертте дә, бер кочагына улын, икенчесенә Сәрияне алды.

– Сез бәхетле булсын өчен мин барысын да эшләрмен, – дип, хатынының битеннән үбеп алды.

– Мин дә... – дип пышылдады Сәрия.

Ул чыннан да бәхетле иде.

ЙӨРӘКТӘ!



«Безне – сәер яшәп киткәннәрне искә алмас, бәлки, беркем дә, – җырланган җыр, тере шигырь калыр дөньядагы җилләр иркендә», – дип язган иде шагыйрь Зөлфәт замандашы, каләмдәше Рәшит Әхмәтҗанов истәлеген яд итеп. Һәм очрашуларының берсендә ул җырлаган бер җырны да искә төшерә: *«Ак үрдәккә, күк үрдәккә / Җимнәр салдым түмгәккә. / Эчем яна, тышым яна / Ут кабынмый күлмәккә! Уф!»*

Бу – Рәшит. Шук, шаян да, уйчан, гамьле, моңлы һәм... серле дә. Актык сулышынача үзен шигъриятькә багышлаган, *«Җирдә җылы артык булмас әле, / Мин дә җанны ягып калдырам»,* – дип җырлаган Рәшит юк инде. Иртә китте, ә шигырьләре исән...

Халыкның йөз аклыгы, вөҗданы, иманы булып тарихта калу сирәкләр өлешенә тия. «Ачлык мәйданы»нда, җөмһүриятебезнең бәйсезлеге өчен көрәшүчеләр сафында иде Рәшит тә. «Догалы читекләр, дагалы итекләр», каһарманнар тарихта калды. Шигърияtнең тормыш иминлеге өчен көрәштә хәлиткеч көч икәнлеген аңлап иҗат итте ул.

Кысылулар, сугылулар булса –
Дошманнарга каршы чыгарбыз.
Без туган тел булып җырларбыз да,
Без туган җир булып сугарбыз.

Диңгез төбенә төшеп энҗе эзләгәндәй туктаусыз эзләнде, сүзләрдән асылташка тиң шигъри мәрҗәннәр тезде. Йөрәгенең яктысын, җан җылысын халкына биреп, милләтнең аң-дәрәҗәсен күтәреп, гамьсезләрне уятырга омтылды. «Бу тормыш – тоташтан зилзилә»сендә болай язган иде:

Йөрәккә кагыла салкын сүз,
Җылы кул, салкын таш, җылы җил,
Барысы да тарала, югала, –
Кала тик туган ил, туган җир.

«Бала чагымда җылыткан кояш җылытты мине гомер буена», – дия иде.

И туган тел! Сине Әнкә итеп
Йөрәгендә саклый бу халык,
Таралган ул... Әгәр син булмасаң,
Бетәр иде күптән югалып.

Фидакарь җанлы дустыбызны «Безнең Рәшит» дип йөрттек. Берәүгә дә охшамаган, беркемне кабатламый, үзе булып яшәгән хөр күңелле шагыйрьне «безнеке» дип атавым юкка түгел! Сабакташлар идек без. Кан кардәшләр булмасак та, туганнар кебек, җанкардәшләр булганбыз ич!

Милли җанлы, талантлы шәхесләребезнең күбесе төрле елларда университетның тарих-филология факультетында оешкан татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыды. Каләм кыштырдатырга маһир, язучы, шагыйрь булырга хыялланган һәр татар баласы, очар кошлар канат ныгыткандай, шушы бүлектә чыныгу алды.

Солдат киемен дә салмаган Рәшит ул чакта ук безнең буй җитмәслек йолдыз иде. Балачактан шигырь язу белән җенләнгән, Әлмәттә Чупай ташыннан йортлар салышкан. *«Таш күтәреп тала буыннарым / Ташлардан ук үзем көч алам. / Яшьлек, яшьлек! / Синең сафларыңда тау-ташларны ватып сыналам»* дигән юлларын без ятлап алган идек инде. Ә «Бәйрәм»е – бәйрәм генәме, ачылмаган сер булды бугай:

Без мәңгегә, без мәңгегә монда,
Эх, бу җирне күпме таптады
Безнең йөрәк бәйрәмнәренең
Кыңгыраулар таккан атлары.

(Соңрак басылган җыентыкларында «бәйрәмнәребезнең» дип укыдык, әмма безнең өчен «йөрәк бәйрәмнәре» аңлаешлырак, якынрак иде).

Рәшитнең үсмер чакта район газетасына җибәргән шигырьләрен яшь кеше язганына ышанмый, бастырмый яткыруларын, олпат әдипләр – Хәсән Туфан, Сибгат Хәким талантлы егеткә өмет баглап, хәер-фатиха бирүен дә, китабы нәшриятта басылырга чират көтеп ятуын да ишеткән идек. Боларның берсен дә үзе сөйләми, тыйнак, әдәпле, хәтта үсмерләр кебек оялчан иде ул.

Аның төс-кыяфәте дә үзгә. Төз гәүдәсенә килешеп торган солдат киемнәрен салмый йөрүе генә... («Әрмис» булып йөрүенең хикмәте – ишле гаиләдә үсеп яшьләй әтисез калган егетне дә ярлылык чит итмәвен искәрә идек тә...) Ул бит шагыйрь! Зур күзләрендә – моң. Дөньяның бар гаме, шатлык-кайгысы – һәммәсе сыйган сыман.

«Абый», дип, үзебез олылагангамы, туганыбыз кебек якын, хөрмәтле кеше булды ул безгә. Өр-яңа шигырьләрен кычкырып, илһамланып укуы, шигъри табышлары белән бүлешүе – бәйрәм. Йөрәк бәйрәме. Сүзнең тәмен белә, шигырь аңлый, шигырь ярата торган, иҗатына гашыйк кыз-кызның мәхәббәтен сизгәндер үзе дә. Әмма эч серләрен теләсә кемгә сөйләп йөрмәс... «Күктә-җирдә сезгә сөю калыр миннән», дип җырлаган Рәшитебезне иҗатка рухландырган «муза» – безнең өчен дә табышмак. Ул кыз янәшәдә! Ә бәлки хыялдыр...

Рәшит эш аты иде. Дан артыннан кумас, эче тулы ут булса да, сиздермәс. Студент елларында балалар бакчасында – төнге каравылчы, аннан газеталарда – әдәби хезмәткәр, гомеренең соңгы унбиш елында «Казан утлары»нда мөхәррир булып эшләде. Гаиләсен, балаларын кадерләп яшәде.

«Кемнәрдер еракта, кемнәрдер йөрәктә... Мин, ахры, еракка – йөрәккә китәрмен, / Бу җирне очсыз һәм кырыйсыз итәрмен!» – дип, афоризмга тиң күп шигырьләр иҗат иткән Рәшитнең иҗаты, бәлки, күпләргә сер булып калыр иде. Ертлач түгел иде ул. Китап арты китап чыгару артыннан йөрүне, бәлки, оят санагандыр, бәлки, тыйнаклыгы комачаулагандыр.
Үзе исән чагында юка тышлыкта басылган китаплары күптән таралып, тузып та беткәндер. 2014 елда бертуган сеңлесе Сания Фәйзрахманова «Рухият» нәшриятында Рәшит Әхмәтҗановның ике томлык шигырьләр җыентыгын бастырып чыгарган иде. Узган ел «Рухият»тә, абыйсының иҗатына олы бәя биргән язма-хатирәләрне туплап, улы Марат белән бергәләп, «Татлы сагыш, рәхәт сагыну» дигән гүзәл альбом нәшер итүләре нур өстенә нур булды.
Мең рәхмәт аларга!

Роза КАМАЛЕТДИНОВА

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Язмам көчле рухлы, батыр йөрәкле татар хатын-кызы турында. *1890 елны Буа өязенең Чәчкаб авылында Һадиятулла бай гаиләсендә бер кыз туа. Исемен Бибигарифә дип куялар. Ул кыз – минем әбиемнең әнисе була.*

Чибәр, укымышлы булып үсеп җитә ул. Өстәвенә, атаклы бай кызы да бит әле! Әсәдулла исемле мишәр егетенең аңа күзе төшә. Һадиятулла байның Бибигарифәне бу егеткә бирәсе килми. «Минем йортымда сиңа бирердәй кыз юк!» – дип, кире бора. Ләкин яшьләр инде бер-берсен ошатып өлгергән була, әтиләренең каршылыгы аларны куркытмый. Бибигарифәгә 20 яшь тулгач, абыйлары аны үзләре белән Әстерханга алып китә. Әсәдулла да шунда балык тотуда эшли. Яшьләр никах укытып, чит-ят җирдә тормыш кора. 1911 елны кызлары туа. Бибигарифәнең яшьли вафат булган әнисе хөрмәтенә аңа Заһидә дип исем кушалар. Тик сабый нибары өч кенә ай яшәп кала. 1912 елда – Маһитап, 1914 елны тагын бер кызлары Хәдичә туа. Аның туганын әтисе күрергә дә өлгерми, шул ук елны Әсәдулланы Герман сугышына алалар. Ул еллардан бездә хәтта бер фотография дә сакланган. Дүрт айлык авыры булган Бибигарифә бәләкәй кызы белән берүзе кала. Ундүрт елга аерылышасыларын ул вакытта әле берсе дә белми…

Бик авыр чорлар була ул. 1915 елны эшчеләргә 30–40 сум акча түләнә, ә фатирга түләү 15 сумнан 32 сумга кадәр күтәрелә. Бибигарифә ничек итеп булса да яшәргә тырыша. Үз хәлен үзе генә белгәндер. Кече кызы Хәдичә әйтүенчә, берәрсенең бәрәңге кабыгы ташлаганын күрсәләр, шуны алып кайтып пешерә торган булалар.

Янадыр ла эчем яна,
Йөрәгемнән каннар тама,
Туган илем, туганнарым,
Ерак калды ике ара.
Түгәм яшем мин сагынгач,
Орам аһлар, бәгърем янгач.
Күңелләрем юанадыр,
Туганнардан хатлар алгач, – дип, үз-үзен шигырьләр чыгарып юата ул.

Бәхетенә, аны ике кечкенә кызы белән Кәрим бай гаиләсе сыендыра. Бибигарифә ара-тирә аларның балаларын караша. Байның балалары Шамил, Наилә, Сафия белән аныкылар бергә үсә. Тамак хакына кешеләргә кер уулар үзенекен итә: Бибигарифә куллары сызлап җәфалана. Бер чынаяк чәй дә күтәрә алмаслык көннәре күп була.



Фото: Әсәдулла һәм Бибигарифә кызлары Маһитап белән. 1913–1914 еллар.

Еллар уза… Сугыш тәмамлана. Тик Әсәдулла гына күренми. Исәнме, юкмы икәнлеген дә белмиләр. Гаиләсе янына бары 1928 елны гына кайта ул. Ләкин кайту белән аны тагын өч ай төрмә көтә… Төркиягә әсирлек-кә эләгеп, анда тагын бер гаилә корган була, кечкенә генә кибет тә ачып җибәрә. Шунда калса, бәлки, бу газапларны күрмәс тә иде, тик беренче хатыны Бибигарифәне, кызларын сагыну хисе көчлерәк булып чыга. Моңарчы әтисен бер тапкыр да күргәне булмаган Хәдичә аның белән тәүге очрашуда һушын югалтып егыла.

Көтмәгәндә Әсәдулланың туган авылыннан кайгылы хәбәр ирешә: бертуган абыйсы белән җиңгәсе мунчада янып үлгәннәр. Балалары ятим калган. Әсәдулла гаиләсе белән туган якларына юнәлә. Хәдичә исә Тәтеш педагогика училищесына укырга керә. Жор телле, шаян кыз укытучылар куйган спектакльләрдә дә катнаша, бик матур җырлый. Солтан исемле егет аны Галиябану ролендә күреп гашыйк була да инде. Әтиләре ризалык бирмәс дип куркып, кызны урлый. Шулай итеп, Камаловлар гаиләсе тө-

Фото: Ксения Богданова

зелә. 1936 елны кызлары Флера туа. Тагын бер елдан танк гаскәрләре офицеры Солтан Камалов гаиләсен Львов шәһәренә алып китә. Сугыш башланган көнне юньләп саубуллаша да алмыйлар: «Балаларны сакла!» – дип кенә әйтергә өлгерә... Алар башка беркайчан да күрешми... Хәрбиләрнең гаиләләрен ашыгыч рәвештә Себергә эвакуациялилар. Ләкин Хәдичәнең ирен калдырып китәсе килми. Бомбалар яңгыры астында ике көн яши әле ул. Дүрт айлык авыры булган хатынын кечкенә баласы белән вокзалга озатышырга дип, Солтан йөк машинасы һәм солдатлар җибәрә. Иреннән иң соңгы хәбәр менә шул була. Хәдичә Себергә үк китми, поезд Канаш станциясенә якынлашканда, кызын кочаклап, вагоннан сикереп төшеп кала. Моннан инде иренең туган авылы Аксуга кадәр җәяү кайта. 1943 елны Әстерханга кадәр барып, әти-әнисен дә Аксуга алып кайта әле ул. Алар Әсәдулланың туган авылы Чатказда төпләнә. Гарәп телен яхшы белгән, Коръән укыган Әсәдулланы авылдашлары бик хөрмәтли. Сугыш вакытында бригадир да, кыр каравылчысы да булып эшли ул, почта начальнигы да була. Бибигарифә исә авылдашларына кирәк-яраклар тегә.

Еллар уза... Әсәдулла каты авырый башлый. Аннан калсам, мин нишләрмен, дип, Бибигарифә бик кайгыра. Төне буе борчылып чыгып, иртән якыннарына аш-су әзерли, үзе исә бакчага чыккан җиреннән җан бирә. 1957 елның 24 июне була ул. Шул елның ук кара көзендә Әсәдулла да вафат була. Шекспир әсәрендәгечә: бер-берсен өзелеп яраткан җаннар бер үк көнне булмаса да, бер үк елны мәңгелеккә күчә.

Гөлнара ҖӘЛӘЛ.
Казан шәһәре.

Минем өчен бик тә якын булган әниемнең туганнан туганнары – Шәйхелислам, Сәхия апа, Нурислам, Мәхмүт, Рәфкать, Фәргать, Фәрит, Дания апа, Рәис, Рәшит абыйларның фотосурәтләре Нурислам абый яшәгән төп нигезнең тәрәзә өсләрендә рамнарда эленеп тора иде.

Заманында алар барысы да СССРның төрле якларына китеп таралышканнар. Кайсы нефть чыгарган, кайсы ГЭС төзегән, кайсы Украинада, кайсы Урта Азия якларында яшәгән... Нурислам абый белән Сәхия апа гына туган якларында калган (сүз уңаеннан: Сәхия апа оста итек басучы иде. Ирләр генә башкара торган авыр хезмәт). Әниләре Рәхимәдән (без аны яратып Яшь нәнә дип йөрттек) бу фотоларда кемнең кем икәнен сорашып, төпченеп бетерә идем. Кайткан саен, ул фотоларның исәбе арта тора – анда инде уларының гаиләләре белән төшкән фотолар да урын алган булыр иде... Бәгырь җимешләрен сагынып, шул фотоларга карап Яшь нәнә: «Очырдым еракларга ла, / Зар тилмерәм күрергә...» – дип моңлана иде...

Шуларның берсе – Шәйхелислам Галимҗан улы 1941 елның апрелендә Украинаның Житомир шәһәренә армия хезмәтенә алына. Шуннан туры сугышка эләгә. 1941 елның 9 июлендә Житомир немец гаскәрләре оккупациясендә кала, шәһәр үзе бик көчле бомбага тотыла. Красноармеец Шәйхелислам Хәйруллиннан туган якларына берничә хат кына килеп өлгерә. Латинча хәрефләр белән язган хатларында бик каты сугышлар баруын җиткерә ул. Кыска гына үзәк өзгеч шигырьләре арасында:

«Әтекәем, Әнекәем,
Кадеркәем...
Герман границаларында
Булыр күк каберкәем...»

«Әнием сиңа бүләгем –
Кара сатин күлмәгем.
Язаланып үстердең дә,
Рәхәтемне күрмәдең...» –

дигәннәре дә булган.

Озак та үтми, «Хәбәрсез югалды» дигән язу гына килеп төшә туган нигезгә. Өметләрен өзмичә, кайтыр дип көткән ата-анага, туганнарына бу бәхетне татырга насыйп булмый. Яшь баба (әтисе Галимҗан) эзләп-эзләп каратса да, кызганыч, эзенә төшә алмады... Хәтер китабына исеме керсә дә, анда бүтән берниндиди мәгълүмат та юк...

Туганнарым арасыннан Рәис абый белән Фәрит абыйны да күргәнем



Фото: Шәйхелислам Хәйруллин. 1941 ел.

булмады. Ә күрәсем бик тә килде... Кызганыч, Рәис абыйдан башка бу туганнарның инде берсе дә исән түгел... Менә ничә еллардан соң, узган елның көзендә Рәис абый белән күрешү бәхетенә ирештем, шөкер... Рамнарга куелган фотодагы кебек, Рәис абый бүген дә төз, матур, сөбханалла. Ерак араларны якын итеп апасының кызлары янына кайтыпкитеп йөри. Дулкынландыргыч күрешү булды ул. Барлык туганнарны – исәннәрен дә, вафат булганнарын да искә алып, истәлекләр белән бүлештек. Күңел түрләрендә җылы, матур хатирә булып калды очрашуыбыз...

Рәис абый Германиядә солдат хезмәтеннән кайткач, авылда эш булмау сәбәпле, абыйсы Фәрит янына Братскига китеп бара. Шунда урнашып кала. Гаилә кора. Балалар үстерә. Аяныч, соңгы елларда сыңар канат белән генә булса да, үзенчә көн күрә. Нишлисең, тормыш дәвам итә...

P. S. Рәис абый белән күрештергәннәре өчен Сәхия апаның кызлары Рита апа белән Линура апага рәхмәтләрем аеруча зур.

Фирдәвес АБДУЛХАНОВА.
Кама Тамагы районы.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан,
Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA

ПОСТКРОССИНГ ЯКИ КӨТЕЛМӘГӘН ХАТЛАР

Посткроссинг ул – почта аша бер дә таныш булмаган һәм төрле илләрдә яшәгән кешеләр белән открыткалар алышу системасы. Аны моннан 16 ел элек Португалиядә яшәүче, компьютерларга мөкиббән студент – Пауло Магальяйнш уйлап тапкан. Шул рәвешле, җир йөзендәге бар халыкны берләштерергә теләгән ул. Открыткаларның бәхет алып киләсенә ышанган! Посткроссингның рәсми сайтында бүгенге көндә 60 миллионнан артык кеше теркәлгән. Һәм иң күңеллесе – күптән түгел генә «Миллиард татар» сайтында бөтендөнья татарларын берләштерү максатыннан татар телле посткроссинг барлыкка килде. Татарларның бер-берсе белән кулдан язылган сүз, хат аша аралашу мөмкинлеге туды!

Раилә ХӘЯЛИЕВА

Кызык бит, сайтта теркәләсең дә, әллә кайда – еракта яшәүче милләттәшеңә открытка җибәрәсең. Беренчесенә, икенчесенә, өченчесенә... бишенчесенә! Һәм үзеңнең почта тартмасын да караштыргалап торасың. Австралиядән яки Франциядән нәкъ сиңа атап язылган открытка килеп төшүе бар чөнки! Бу системаның эшләү тәртибе шундый: син кемгәдер открытка җибәргәннән соң, әлеге сайт аша хат алышырга теләгән башка берәүгә (кайда яшәгәненә карамастан!) очраклы рәвештә ул синең адресны тәкъдим итә.

«Хатлар йорты» белән бергәлектә «Миллиард татар» платформасында оештырылган посткроссингның төп идеясе дә шул: төрле илләрдә яшәүче татарлар арасында дуслык күпере сузу, почта элемтәсе аша милләттәшләребезне бер-берсенә якынайту. «Ел башында без Россиянең төрле өлкәләрендә яшәүче 100 татарга хат язган идек. Алардан һәм чит өлкәләрдә актив эшчәнлек алып баручы милләттәшләребездән порталга теркәлүләрен сорадык. Республиканың танылган шәхесләре белән дә татарча посткроссинг аша хат җибәрүне оештырдык. Җырчы Фирдүс Тямаевка Казан шәһәрендә яшәүче ханымның адресы чыкты. Ә Камал театры артисты Фәнис Җиһаншаның открыткасы Карачай-Чиркәс Республикасына ук китте. Дөньяда посткроссинг аша чит кешеләргә открытка җибәрү модасы үсә барганны күзәтергә була. Тиз арада безнең порталның да базасы тулыланыр һәм географиясе киңәер дип өметләнәбез», – ди «Хатлар йорты» проекты җитәкчесе Энҗе Садыйкова.

Дөресен әйтим, хатлар, открыткалар белән мәш килергә яратсам да, посткроссинг аша әле берәүгә дә открытка җибәреп караганым юк иде. Инде чит җирләргә дә шундый җиңел юл белән татарча открыткалар юллап була икән, нишләп бу мөмкинлекне кулланып карамаска ди?! Безнең әби-бабаларыбыз, әтиәниләребез, бөтен күренекле шәхесләребез гомер-гомергә хат аша аралашкан, кәгазьгә язылган сүз йөрәк җылысын алып барып җиткезгән, ерак араларны якынайткан.

Хат алышу гадәтен яңадан тергезеп, әйдәгез, бергәләп посткроссинг аша открытка җибәреп карыйбызмы?



Фирдүс ТЯМАЕВ,
Татарстанның атказанган артисты

– Ышанырсызмы, юкмы, әмма минем иң яраткан бүләгем – ул открыткалар. Кечкенәдән открыткалар, маркалар җыю белән мавыктым. Әле хәзер дә туган көнемә открытка бирсәләр, бәйрәмнән соң аларны рәхәтләнеп карап, укып утырырга яратам. Студент елларында бер кыз белән, ак кәгазь битенә йөрәк рәсемнәре ясый-ясый, мәхәббәт хатлары алышкан идек... Ә хәзер инде хәләл җефетемә – Резедама бәйрәмнәрдә открыткалар язам. Кул белән язган сүзләр күңелне җылыта, ниндидер бер дулкынлану хисе туа. Миңа тамашачыларым да чәчәк бәйләмнәре белән открыткахатлар бирәләр, аларны бик яратып кабул итәм. Әйдәгез, барыбыз да «Миллиард татар» сайтына теркәлеп дуслашыйк, берләшик, бер-беребезгә хатлар җибәрик әле!

«Миллиард татар» сайтына керүгә , «Открытка җибәрергә» дигән язу күзгә чалыныр. Иң элек шуңа басып, теркәлеп куярга кирәк.


Электрон адресны яздым, инде үзем өчен пароль уйлыйсы, ди. Тә-әк, парольләрнең онытыла торган гадәте бар, шуңа күрә мин аста күрсәтелгән социаль челтәр аша кердем. Һәм менә экранда открытка алыр өчен тутырырга кирәкле форма күренде. Исем, фамилия, төгәл адрес... Шулай итеп, «Открытка җибәрү» дигән өлешкә дә килеп чыгабыз. Монда посткроссинг аша хат алышу кагыйдәләре язылган. Эшне тәртип белән алып бару өчен, анысын да укып чыгу мөһим!

Барысы да үтәлде һәм (монысы минем өчен иң дулкынландыргыч мизгел булды!) «Адрес алу» дигән язуга басабыз. Конвертка кайсы шәһәрнең адресын язасы булыр икән?!

Новороссийск! Минем әле бу шәһәрдә булганым юк. Әмма миңа чаклы хатым бара торуына сөендем генә! Хат алучының исемен язмыйм, чөнки посткроссинг «уенының» бөтен сере дә шунда – почта тартмасыннан көтелмәгән (кемнән киләсен белмәгән) хат алу!

Адрес ачыклангannан соң, «Миллиард татар» сайтыннан туры «Хатлар йорты» интернет-кибетенә күчәргә дә мөмкин. Открытканы шуннан гына сайлап та җибәрергә була икән. Яки үзең кулдан язарга да. Ә мин хатымны үзем почтага илтеп салачакмын! Һәм кү-ү-үп итеп көтелмәгән хатлар көтәчәкмен!

ТАТАРЧА ПОСТКРОССИНГНЫҢ ТӨП КАГЫЙДӘЛӘРЕ



Инфографика: Камилә Димөхәмматова.



Фәнис ҖИҺАНША,
Татарстанның атказанган артисты


– Берсендә театр мине Кавказга ялга җибәргән иде. Шуннан инстаграмда язылучы дусларыма хатлар, открыткалар җибәргәләдем. Көтелгәннән дә җылырак кабул иттеләр! Татар посткроссингы барлыкка килгәч, туры эфирда Энҗе белән бергәләп Черкесск шәһәрендә яшәүче татар гаиләсенә Рамазан ае белән котлап открытка җибәрдек. Открытка язу да, алу да күңелле инде ул. «Миллиард татар»да теркәлүем дә юкка гына түгел. Үземнең дә күп итеп хатлар аласым килә. Языгыз!

Посткроссингта катнашу өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз. 16+



РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

Татарстанның Балык Бистәсе районы Югары Тегермәнлек авылында яшәүче тыл һәм хезмәт ветераны Каләмгөл Мөхәммәтшина тормышы күпләргә үрнәк булырлык. Ул үзе зур бер тарих! Быел Каләмгөл апа 90 яшьлек юбилеена әзерләнә. Кызыклы да, авыр да язмыш кичереп, ул хәзер Зәкия апасының кызы Гөлчирә Касыймова тәрбиясендә көн күрә. Бик атаклы нәсел дәвамчылары алар.


Фото: автор

Рахман ШӘФИГУЛЛИН

ТОРМЫШ АРБАСЫНА ҖИГЕЛЕП...

Балык Бистәсенең Балтач (Юлсубино) авылында Боҗырлар нәселен белмәүчеләр юктыр, мөгаен. Бер дигән балта осталары! Дуга бөгү, чана-арба ясауда аларга тиңнәр юк. Шушы нәсел егете булган Ярулла, заманында патша армиясенә чакырылып, Кавказда егерме биш ел солдат хезмәтен үтә. Балта эшенә маһирлыгы монда да ярап куя. Авыр йөкне җилкәләрендә ташучы җирле халыкны кызганып, аларга җиңел кул арбасына кадәр ясап бирә ул. Грузиннар бу уңайлы арбаларны «татар арбасы», дип йөртә. Тау-таш арасыннан йөк ташыр өчен гаять чыдамлы итеп ясалган, тимер кыршау белән ныгытылган тәгәрмәчләргә шакката алар.

Солдат хезмәтен тутыргачы ук Ярулла Әл Кутаисида мөселман кызы Фатыймага өйләнә, уллары Мөхәммәтша туа. 1870 елда үзенә күрә баеп, Балтачка кайтып урнашалар. Дәүләт җир һәм шактый күләмдә пособие бирә. Аннан уллары Нурмөхәммәт, Мөбарәкша, Мөхәммәтхан туа. Алар да ата-бабаларының һөнәрен дәвам итә.

Шулай матур гына яшәгәндә беренче бөтендөнья сугышы башлана. Аннары революция... Егерме беренче елгы ачлыктан исән калып, хәл җыярга да өлгермиләр, индустрияләштерү, авыл хуҗалыгын күмәкләштерү китә.

Ярулла солдат малае Мөхәммәтшага авыл советында эшләүче Гыйльфан кайгылы хәбәр җиткерә: «Әгәр Нурмөхәммәт белән Мөбарәкша колхозга кермиләр икән, аларны кулга алачаклар». Ярулла улларын киңәшкә җыя. «Властьны җиңеп булмый. Иртәгә үк эш коралларыгызны «сәвит»кә илтеп бирегез! Бер каныксалар, тынгы бирмәсләр, монда кала алмассыз», – ди. Нурмөхәммәт белән Мөбарәкша әтиләре кушканча эшлиләр дә авылдан китү хәстәренә керешәләр. Нурмөхәммәт гаиләсе белән Лаеш районы Красное Знамя авылы янындагы

урманга килеп урнаша: алты баласы һәм хатыны белән землянкада яши башлый. Тырыш гаилә көзгә инде яңа йорт, терлек-туар өчен каралты-кура җиткерә. Арба-чана ясау, дуга бөгү – аларның яшәү чыганагына әйләнә.

Мөбарәкша исә Балык Бистәсенең ашлык кабул итү пунктына балта остасы булып урнаша. Кулга алынган бер байның бакчасындагы җәйге йортында – флигелендә яши башлый. Шунда мич чыгара, кыш чыгарлык хәлгә китерә. 1933 елның май башында хатыны Бибигөл сыйган кадәр мөлкәтен ике «уфалла» арбасына төяп, биш кызы белән ире янына юлга чыга. Туган авыллары белән елый-елый саубуллашалар. Ул арада коеп яңгыр яварга тотына. Болай да кибеп өлгермәгән юл тоташ сазлыкка әйләнә. Таң алдыннан юлга чыккан гаилә төнге уникеләрдә генә Балык Бистәсенә килеп җитә. Уңган-булган кешеләр монда да шушы кечкенә генә өйне, чүп баскан бакчаларны тиз арада гөл кебек итә. Җиде класс белем алган кызлары Зәйтүнә почтага эшкә керә. Сәүдә эшенә куллары ятып торган Боҗырныкылар пристаньда өчпочмактыр, кумәчтер сата. Сату эше әкренләп файда китерә башлый. Ул арада инде Каләмгөлгә дә алты тула. Тизрәк мәктәпкә барасы, укыйсы килә...

Ләкин 1937 елны әтиләре Мөбарәкшаны кулга алалар. Имештер: «Халыкның ашарына юк, ә ашлыкны баржаларга төяп каядыр озаталар», – дип әйткән... Аны Чистай төрмәсенә үк алып китәләр. Суд өч айдан соң гына була. «Әтине күрергә барыбыз да бардык. Танырлык та түгел иде. Йөзен сакал-мыек баскан, күз төпләре янган...» – дип искә ала ул хәсрәтле көннәрне Каләмгөл апа.

Тагын бер елдан әтиләренең вафат булу хәбәрен җиткерәләр.

1939 елны Фин сугышы башлана. Озак бармый ул. Җиңелгән Финляндия чиктәш җирләрен Россиягә калдыра – ил чиге йөз илле километрга күчерелә. Финнардан бушаган җирләргә совет халкын күчерү бурычы куела. Биш кызы белән Бибигөл дә шунда китәргә карар кыла. Балык Бистәсендә яшәп җиде елда тупланган байлыкны таныш-белешләргә өләшеп, гаилә финнар иленә кузгала. Әле кайчан гына үзләре өчпочмак саткан пристаньда пароходка утырып, Казанга кадәр баралар. Кызлар пароход култыксасынаябышып, елый-елый җырлый: «Караңгы төн, томанлы көн – без аерылган көн бит ул...» Казаннан – Мәскәүгә, аннан инде Ленинградка килеп җитәләр. Вагоннардан төшү белән аларны брезент белән каплаулы машиналарга төяп, элеккеге Финляндия җирләренә алып китәләр. Һәр гаилә бер-берсеннән яртышар чакрым ераклыктагы хуторларга урнаштырыла. «Монда яшәр өчен бөтен уңайлыклар да бар, кадерен белегез!» – ди аларны озата килүче хәрби кеше. Финнарның да үзләре тырышып тапкан бу байлыкларны читятларга калдырып китәселәр килмәгәндер инде. Ләкин кызлар болын кадәр өйдә, зур хуҗалыкта бер генә җимерек әйбер дә тапмыйлар. Атна-ун көн савылмаган сыерлар, кош-корт каршы ала яңа хуҗаларны. Финнарның яшәү рәвеше безнекеннән аерылып торса да, малтуарны ашату, тәрбияләү кайда да бертөрле эш инде. Чәчү җирләре дә күп икән. Нарат бүрәнәләрдән салынган йорт чип-чиста күлгә карап тора. Ә анда бәбкәләрен ияртеп каз-үрдәкләр йөзеп йөри. Мондый зур хуҗалыкны тотар өчен нык бәдәнле ир-егетләр кирәк. Ләкин Боҗыр нәселе бирешә торганнардан түгел: кызлар монда да сынатмый. Татар халкы үз тормышын җиңел кул арбасыннан башка күз алдына да китерә алмый, ә финнарда ул булмаган, күрәсең. Кызлар хуторны бетереп эзләсә дә, андый арбаны таба алмый.

Кешене өмет яшәтә. Бүгенгә түзсәк, иртәгесе көн яхшырак булыр дип өметләнәбез.

Ак төннәр тәмамланып көзгә кергәнче, барлык игеннәрне дә җыеп алырга өлгерәләр. Малларга да җитәрлек итеп печән әзерләнә. Зәйтүнә белән Мәрьям хәрби частька эшкә керә, Зәкия, Факия һәм Каләмгөл исә элек фин балаларыныкы булган мәктәпкә укырга йөри. Бибигөл кызларын үзебезгә хас аш-су пешерергә дә, кул эшләренә дә өйрәтә. Биш кызын биш төрле сукмак көтә бит алда, берүк бәхетләре генә булсын...

Сугыш башлану хәбәрен басуда ишетә алар. Барча халыкка кичекмәстән эвакуацияләнергә әмер бирелә. Юлдагы халык, ыгы-зыгыны күрсәң!!! Поездларга утыру мөмкин түгел, халык җәяүләп тылга таба агыла. Гаиләләрне баржаларга төяп, Волга–Балтыйк каналы аша Рыбинск шәһәренә озаталар. Кайту бер айга сузыла. Фашист самолетлары баржаларны көндез бомбага тота. Шуның өчен юлны бары тик төнлә генә кичү мөмкин була. Бибигөл апа август башында гына биш кызы белән Балтачка кайтып җитә. Исән калуларын чын могҗизага тиңли алар. Үзләре белән берни алырга өлгермиләр, бары тик фин истәлеге итеп сөт сепараторын гына алалар. Ярый әле тирә-күрше, туган-тумача ярдәмчел: тормышны өр-яңадан башларга булышалар.

Никадәр авыр булса да, дөнья бер урында тукталып калмый. Гомер тәгәрмәче гел хәрәкәттә. Апалары берәмберәм үз гаиләләрен кора. Каләмгөл исә Факия апасы янына – Урал якларына китеп, заводка эшкә урнаша. «Миңа 16 гына яшь иде. Эше булгач, авырлыгын уйлап та тормадым. Металл эшләнмәләрне чыныктыра торган зарарлы цехта эшләдем», – ди ул.

Шушында туып-үскән Вазыйх исемле егет белән тормыш кора. Гомере буена зыянлы эштә эшли. Алар яшәгән җиргә якын гына яңа коралларны сыный торган полигон була. «Полигон читендәге аланда җиләкләр җыеп ашый идек. Аларның куркыныч булуын кем белгән ул вакытта?!» – ди бу дөньяга җиде бала тудырып та, җидесен дә бер-бер артлы җир куенына сала барган ана. Соңгы ике баласы 15–16 яшендә вафат була. Радиация аркасында, диләр... Факия апасы да озак яшәми. Каләмгөл апа аның ике баласын үзе үстерә.

Утны-суны кичкән татар кызы Каләмгөл Мөбарәкша кызының көчле рухына ничек сокланмыйсың да, аның белән ничек инде горурланмыйсың?!

PRESSA



ҮЗЕҢӘ ЫШАНЫРГА КИРӘК



Лариса
ХӘМИТОВА

– Кемгә кирәгең бар соң синең? Кая китә алам дип беләсең? Башта үзеңә кара...
Бу кимсетү, түбәнсетүләрнең очы-кырые булмас кебек иде. Ничекләр генә итеп аларны ишетмәскә соң? Колакларымны каплап карыйм, әмма өстемә туфан кебек бертуктаусыз явып торган бу ямьсез сүзләр, лайлалы пычрак кебек барыбер бармак араларымнан үтеп керә... Җаныма ук уза... Аңымны томалый... Башымда бер генә уй бөтерелә: «Ничек?! Ничекләр мин бу кешене кайчандыр ярата алдым икән?! Ялгышканмын, бигрәкләр каты ялгышканмын лабаса!»

Әйтерсең лә алдымда торган ниндидер пәрдәне алып ташладылар һәм моңарчы бәйләүдә булган күзләрем ачылды.

Ниһаять, ул туктады. Арыды бугай... Бу мизгелләрне дә күрер көнем бар икән. Сәгатькә күзем төште. Төнге өч! Аякларымны көчкә сөйрәп барып, караватыма йөзтүбән капланам. Җанда – бушлык, күңелдә – чарасызлык, тәндә – хәлсезлек... Башта уйлар өермәсе – бу тәмугтан качасы һәм ул беркайчан эзләп тапмаслык урынга барып яшеренәсе иде бит. Күзем күрмәсен, колагым ишетмәсен иде аны – дөньяда барлыгын да онытасы иде...

Хәзер, бу вакыйгалардан соң инде берничә ел узгач, уйлап-уйлап та ул вакытта үземне нигә шулкадәр мыскылларга рөхсәт итүемне, көчсезлегемне аңлатырлык бер сәбәп тә таба алмыйм. Ахырда: «Миңа, күрәсең, корбан ролендә булу ошагандыр», дигән нәтиҗәгә киләм. Җайлы бит: үз тормышың өчен җаваплылыкны кемнеңдер җилкәсенә саласың да, агым уңаена агасың да агасың... Бернәрсә уйламыйсың, беркая омтылмыйсың, тормышыңны үзгәртү өчен бер адым да ясамыйсың... Кая гына барсам да, кара сакалым үземнән калмас, дип язмыш белән ризалашу булдымы икән соң, белмим. Алай дисәң, күңелнең кайсыдыр бер почмагында бу җәһәннәмнән котылу теләге яшәгән бит. Аннан ул теләк үскән, зурайган...

Ялваруларым, көне-төне теләгән теләкләрем, ниһаять, Аллаһы Тәгаләгә барып иреште: иремнән аерылдым. Никадәр авыр, катлаулы булса да, ясадым бу адымны... Ул миннән моны, әлбәттә, көтмәгән иде. Хәтта фатирны да бүлеп ала алдым. Монысы бөтенләй могҗиза булды... Үзем белән булган әлеге яңалыкларга шулкадәр шат идем дип әйтү – бернәрсә дә әйтмәүгә тиң. Сүзләр таба алмыйм... Яңа фатирымны шунда ук яраттым. Аңа гашыйк булдым! Менә җәннәт кайда икән ул: сине берәү дә юкка битәрләми, түбәнсетми, начар сүзләр әйтми – җаныңны кыйнамый... Үземне ул көннәрдә тимер читлектән котылган кошчык кебек хис иттем.

Бар да әкрен генә бер эзгә төште. Мин дә яңа дөньяма ияләнә башладым. Тормыш матур икән бит ул! Хыялларым да бар икән минем һәм күп икән. Хәзер инде йокларга ятканда татлы уйларга чумам: үзем барасы яңа матур шәһәрләрне күрәм, зур аэропортларны, хәтта аэропортта очкыч көткәндә эчәсе каһвәнең хуш исен тоям...

Күктән эзләгәнне җирдән бирермен дигәнме әле Ходай? Берничә айдан миңа яңа проектта катнашырга тәкъдим иттеләр. Яңа эшем командировкалар белән бәйле иде. «Бөтен ил буйлап йөрергә туры киләчәк», – дип кисәттеләр. Тәвәккәлләп ризалаштым. Күңелдәге икеләнүне, куркуны җиңеп, әлбәттә. Белемемне, мөмкинлекләремне кулланудан тыш, хезмәттәшләремне яңа үрләр яуларга, нәтиҗәле эш башкарырга рухландырырга да кирәк булачак иде.

Новосибирск шәһәренә булган беренче командировкамны һич онытасым юк. Урамда 40 градус салкын. Офистагы кызлар мине туннар киеп каршы алды. Күзләрендә – битарафлык, өметсезлек... Күбесенең өстәл тартмасында эштән китү турында гариза ята икән инде. Нишләргә? Бу күзләрдә ничек итеп ышаныч уты кабызырга?

Кызларның һәрберсе белән аерым сөйләшкәндә бер нәрсәне аңладым: барысының да проблемасы бер икән аларның – үз-үзләренә шикләнеп карау, үз көчләренә ышанмау, киләчәктән бернинди яхшы әйбер көтмәү... Баштан кичкән хәлләр... Боларның барысы да эшкә тәэсир итүенә шаккатасы да юк. Бигрәк тә шәхси тормышка. Хәер, анысы кызларның күбесендә юк дәрәҗәсендә. Үзеңне үзең дә яратмагач, башкалар сине ничек яратсын инде?!

Мин алар күңеленә юлны җиңел салмадым. Тамчы тамган кебек, әкрен-әкрен генә... Үз башымнан кичкәннәрне сөйлим: «Мин булдырдым бит, тормышымны үзгәрттем, димәк, сез дә моны эшли аласыз!» – дим. Ихласлыгым бөтен каршылыкларны җиңде. Кызлар күз алдымда үзгәрде – күңелләрендәге боз эри башлады. Күзләрендә очкыннар пәйда булды. Өмет уянды! Бу эшебезгә дә тәэсир итми калмады. Дөрес, кем беләндер бөтенләйгә саубуллашырга, ә кемнедер яңа максатлар куярга рухландырырга туры килде. Әмма без барыбыз да бер нәрсәне аңладык: гомер бер генә, аны мәгънәсезгә, бушка уздыру ярамый. Тагын – үз кадереңне үзең белергә өйрәнергә кирәк, шул очракта гына сине башкалар да хөрмәт итәчәк. Новосибирск шәһәреннән мин ниндидер бер җиңеллек белән кайтырга кузгалдым: теләгемә ирештем – аларның тормышын үзгәртә алдым. Кызлар белән аерылышасыбыз да килмәде хәтта...

Икенче командировкам мине көньякка алып килде. Новороссийск каласына. Герой-шәһәргә! Беренче аяк баскан минутларымны һич онытасым юк: кояшның кайнар нурлары тәнемне иркәли, әйтерсең лә яраткан иреннәр кагыла һәм бөтен гәүдәм буйлап дулкыннар йөгерә... Авызда – тулышып пешкән җиләк-җимеш тәме. Аларның баллы, татлы исе колагыңнан да, чәчләреңнән дә, бөтен тәнеңнән дә килә кебек. Аңыңны томалый!.. Яңа коллектив минем алга бурычларның өр-яңаларын куйды. Монда барысы да киресенчә иде. Көньяк климаты кешеләрнең холыкларында да чагылыш тапкан: бирелә барысы да шат күңелле, беркая да ашыкмый – шул исәптән эшкә дә. Алар, гомумән, тормышларыннан бик канәгать...

Яңа энергия белән җиң сызганып эшкә тотындым. Һәм ул миңа шатлык кына иде!

Көннәр бер-бер артлы уза торды.

Шимбә-якшәмбеләрне, әлбәттә, күбрәк диңгез янында уздырырга тырыштым. Ялгыз калып, дулкыннар шавын тыңлап утырыр, җаныма көч алыр өчен аулаграк урыннар

Фото: www.pixabay.com

Кеше шулай яратылган инде: без беркайчан булганыннан канәгать түгел, һаман нидер эзлибез.



■ Нигезеннән башлап түбәсенә кадәр төзелеш белән җитәкчелек итүне үз кулларыма алырга туры килде.

эзлим. Һәм табам! Шундый көннәрнең берсендә аякларым зур булмаган бер аланга алып килде. Тирә-юнен биек-биек таулар чорнап алган әлеге аланда басып торганда, бер нәрсәне аңладым: минем урыным монда, менә шушында – Кара диңгез буенда яшәргә һәм эшләргә телим! Күңелеңдәге барлык начарлыкларны үзе белән юып алып китә һәм сиңа яшәргә көч бирә торган диңгез ярында…

Әйе, менә шулай кинәт һәм бик тиз хәл иттем: калам!

Мине бу фикеремнән берәү дә кире чигендерә алмый инде. Булачак кунак йортым бөтен уйларымны биләп алды. Өндә дә, төштә дә шуның белән саташам. Агачтан төзиячәкмен мин аны. Ул агачның исләрен дә сизәм, бүлмәләрдә нинди җиһазлар буласын да беләм. Китап киштәләренең кайда урнашачагына кадәр! Өй каршында яшел чирәм үсәчәк, тирә-якта яраткан розаларым, гортензияләрем чәчәк атачак… Койма кырыена груша, шәфталу агачлары утыртачакмын. Ә йортымны виноград тәлгәшләре уратып алачак…

Гади генә йорт булмаячак ул! Аның ишекләре бу катлаулы дөньяда үз-үзен эзләүче, үзе ни теләгәнен аңларга тырышучы хатын-кызлар өчен һәрвакыт ачык булачак. Мин инде ул ханымнарның тавышларын ишетәм, күз карашлары белән очрашкандай булам, алардан килгән энергияне сизәм, бирәчәк сорауларына җавап эзлим…

Кеше шулай яратылган инде: без беркайчан булганыннан канәгать түгел, һаман нидер эзлибез: зур акчалар артыннан куабыз, бизнес турында хыялланабыз, карьера баскычыннан күтәрелергә, яңа илләр күрергә телибез. Хыяллар картасы төзибез, аффирмацияләр пышылдыйбыз, курсларга, тренингларга йөрибез… Әмма боларның кайсы синеке икәнен ничек белергә соң, ничек адашмаска? Үз-үзеңне, Җирдәге урыныңны тапканда, дөньяга нигә килгәнеңне аңлаганда гына җаннарга тынычлык урнашачак – Галәм белән бер дулкында булачаксың…

Хыяллар биеклегеннән мине… пандемия тартып төшерде. Бөтен кешенең телендә бер сүз: «Ковид…» Тормыш бер мизгелдә үзгәрде дә куйды. Беренче мәлдә хәтта югалып та калдым: тәвәккәллегем, батырлыгым да әллә кая китте – кулымнан эш төште. Әмма чит шәһәрдә эшсез һәм бер ялгызым торып калгач, шуны аңладым – бу минем өчен тагын бер сынау. Аны ничек узам – киләчәк тормышымның ниндилеге шуннан торачак.

Үткәннәр белән мине инде берни дә бәйләми иде, аяк-кулым чишелгән – балаларым үсеп буй җиткән. Олы улымның үз гаиләсе бар, кечесе дә аның үкчәсенә басып килә. Димәк, алар хәзер адым саен минем кайгыртуга мохтаҗ түгел.

Әллә көтелмәгән бер могҗиза булды, әллә ихлас теләкләрем, чыннан да, тормышка ашты – фатирымның сатылуын сизми дә калдым. Ә иң мөһиме – диңгез буендагы җир участогының хуҗасы нәкъ шул көннәрдә ике як өчен дә файдалы тәкъдим белән чыкты: ул миңа җиренең бер өлешен бирә, ә моның өчен мин аны карап-тәрбияләп торырга тиеш булачакмын. Карамыйммы соң, әлбәттә, карыйм!

Булачак йортның проекты да бик тиз табылды. Һәм күптән көтелгән төзелеш эшләре башланып китте…

Һәр көнне таң белән уянам да, бетмәс-төкәнмәс проблемаларны хәл итәргә керешәм: йортның фундаменты ничә сантиметр булырга тиеш, стеналарының калынлыгы, вентиляция тишекләре, коммуникация урыннары, җылылык изоляциясе…

Төнгә каршы җеп өзәр хәлем дә калмыйча, урыныма барып авам. Ару-талуның очы-кырые булмас төсле иде. Кайчагында баш миенә сатлыкҗан уйлар да кереп оялый. «Йә, нәрсәгә дип бу кадәр интегәм соң әле мин?» – дим. Әллә барысына да кул селтәп, әни янына кайтып китимме, яртылаш төзелгән йортымны сатыйммы дим. Әмма секундның икенче мизгелендә инде берничә ел элек булган хәлләр күз алдына килеп баса: мин шулай ук караватта капланып ятам, тәнемдә шундый ук арыганлык… Әмма аерма зур иде шул: ул чакта иремнең мыскыллау, рәнҗетүләреннән туеп арыган булсам, хәзер тәнемдә дә, җанымда да бөтенләй башка халәт. Бу – гаҗизлек түгел, минем ныклыгымны тагын бер кат сынау гына. Дөресрәге, хыялларымны тормышка ашыру өчен көрәш.

Ә аннан әкрен генә алсу таң ата. Тәрәзәдән искән йомшак җил чәчләремнән иркәли. Торырга вакыт: яңа көн белән мине яңа мәшәкатьләр көтә: ишекләр сайлыйсым бар, обойлар, тәрәзә йөзлекләре…

Һәм, ниһаять, ул көн җитә: бригадир учларыма әзер өемнең ачкычларын сала. Кинәт кенә йокымнан уянгандай булам. Беренче кат күргәндәй, кулларыма карыйм: кояшта янып каралганнар, сыдырылып, тырналып, сөяллләнеп беткәннәр… Шулчак керфекләремнең чылана баруын тоям… Әллә ару-талчыгуларым шулай чыга, әллә шатлык яшьләре бу… Булдырдым бит! Хыялымны чынга ашырдым! Әйе, чынлап торып теләсә, хатын-кыз көчле дә була ала…

Кунакханәм кунаклар кабул итәргә әзер! Рәхим итегез!

РЕЗИДЕНТ TMTV

БЕЗГӘ
ЯҢА ЙОЛДЫЗ 2
КИРӘК!

ДӨНЬЯ СИНЕ ИШЕТЕРГӘ ТИЕШ!

КАСТИНГ СТАРТ АЛДЫ
WWW.TMTV.TATAR

РЕКЛАМА 6+

PRESSA

Белмим, әллә элгәреге тормышта тауларда яшәдемме икән соң? Тау сүзен ишетүгә, эрим дә китәм. Бу юлы да шулай булды. Ике көннән китәбез, дип, Дагстан тауларына чакырдылар. Юл биштәрем аркама асып, көзгегә карадым да: «Мин һәрвакыт әзер!» – дип елмайдым.

Гөлүсә ЗАКИРОВА

БИШТӘР АСЫП... ДАГСТАНГА!

Тауларга мәхәббәт

Тауларга җыенган, әле инстаграм аша гына таныш ун туристны ни берләштерә? Тауларга мәхәббәт! Тагын – дүрт көнгә генә булса да тормыш режимын көйли алу. Командада йөри белү. Сәяхәтнең кайбер көйсез моментларында нык булу. Һәм Аллаһның менә бүген биргән нигъмәтләренә шөкер итү. Беребез дә лакшери-сәяхәт көтми, аркада – биштәр, йөрәктә – таулар бөеклеге...

Танышабыз. Җитәкчебез – Алена. Тәҗрибәле, белемле турист. Кайда гына йөрмәгән: Алтайны да гизгән, Байкалда да булган. Беренче тапкыр үзенең команда туплавы. Борчыла. Ә команда шәп күренә: кемдер волонтерлар белән эшли икән, кемдер кимчелекле балалар белән хәйрия акцияләре үткәрә, экстремаль спортны үз итүчеләр дә бар, җимеш төшеннән тропик агачлар үстерүче, фатирникларда гитарага җырлаучы, каһвә яратучы, массаж ясаучы, язучы... Бер сүз белән әйткәндә, барыбыз да бер рухтагы кешеләр – яшәүдән тәм табучылар.

...Дагстанга төн уртасында барып төштек. Һәм маҗаралар башлануын шунда ук сиздек. Аэропорт бинасы тулы барысы да гел карадан киенгән кешеләр. Шикләнебрәк калдык... Ни булыр бу? Куркырлык бернәрсә юк – бер нәсел туганын каршы ала икән. Барысы бергә шулай җыелып килгән. Ак сакаллы, таякка таянган бабайларына кадәр! Кочаклашалар, елашалар... Озак еллар кайтмаган булган, ахры, туганнары... Алар шау-гөр килеп чыгып киткәч, аэропорт бушап калды.

Ишектә безне каршы алучы авар егете Абдрахман күренде. Үзебезчә сөйләшә-көлешә ун кешелек минивэнга төялдек. Абдрахман безне дүрт көн буе озатып йөриячәк.

Беренче үр

Иртән Гуниб районының Хиндах авылында уяндык. Караңгы тау юллары аша өч сәгатьләп изрәп барып, ничек итеп караватка кереп ауганны сизми дә калганбыз... Дагстанда будильник кирәкми – кояш нуры битеңә төшүгә, йокың туеп, күзең ачасың. Һәм ни күрик: алда – упкын, артта – кыя! Ташлар арасында йортлар салуларына шаклар катарлык! Кояш нуры өрек, чикләвек агачларының инде тулышып килгән бөреләренә кагыла. Күтәрелеп карасаң, башыңнан бүрегең төшәрлек кыя түбәсенә кагылып, бөркет йөзә... И-и тәмле иртә! Тын һаваны күкрәк тутырып суласаң, башлар әйләнә. Кунак йорты хуҗалары инде табын хәстәрләп йөри – агач өстәл тирәсенә елышабыз. Бар да өйдәгечә. Мырлый-мырлый (тел йотарлык тәмле!) өрек боткасын сыпыртабыз. Өрекне пешерәләр дә, туглап, бодай оны кушалар икән. Шуны урбеч белән ашыйсы. Көн буена җитәрлек энергия бирә ди. Ә безгә ул бик кирәк, чөнки беренче үр – Гамсутль: тау башына менәсе. Үзебез белән гитара да алабыз – менеп җиткәч, хәл калса, җырлашырбыз.

Гамсутль – тау башында урнашкан, ике мең елдан артык тарихы булган «өрәк-авыл». Әле элгәре чорларда ук басып алучылардан туйган тау халкы әнә шулай кыяларга «оя корган». Анысы да монысы – авылның иң соңгы кешесе Абдулҗәлил ага моннан алты ел элек кенә вафат булган. Шәһәрдә яшәп арганнан соң, бирегә – нәсел тамырлары тоташкан нигезгә кайтып төпләнгән булган. Чишмәгә дә 500 метр аска төшеп йөргән ул. Ут кермәгән... Күз алдына гына китерегез: өй ишеген ачып җибәрәсең, ә аста – упкын! Ул бабайны таулар рухы чакырып кайтарган булгандыр. Анда сулыш алуы да башка, киңлек, кай якка карама – ак карлы тау түбәсенә кагылыр-кагылмас йөзеп йөргән болытлар.

Күз алдына гына китерегез: өй ишеген ачып җибәрәсең, ә аста – упкын!

Әзерлексез кешегә тауга менү бер җәфа икән! Башта безгә кызу тоелды: курткаларны салып билгә бәйләдек (кан йөри башлады). Ярты сәгатьтән аяклар атламас булды, күкрәк кыса, сулыш алулары читенләште (үпкәгә кислород тулды). Туктап, күнекмәләр алабыз: авыз белән түгел, борын белән суларга кирәк икән. Атлый торгач, туңдыра башлады, тиз генә киенеп куйдык (тауның кар яткан өлешенә аяк басканбыз). Күзне ачып булмаганын язып тормыйм – кояшлы, карлы тау башына кара күзлексез менәсе дә түгел. Тагын бер киңәш: тауларга киеп менәсе киемнәрне алдан ук кайгыртып барырга кирәк. Гадәти кроссовкалар биредә ярамый, треккинг аяк киеме кирәк. Үзем барып күргәч әйтә алам: аяк шуып китәрлек тайгак, куркыныч урыннар монда адым саен. Махсус ботинкалар гына коткара! Алар белән ышанычлы атлыйсың. Термокиемнең шәплеген дә сиздем: кызуда тирләтми, салкында туңдырмый!

Тау юлында табигать күренешләре диафильм караган кебек алмашынып тора: артыш куаклары, көздән калган гөлҗимешләр гирлянда кебек озата бара, тау каеннары, ара-тирә яфракларын да коярга өлгермәгән ут кебек сары имәннәр дә очрап куя... Чишмәгә җиткәч, җәен капка төбенә кич утырырга чыккан кебек, бүрәнәгә тезелешеп утырабыз да хәл алабыз. Күңелдә эйфория (тау түбәсенең билгеле бер ноктасына җиткәч, организмда эндорфин бүленә башлый). Әмма озакка түгел. Калган мең метрга якын араны актык көчләрем һәм мамыкка әйләнгән аякларым белән Берлинны алырга җыенган кебек үттем. Кояш нурында кар эреп, җепшек, баткак юл хасил иткән. Кинәт сул теземдә көчле авырту тоеп, чак кычкырып җибәрми калам. Җайсыз басмадым да кебек, әмма аякка көч килгән булып чыкты... Тау башына мин яралы солдат халәтендә менеп җиттем. Әмма мендем! Команда яхшы бит: резин бинт белән бүлешteләр – ныгытып бәйләп куйгач, аяк кайгысы беразга онытылды. Кыядан аска караш ташлагач, җырлашырга да, фотоларга төшәргә дә энергия табылды үзе.

Куркыныч рәхәт

Икенче көнне тарлавык белән шарлавыклардан башладык. Тик... интернетта язылганча ук булып чыкмады ул. Бер атнага иртәрәк килгәнбез: тауларда кар «уянырга» өлгермәгән. Таш-мәгарә эчендәге Салта тарлавыгында тын-

Автор фотолары

Мич авызына утын салып, ялкынында җылынып, үлән чәе йотып утыруның үз романтикасы бар!



■ Гамсутль авылында гел бер метр киңлектәге тау юлыннан гына йөрисең. Ә башың әйләнеп китсә? Ә ялгыш бассаң?..

■ Авар ханымнары камыр җәеп, чуду пешерә тора, без мактый-мактый ашый торабыз.







лык... Карадах тарлавыгы исә Дагстанның уникаль табигать объектлары исемлегендә. «Могҗиза капкасы» дигән атамасы да бар. Менә без дә бер-берсенә терәлеп диярлек торган ике тау арасыннан уздык һәм... гаҗәпләнүдән «аһ» иттек. Әкият дөньясына эләккән кебек! Әйтерсең лә, таш капка ярыгыннан үтеп, гүзәл бакчага чыктыкмыни! Тау битендә чыршылар сибелгән. Уртадан җәйрәп аккан тау елгасы ярларында әфлисун төсендәге вак җимешле сырганаклар тезелеп киткән. Акустиканы әйтә торган түгел. «Мин – татар!» – дип кычкырсаң, кайтавазы таш-кыяларга бәрелә-бәрелә, Дагстанны урап, Ватаныбызга кайтып ирешер шикелле... Чиратта – тау башына урнашкан Гоор авылы. Монысы ташландык түгел, халык яши торганы. Кызык булырга охшаган!

Гоорга кояш шәфәкъ ягына авышканда гына барып җиттек. Борма-борма тау юллары асфальтның ни икәнен дә белми... Бер урында ремонт эшләрен башлаганнар үзе. Зур йөк машиналары таш ташый. Алгарак узып булса да әйтим, кайткач, яңалыклардан укып белдек: икенче көнне шушы урында, таш төялгән машина авырлыгын күтәрә алмыйча, күпер ишелгән...

Әлегә без Гоор табигатенә сокланып торган мәл. Авылда тормыш гөрли: бикле булса да, мәдәният йорты, кибете бар. (Без моңарчы булган авылларда кибетләр, гомумән, күренмәде.)

Бер гаилә безне төшке ашка чакырды. Комганнан су агызып кулларны юдык та, агач өстәл артына кош балалары кебек тезелешеп утырдык. Туңганбыз икән (карлы тау башында йөрибез бит!). Кайнар ризыктан йөзләребез алсуланып китте. Агач куштабаклардан итле, бәрәңгеле, эремчекле курсу ризыгы да «очты» гына. Аннан тау сырганагы кайнатмасы белән чәй килде. Аның тәмлелеге!..

Әле тау үренә менәсебез бар. Анда да җәяү теркелдисе. Тезем сызлаганга чыдап булмый, тамак тую белән генә басылырга уйламый да. Ярый әле авыртуны җиңеләйтә торган көчле дарулар алган идем. Башкалардан аерылып каласым килми – көн дә Дагстанга килмим бит...

Авар халкының зиратлары үзенчәлекле икән. Тау битенә янәшә диярлек тезелгән кабер ташларына төрледән-төрле тасмалар тагып чыкканнар. Күрәсең, мәҗүсилектән калган йоланы үтиләр. Менә безнең дә сукмак каберләр арасыннан уза... Күңелдә әллә нинди каршылыклы уйлар: үзебез тау башына менәбез, тик нигәдер вакытны артка күчереп, Гоор авылы кешеләренең борынгы бабалары белән күрешәбез төсле. Алар кайчандыр шушында – нәкъ менә тау башында гомер иткәннәр, ул авылны Кахиб дип йөрткәннәр. Борынгы таш корылмалар арасыннан төрбә сыман каберлекләр дә очрап куя, кызыл йолдыз куелган мосафир каберләре дә... Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун...

Тау башында безне алмаштырып куйдылармыни! Аякларны салындырып, упкыннан да курыкмыйча, кыяга кереп утырабыз! Дөресрәге, куркыныч һәм... рәхәт. Тау авыруы шундыйдыр инде: курку, саклану хисен оныттырып, адреналин бәреп тора! Кайберәүләр махсус матур күлмәкләр дә кыстырып килгән: калын курткаларын салып, салкыннан калтыранып булса да, аллы-гөлле күбәләкләр кебек фотога төшәләр. Норвегиянең танылган «Язык Тролля» дигән урынын барып күргән булмаса да, Дагстанның «Тролль телен» күрдек, дип көлешәбез.

Тауларда шундый нәрсә бар: кисәк кенә таң аткан кебек, кинәт караңгы төшкәнне дә сизми каласың. Бер мизгел һәм дөнья үзгәрә дә куя! Кайтыр юлга кузгалганда уч







төбендәгедәй җем-җем итеп утлары балкыган Гоор авылына кар бөртекләре төшә башлаган иде.

Ул кичне безне Гоцатль авылында яшәүче Зәйнәп ханымнар үз йортларында кундырдылар. Гаиләләре белән җылы итеп каршы алдылар, 8 Март хөрмәтенә хуҗа һәрберебезгә берәр лалә чәчәге дә бүләк итте. Зәйнәп ханым тарих укытучысы икән. Имам Шамил тарихын тыңлап, аздан гына йокыга китми калдык. Бездәге Тукай музееның Шамил йорты дип йөртелүен аларга сөйләп тормадым инде. Йокы килә иде, арылган... Чын...

Романтикалы маҗара

Таң белән Ирганай ГЭСына юл тоттык. Совет чорының зур казанышы! Суы фирүзә-яшел төстә. Көрән тауларның судагы чагылышы да иң матур буяуларны сеңдергән кебек. Зәйнәп апаның үләнле чәйләрен термоска ясап алган идек. Тау чамбыры, зәңгәр мәтрүшкә, бөтнек, гөлҗимеш, нарат бөресе... Кәртинкә кебек урында шундый чәй йотып утыру – каһвә-маһвәләр белән фотога төшү тренды гына түгел ул. Без инде бер гаилә кебек! Кирәк чакта тын калып та, «дзынь» ноктасы таба беләбез!

Казбек районы чигендә автоматлар аскан хәрбиләр туктатты. Кәефләре юк чакка туры килдек, ахры, паспортларыбызны җыеп алып тикшерделәр, нидер яздылар. Аннан, 15 минут вакытыбызны югалтып, юлыбызны дәвам иттек. Баксаң, боларның эшен тикшереп, 50 метр ераклыкта безнең «Ларгус»лар кебек камералы машина тора икән. Туктатмый кара! Кесәләребездән алып, инде онытыла башлаган битлекләрне дә киеп куйган идек...

Асфальт янә бетте. Тау юлыннан барабыз. Кемдер Рәсүл Гамзатовны укый. Сүзгә Абдрахман да кушыла: «Минә аның әтисе улыннан да көчле чичән иде. Туган авыллары Цадага да кереп чыгарбыз... Анда Гамзат агага куелган һәйкәл дә тора!»

Тик тагын бер маҗара: карлы юлда машинаның тәгәрмәче тишелде. Буран чыгарга җыенган кебек. Өстәвенә, беребезнең дә телефоны тотмый... Әлеге дә баягы кыю амазонкалар кебек, тәгәрмәчне алмаштырырга дип җиңнәрне сызганган гына идек, беребезнең МТС операторы тота булып чыкты (башка урында фәкать «Мегафон» һәм «Билайн» гына тота). Ярдәм чакырттык. Озак та үтмәде, ике иске «Нива» белән артыбыздан килеп тә җиттеләр. Алдагы төндә бик көчле буран булган икән: юлларга хәйран гына кар салган. Яшь чакта күрше авылга дискотекага барган кебек, сикәлтәле юллардан көлешә-көлешә базага да барып җиттек.

«Чишмә» крестьян-фермер хуҗалыгы икән монысы. Маллар асрыйлар, болынлыклары гына да фәлән хәтле! Соңгы елларда туристлар өчен кунак йортлары да төзеп куйганнар. Җылылык системасы юк, билгеле, әмма яга торган мичләре бар. Ул төнне безнең бүлмәдәге кызлар мине дежурга куйды: туңмас өчен мич авызына утын салып, черт-черт янган ялкынында җылынып, үлән чәе йотып утыруның, чынлап әйтәм, үз романтикасы бар! Тау астындагы Сулак каньонында көймәдә йөзгәндә таулардан агып төшкән шарлавык шавының да үз релаксы!

Иртәнге алтынчы яртыда барыбыз бергә кояшны каршы алдык. Аста яшел елан кебек каньон суы җәйрәп ята. Төне буе яуган карларга ак башлыклы тау артыннан калыккан кояш нуры куна. Ә без истәлеккә фотога төшәбез! Рәхмәт, Дагстан! Рәхмәт, таулар рухы! Безгә самолетка өлгерергә кирәк...

Янә «Нива»ларга төялеп чыкканда олы юлда тәгәрмәче төзек машинасы белән Абдрахман көтеп тора иде.

«ИҢ КУРКЫТКАНЫ – БЕЗНЕ КИРЕ КАГУЛАРЫ»



Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк Галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.

Фәнил ВАККАЗОВ,
җырчы, алып баручы;
гаилә стажы – 10 ел;
балалары – Нурбәк (8 яшь),
Алимә (3 яшь).

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Гомернең кайсы чорына җитүеңә карап үзгәрә тора ул. Яшьрәк чакта, әлбәттә, күбрәк күзләренә игътибар итәсең: кызларның күзләре белән очрашырга тырышасың. Аларның сиңа ничек каравы мөһим. Аннан икенче чор башлана – кием-салымнарына игътибар итәсең Бүгенге көндә исә беренче чиратта буй-сыннарына күз ташлыйм. Хәзер шундый заман: биттәге матурлыкны ясап та була, ә тән матурлыгына крем сылап кына ирешә алмыйсың – аны даими карарга кирәк. Аннан шунысы да бар: хатын-кызның буй-сыны зифа икән, аңа бөтен кием дә килешәчәк.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Бөтен нәрсәне дә гафу итәргә буладыр – беребез дә идеаль түгел. Кайберәүләр: «Хатын телефонга кереп китә дә дөньясын оныта», – дип зарлана. Минем бер дә алай әйткәнем юк. Чөнки беләм, ул анда эшли: нәрсәдер эзли, белешә, өйрәнә... Гомумән, бөтен тормышыбыз хәзер телефон аша бара бит.

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Бу сорауга җавапны озак уйладым... Мөгаен, аламалыкны һәм пөхтәсезлекне гафу итмәс идем. «Алама» дигән сүз мин әйтәсе мәгънәне төгәлрәк тә ачып бирәдер. Өс киеме бик кыйммәтле, тик тапланып беткән, өе зур, ләкин җыештырылмаган, машинасы затлы, әмма тузанга чумган, балалары шапшак... Юк, андыйны кичерә алмас идем.

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?

– Алар, чынлап та, бүленәме, белеп әйтәсезме? Миңа аның икесе дә мөһим. Хатын-кыз сине мактый, синең белән горурлана икән, димәк, ул сине илһамландыручы була инде. Иң мөһиме – артка гына сөйрәмәсен. Ә өйдәге комфортка килгәндә, ул яктан мин демократ. Бар эшне дә үзем эшли алам. Хатынымның да арырга, кәефе булмаска мөмкин икәнен яхшы аңлыйм.

5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Миңа калса, дус булырга тиеш тә. Тора-бара хисләр икенче төрле формациягә керә, тынычлана. Гел гыйшык утында янып яшәмисең. Хатыныңа булган мәхәббәтеңнең бер өлешен балалар үзләренә ала... Дус булмасаң, аңа үзеңнең серләреңне ничек ышанып тапшырасың? Аның белән ничек бер түбә астында яшисең? Кич кайткач, без дә икәү сөйләшеп утырабыз. Нинди генә тема кузгатмыйбыз?!

6 Хатынызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?

– Бөтенләй хәтерләмим! Хатыннан сорадым әле. «Казан» милли мәдәният үзәге янында ясадың», – ди... Иң беренче күрешүебез дә шунда булган иде. Без аның белән урамда таныштык. Дуслар белән машинада бара идек, өч кыз кул күтәрде. Ул чакта «мотор тоту» бик популяр иде. 2008 елның июне бу. Футбол матчы булган көн. Европа чемпионатында безнең җыелма команда җиңде. Шәһәр гөжли – бөтен җирдә күтәренкелек. Без дә дуслар белән шул эйфориягә кушылдык... Өчәү идек, тагын өч кыз да утыргач, сыеп булмый дип, кире кайтып, минем машинаны алып килдек. Икегә бүлендек, һәм ул минем машинага туры килде... «Татмак»ка барып пицца ашавыбызны хәтерлим – төне буе эшли торган бердәнбер җир иде бугай ул вакытта. Аннан «Казан» милли мәдәният үзәге янына киттек... Гөлназ – Казан кызы. Кыз сорарга барулар барысы да йолага туры китереп эшләнде. Апрельдә никахыбыз булды, ә туйны октябрьдә генә ясадык. Җәй – минем эш сезоны: туйлар алып барып акча эшләдем дә, көзен үзебезнекен бәйрәм иттек. «Иң беренче очрашкан урыныбыз дип, «Казан» милли мәдәният үзәге янына алып бардың. Тәкъдимне шунда ясадың. Чәчәкләр, балдак бүләк иттең», – ди Гөлназ. Хәтерләмим!..

7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Миңа калса, шулайдыр. Аны хәтта үзең аңламыйсың да, әмма тора башлагач уртак яклары барын күрәсең, аңар-

да әниең чалымнарын тоясың... Казан кызы булса да, Гөлназның бөтен җәйләре авылда үткән – эшләп үскән. Шәһәр күмәче генә булса, мин аңа үзем дә карамас идем. Гөлназның әти белән әнигә охшаячагын шундук белдем... Әни белән уртак телне алар тиз тапты. Кайтканда-киткәндә генә кайнана белән уртак тел табу кыен түгел инде ул. Бер түбә астында яшәсәң генә конфликтлар килеп туарга мөмкин.

Туйларда гел: «Сезнең гаилә берәүне дә кабатламаячак, аны кемнекенәдер охшатырга тырышмагыз. «Безнең әниләрдә», «безнең әтиләрдә» дигән сүзне, гомумән, онытыгыз», – дим. Үз гаиләң идеалы итеп әти-әниең гаиләсен күрү упкынга алып барачак... Мин алып барган мәҗлесләрдә шуңа күрә ике якны ярыштыру да юк – андый конкурслар үткәрмим. «Кияү ягы, кәләш ягы дигән сүзне онытыйк, «без – бу яңа гаиләнең туганнары» дип берләшик», – дим кунакларга да. Аңлашылмаучанлыклар туйда ике якны бер-берсенә каршы куюдан ук та башланып китәргә мөмкин бит.

8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Кешене белмим, ә үземә килгәндә Гөлназ нәрсәгә сәләтле булуымны, мал таба алганымны яхшы белә. Шуңа күрә бүгенге көндә акчаны ул күбрәк эшләсә, моңа тыныч карар идем, хәтта шат булыр идем. Акча эшләү – ул бит үзе бер хобби шикелле. Кем белә, бәлки хатынымның хоббие шундыйдыр, бәлки әле ул аны аңлап кына бетермәгәндер. Шуңа күрә мин дә, абыйсы да аны моңа этәрәбез – финанс яктан мөстәкыйль булуын телибез. Кемгә күпме гомер бирелгәнен белеп булмый бит, Алла сакласын инде... Аннан моңарчы бала табып, бала үстереп, бәлки, ул үзенең потенциалын да ачарга өлгермәгәндер. Аңа бит әле аңа шәхес буларак та үсәргә кирәк.

9 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Тыныч карыйм. Кыз яратуын беренче булып белдергән парларны беләм – андый туйлар да алып барганым булды. Егетләрнең иң курыккан әйбере – безне кире кагулары. Бу турыда күбрәк уйласаң, танышырга теләгән кыз янына бара да алмаячаксың. Ә кызның көткән булуы да мөмкин... Моны ничектер сиздерсә, дөресрәктер. Сиздерү, «Сез миңа ошыйсыз, бүген мине озатып кайтыгыз әле», – дип килеп әйтү түгел бит. Зирәк кызлар аның юлын таба.

10 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Миңа калса, юмор хисе, интеллект җәлеп итәдер. Тән төзелеше, мускулларга исләре китмидер. Югыйсә урам тутырып юан ир-атлар йөрмәс иде... Эчке дөнья барыбер мөһимрәк. Тышкы матурлык гел үзгәреп тора: кеше картая, җыерчыклар чыга... Ә күңел шул килеш кала. Киресенчә, еллар үткән саен матурланырга, баерга гына мөмкин.

11 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр.

– Килешәм, ирләр көчле хатын-кызлардан бераз шүрли. Андый ханымнар янында үзем дә дискомфорт тоям. Нишләп икән, белмим. Күрәсең, хатын-кызның ир-аттан узып нәрсәдер хәл иткәнен өнәп бетермим. Хатын-кыз көчле булса да, көчсез булып күренә алсын, үз теләгәнен ир авызыннан әйттерсен.

Хатын-кыз ир кешегә караганда акыллырак булса да, зирәгрәк эш йөртергә тиештер. Хатынга да гел әйтәм: «Минем өчен иң мөһиме – кеше янында гаилә башлыгы булып күренүем. Бу гаиләдә бөтен нәрсәне Фәнил хәл итә икән, дигән фикер туарга тиеш», – дим. Ә өйдә... Кеше янында ир-ат үзен баш итеп хис итә икән, ул өйдә барысына да риза. Савыт-саба да юа, тузан да суырта... Башкалар янында үзен түбәнсетүне, санламауны авыр кичерә ир-ат.

12 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный. Мондый очракта нишлисез?

– Кайвакыт ризалашу күпкә җайлырак: бәхәсләшү күп көчне, нервыны ала бит ул. Кайчак: «Җимешем, бу сөйләшүнең ахыры нәрсә белән бетәсен беләм, әйдә, шушы урында туктыйк – синең белән килешәм», – дим. Вакыт кемнең хаклы икәнен, кемнең юк икәнен күрсәтә, шулай булгач, нигә бәхәсләшеп торырга. Мин Үлчәү йолдызлыгында туган. Үлчәүләр конфликтлы кешеләр түгел, бик сабырлар, соңгы чиккә җиткәнче түзәләр. Минем турында начар уйламасыннар дип яшиләр. Шулай яши-яши бөтен хәл бетә...

13 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез, ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, мин арыдым, дип, диванда кырын ятып тора.

– Минемчә, бу татар гаиләләренә хас күренеш түгел. Мин генә кайтмыйм бит әле өйгә, балалар да кайта. Ир ярый инде ул кеше баласы, малай белән кыз үзенекеләр бит. Шуңа күрә ул минем турында уйлап пешерәме икән, әллә балалар турындамы, белмим. Аннан мин ашау даулап йөрүче дә түгел. Беренчедән, әйткәнемчә, үзем дә пешереп ашый алам. Икенчедән, туклануым да гел бертөрле. Без, гомумән, икебез дә дөрес туклануда. Бәлешләр саласы юк, пешкән майсыз тавык түше, кыяр-помидор, бал, эремчек булса, шул җитә. Төп ашны төшкә кадәр ашыйбыз, аннан җиңел генә туклanабыз.

14 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.

– Дөресен әйткәндә, бүләк бирергә дә, алырга да яратмыйм. Бу – минем бик зур кимчелегем. Хатын читләтеп тә, ачыктан-ачык та әйткәли моны. «Аңла инде, сюрпризлар булу хатын-кыз өчен бик мөһим бит», – ди. «Әйдә, акча бирәм, нәрсә кирәк, барып ал», – дим. Мин бик реалист кеше – кирәкле әйбер генә алам. Чәчәк тә бүләк итмәс идем әле. Кулыңа алган мизгелдә бер секундлык ләззәт китерә дә, аннары вазада корый... Акчаны җилгә очыру кебек күренә ул миңа. Ә сез – хатын-кызлар шундый, сезгә чәчәк кирәк... Ә хатын алган бүләкләр арасында ошамаганнары юк. Ул миңа нәрсә кирәген белә. Күлмәк, носки ише әйберләрне үзе генә дә ала, калганнарын бергә сайлыйбыз. Элек аптырый идем әтигә: әни нәрсә ала – шуны кия. Гомеремдә дә хатынга әйбер алдырмаячакмын дип уйлый идем. Яши-яши үзгәрәсең икән. Башта трусик, носкины гына ышанып тапшырасың. Ә әти яшенә җиткәндә инде, мөгаен, барысын дадыр. «Нигә әтигә бөтен әйберне әни ала икән?» – дип аптырап йөрү чираты улыңа җитә...



Әлеге диагнозны, гадәттә, балага тугач ук куялар. Сабыеның йөрәгендә ниндидер кимчелек барын ишетү кайсы әнине дә борчуга салыр. Шулай да күп очракта әти-әниләр иртәрәк хафаланган булып чыга.
Республика балалар клиник хастаханәсенең югары категорияле табиб-кардиологы, медицина фәннәре кандидаты Юлия КАЛИНИЧЕВА белән балаларның йөрәгендәге патология хакында сөйләшәбез.

АЧЫК АРТЕРИАЛЬ АГЫМ – ОАП

Йөрәктән чыгучы ике төп кан тамырын – аорта белән үпкә артериясен тоташтыручы тамырны ачык артериаль агым дип йөртәләр. Бала әнисенең карынында чакта бу күренеш норма булып тора. Сабыйның үпкәләре формалашканчы, кан әйләнеше шушы тамыр аша башкарыла. Туганнан соң ул ике-өч көндә ябылырга тиеш. Җитлекми туган балаларда тоткарланырга да мөмкин.

Үз вакытында ябылмаган ачык артериаль агым баланың йөрәгенә һәм үпкәләренә кирәгеннән артык күп кан килүенә китерә, үпкәләрдәге басым арта, йөрәк көчсезләнә. Мондый патология күбесенчә иртәрәк туганнарда күзәтелә. Бик еш кына аны бәләкәчкә беренче тапкыр УЗИ ясаганда ук ачыклыйлар.

Йөрәгендә мондый патология булган бала табиб күзәтүендә даими булырга тиеш. Ачык артериаль агым күп вакытта үзеннән-үзе ябыла. Үз вакытында ябылмаган очракта, җитлекми туган балаларга ялкынсынуны басучы нестероидлы препаратлар билгеләнә. Ләкин әлеге дәва методы бала тууга ук билгеләнсә генә нәтиҗәле. Аны җитлегеп туган һәм туганнан соң шактый вакыт узган балаларга билгеләүнең файдасы юк.

Ачык артериаль агым сәламәтлеккә зур куркыныч янамаса, табиб баланың бераз үскәнен көтәргә киңәш итәргә мөмкин. Авырлыгы 10 килодан артыграк балаларда бу патологияне йөрәк куышлыгына зонд кертеп дәваларга була. Процедура бот төбендәге артерия аша башкарыла. Катлаулырак очракларда хирургия операциясе кулланыла.

Мондый патологияле кешеләр күп вакытта гадәти тормыш белән яши. Дәваланганнан соң хәтта профессиональ спорт белән шөгыльләнүчеләр дә бар.

Билгеләре:
- баланың начар ашавы, авырлык җыймавы;
- елаганда, уйнаганда, ашаганда бик нык тирләве;
- тыныч кына торганда да еш-еш сулавы, йөрәк тибешенең ешаюы;
- бик тиз аруы.



Кисәтү чаралары:
- йөклелекне планлаштырыр алдыннан булачак әнинең җентекле медицина тикшерүе узуы;
- начар гадәтләрдән тыелу, стрессларны булдырмау;
- үзбелдекләнеп дару эчмәү;
- рационга витаминнарга, аеруча фолий кислотасына бай ризыклар кертү;
- авырлы вакытта инфекцияләрдән качу;
- нәселдә йөрәк патологияле кешеләр булса, авырга узганчы ук генетик белән киңәшләшү.

Сәбәпләре:
- баланың вакытыннан алда тууы;
- нәселдәнлек;
- әни кешенең авырлы вакытта инфекция кичерүе, кызамык белән авыруы. Кызамык вирусы плацента аша үтеп кереп, баланың йөрәк-кан тамырлары системасын зарарларга мөмкин.

Фото: www.pixabay.com

Нинди куркыныч тудыра
- Ачык артериаль агым аша кан кирәгеннән күбрәк узып, үпкәләрнең гипертензиясенә китерергә мөмкин. Әгәр дә ачык агым зур икән, үпкәләрнең зарарлануы ихтимал.
- Вакытында дәваламаган очракта әлеге патология йөрәкнең зураюына һәм көчсезләнүенә китерә. Нәтиҗәдә, йөрәк җитешсезлеге күзәтелә.
- Ачык артериаль агым аркасында йөрәкнең эчке тукымаларында ялкынсынулар башлану куркынычы бар. Менә шуның өчен дә мондый патологияле балаларның организмындагы инфекция чыганакларын вакытында дәвалау мөһим.

Диагностика алымнары
- Эхокардиография йөрәк камераларының никадәр зураюын белергә һәм йөрәк мускуллары кыскаруын бәяләргә мөмкинлек бирә. Әлеге тикшерү вакытында йөрәк клапаннарының ничек эшләвен дә күреп була.
- Күкрәк читлегенә рентгенография уздыру йөрәк һәм үпкәләрнең торышын ачыкларга булыша.
- Йөрәк куышлыгына зонд кертеп карау ОАПны ачыклау өчен мәҗбүри ысул булып саналмый. Гадәттә аны эхокардиография вакытында беленгән башка төрле патологияләрне өйрәнү өчен билгелиләр.



ДРКБның матбугат хезмәте җитәкчесе Зөһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.



Үт куыгында ташлар барлыкка килү – гастроэнтерология өлкәсендәге иң киң таралган чирләрнең берсе. Дөньядагы барча халыкның 10–15 процентына әлеге диагноз куела. Алар арасында хатын-кызлар күбрәк. Бу чир бик борынгы, хәтта Мисырда табылган кайбер мумияләрнең дә үт куыгында ташлар булуы ачыкланган. Татарстанның атказанган табибы, медицина фәннәре кандидаты, Республика клиник хастаханәсе хирургы Руслан ЗЕФИРОВ белән холелитиаз – үт куыгында һәм үт юлларында ташлар барлыкка килү турында сөйләшәбез.

ХОЛЕЛИТИАЗ

Холелитиаз диагнозы күбесенчә 40 яшьтән соң куела. Статистика буенча хатын-кызларда ир-атларга караганда ике тапкырга ешрак очрый.

Норма буенча кеше организмында тәүлегенә 500–1000 мл үт сыекчасы бүленеп чыга. Ул үт куыгында җыела һәм кирәк булганда аз-азлап уникеилле эчәккә ыргытыла. Дуоденаль ачыклыкта ризык булмаса, үт куыгының клапаны ябылып, сыеклыкка агып чыгарга ирек бирми.

Ташлар барлыкка килү үт сыекчасының куеруыннан башлана. Үт куыгында касмак сыман утырым оеша башлый. Үт кристаллары – комга, ком исә ташка әйләнә. Ташларның барлыкка килү сәбәпләре тулысынча билгеле түгел. Моңа күп факторлар тәэсир итә. Кеше үт куыгында ташлар булуын сизмәскә дә мөмкин. Баштарак ул бернинди комачаулык тудырмый. Үт куыгы ялкынсынса, ташлар үт юлларына эләксә генә авырту барлыкка килә. Майлы, ачы-кырку ризыклар, камыр ашлары ашаганнан соң ул тагын да ныграк көчәя. Кайчак авырту аркага, калак сөякләренә кадәр таралырга мөмкин.

Төгәл диагнозны кую өчен кан анализы, УЗИ билгеләнә. Дәвалауны бары тик табиб кына билгели. Үт куыгында ташлар булганда үзбелдекләнеп дәвалану бик тә куркыныч.

Үт куыгында үзгәрешләр башланып, ташлар күзәтелгән очракта бердәнбер дәва методы – хирургия ысулы. Хәзер аны лапароскопия алымы белән ясыйлар. Организмга тернәкләнү өчен күп вакыт таләп ителми. Үт куыгы булмау кеше тормышына зур үзгәрешләр кертми.

Үт куыгында таш булганда тыела:

- исерткеч эчемлекләр;
- кофе, каты чәй, шоколад;
- майлы сөт ризыклары;
- майлы ит һәм майлы балык;
- борчак һәм фасоль;
- гөмбә;
- консервалар;
- яңа пешкән ипи;
- тозлы сырлар;
- әче һәм борычлы тәмләткечләр.

Сәбәпләре:

- үт юлларындагы төрле проблемалар аркасында үт сыекчасының тиешенчә бүленеп чыга алмавы;
- организмда матдәләр алмашы бозылу;
- гормональ препаратлар куллану;
- диетаны дөрес тотмау;
- дөрес тукланмау;
- аз хәрәкәтләнү;
- йөклелек (үт сыекчасының куеруына китерергә мөмкин).

Билгеләре:

- уң яктан кабырга астында авырту;
- күңел болгану, укшыту;
- тән тиресе, күз алмалары саргаю;
- авызда әче тәм барлыкка килү;
- бәвелнең көрән төскә керүе;
- тәрәтнең агаруы.

Табиб киңәше

Үт куыгында ташлар булганда диетаны катгый үтәү мөһим. Кыздырган, тозлы, ысланган, маринадланган ризыклар, майлыбаллы камыр ризыклары, өреле шулпалар тыела. Үт бүленеп чыгуны көйләү өчен, аз-азлап, көненә биш тапкыр ашау файдалы.



БЕЛҮ МӨҺИМ

Үт куыгында ташлар булганда үт кудыргыч препаратлар кабул итәргә ярамый. Ташлар урыннарыннан кузгалып, үт юлын тулысынча томаларга мөмкин. Нәтиҗәдә, үт куыгы шартлап, кеше гомере өчен куркыныч тудыручы халәт барлыкка килә. Үт куыгының дөрес эшләмәве аркасында ашказаны асты бизе ялкынсынуы – панкреатит башлануы ихтимал.



Республика клиник хастаханәсенең җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча әйдәп баручы белгече Валерия Белова ярдәмендә әзерләнде.

ҖӘЙ БУЕ ЧӘЧӘКТӘГЕ КЛУМБА



Тиздән җәй! Тирә-юнебез шау чәчәккә күмелер. Укучыларыбыз арасында да чәчәкләр үстерергә яратучыларыбыз күп. Бәлки, кемдер бу эшкә әле беренче генә елын керешәдер. Менә шуларның барысын да исәпкә алып, бу сәхифәбездә яздан алып көзгәчә туктаусыз чәчәк атучы клумба үстерү серләрен ачарга булдык. Тәҗрибәле ландшафт дизайнеры, журнал укучыларыбызга инде таныш Наилә ГАЛИЕВА моның өчен нинди үсемлекләр сайларга һәм аларны ничек итеп төркемләргә икәнен аңлатыр.
Без тәкъдим иткән клумба – Наилә ханымның авторлык эше. Биредә декоратив куаклар белән берьеллык һәм күпьеллык чәчәкләр бергә үсә. Кайсы үсемлекнең кайсысы белән ярашуы схемада ачык күренә. Әгәр дә берәр сортны таба алмасагыз, аны шуңа якын булган икенчесенә алыштырырга була.
Клумбаны утырткан вакытта берничә елдан соң куакларның җәелеп үсеп китәчәген дә исәпкә алып, үсемлекләр арасында берникадәр ара калдырырга онытмагыз.

Декоратив куаклар

Артыш агачын бакчачылар яратып өлгерде инде. Күптөрле сорты бар. Безнең очракта «*Блю Эрроу*» сорты алынды. Аның ылыслары зәңгәрсу яшел төстә һәм ук сыман өскә таба очланып менә. Әлеге сортны «*Скайрокет*»ка алыштырырга мөмкин.

Артышның җәелеп үсә торган төреннән чәчәк клумбаларына «*Андорра компактный*» сортын утырту отышлырак. Бу сортның ябалдашы артык җәелми, биеклеге 10 см, ә куе ябалдашның диаметры 1 метр чамасы гына. Җылыга һәм яктыга бик мохтаҗ булса да, бездә яхшы кышлый.

Себеркәчле (метельчатая) гортензия. Аның сортлары бик күп, без исә «*Сандей фрайз*» сортын алдык. Ул миниатюр булып үсә, биеклеге һәм киңлеге 1 метрдан артмый. Формасы белән җыйнак кына шарны хәтерләтә, махсус рәвештә формалаштырырга кирәкми. Июльдән алып октябрь аена кадәр чәчәк ата. Гортензия әче туфракларда яхшы үсә, шуның өчен аны утыртасы чокырга торф салып калдыралар.

Япон спиреясының «*Литтл Принцесс*» яисә «*Мейджик Карпет*» сортларына тукталдык. Икесенең дә ботаклары куе. Түгәрәк шар рәвешен саклар өчен, сезонга берничә тапкыр кисеп торырга кирәк. Спиреяның төп үзенчәлеге – яздан көзгәчә төрле төскә керүче яфракларында. Бер клумбада аның бер генә төрен кулланганда, затлырак күренә.

Тау наратының да сортлары күп. Без киңәш иткән «*Мопс*» яисә «*Мини-мопс*» сортларының ябалдашы – куе шар формасында. Тау нараты бик әкрен үсә, үзенең формасын озак саклый. Тамыр системасы нык, шуның өчен туфракка талымлы түгел, хәтта комлы урында да яхшы үсә. Тау нараты урынына «*Еллоу Риббон*», «*Столвик*», «*Майки*» сортлы көнбатыш туялары утыртырга була.

Күпьеллыклар

Берьеллыклардан аермалы буларак, чәчәкләрен тизрәк атып бетерсәләр дә, мәшәкатьләре азрак булу һәм бер урында күп еллар үсә алуы белән уңайлы.

Дербенник (иволистный) – дымсу җирләрне үз итә. Чәчәкләре алсу, шәмәхә алсу төстә. Июньнән сентябрьгә кадәр сулмый. Биеклеге – 80–140 см.

Лилейник (кызгылт сары яки кура җиләге төсендә) – чәчәкләрен




Схема:
Наилә Галиева

җәй ата. Талымсыз, тиз үсә, авыруларга бирешми.

Себер ирисы гадәти ирислардан ваграк булса да, чәчәкләренең төсләре бик җете, зәңгәр йолдызлар шикелле чекерәешеп утыралар. Сары фонда аеруча матур күренәләр, әйтик, сары спирея белән. Июнь аенда чәчәк ата.

Вероника. Бакчачылар аны зәңгәр, шәмәхә төстәге чәчәкләре өчен яратып үстерә. Авыруларга һәм һава торышы шартларына чыдам. Июльдә чәчәккә күмелә.

Новобельгия астрасы – көзге якта чәчәк ата. Үсемлекнең формасы шарны хәтерләтә.

Схемада күрсәтелмәсә дә, иртә язда клумбаны ямьләр өчен, куак араларына, агач төпләренә примула, нәркис яки крокуслар утыртырга була. Башка гөлләр үсеп чыкканчы алар чәчәкне атып бетергән була инде.

Берьеллык чәчәкләр яздан алып көзгә кадәр чәчәк ата. Ләкин үстерүе мәшәкатьле, ел да орлыктан чәчеп, җылы урында үстерергә кирәк. Әгәр теләсәгез, клумбаның алгы ягына петунияләр утыртыгыз. Лилейниклар фонында петунияләр матур күренәчәк. Алар урынына яфраклары без сыман булган флокслар да утыртырга ярый. Русчасы – «*Флокс шиловидный*». Ул – күпьеллык үсемлек, биек булып үсми, чәчәкләре бик матур һәм озак саклана. Бер сезонга ике тапкыр да чәчәк атарга мөмкин.

Клумбаларга төгәлләнгәнлек һәм тагын да декоративлык өстәү өчен вакланган кайры яки вак таш кулланырга була. Вак таш туфракка салкынлык бирә. Аны ылыслы үсемлек араларына гына түшиләр. Ә яфраклы агачлар һәм куаклар утыртканда, розалар, пионнар үстергәндә вакланган кайры куллану отышлырак. Клумбада аның бер генә түгел, берничә төслесен дә куллана аласыз. Мәсәлән, сары спирея кызыл кайры җирлегендә бик матур күренә. Декоративлык өстенә, ул әле чүп үләннәрен дә үстерми, дымны да саклый.



Заманча «хрущёвка»

1950–1980 елларда төзелгән функционализм стилендәге бер типтагы бу йортлар Россиядәге барлык торак фондының 10 процентын тәшкил итә. Алар Франциядәге күп катлы йортлар проекты буенча салынган. Тиз һәм очсыз торак төзү программасын Никита Хрущев башлап җибәргән. Шуңа аларны халык телендә «хрущёвка» дип атыйлар. Бәдрәф белән ванна берләштерелгән, кухнясы 6 квадрат метрдан артмаган кечкенә мәйданлы фатирга заманча ремонт ясап, яңа сулыш өреп яшәүчеләр дә юк түгел. Шундый бер фатирның хуҗасы Искәндәр ХӘКИМОВтан – кызыклы идеяләр. Программист булып эшләүче Искәндәр ремонтны үзе ясаган. «Бу фатирга ремонт ясамыйм, яңасына акча җыям, диючеләр бар. Ә без менә күңелебезгә ошаган фатирда гомер итәбез. Ник иртәгәге көн белән яшәргә, бүген яшисе бар әле», – ди ул.





Фото:
Анна АРАХАМИЯ
Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА
әзерләде

Коридор

Ишектән килеп керүгә үк гадәти фатир гына түгеллеге сизелә. Гадәттә, кечкенә коридорлы «хрущёвка»да берничә кеше бергә киенә-чишенә дә алмый. Шунда ук шкаф та, кием элгечләр дә. Ә бу фатирдагы коридорда – бушлык.

- Шкафлар стенага кертелеп эшләнгән. Хәтта махсус аяк киемнәренеке дә бар. Моның өчен гипсокартон кулланылган. Почмакта да шкаф. Ул стенадан чыгып тормагач, мәйдан да алмый кебек, ә күпме әйбер сакларлык урын. Өстә тезелеп киткән антресольләр дә тулы бер ансамбль тәшкил итә.
- Стенада эленеп торган көзге дә серле булып чыкты. Кысага утыртылган көзге петля белән стенага ябыштырылган. Ул ишек кебек ачыла. Артына күннән махсус кесәләр тегеп беркеткәннәр. Анда аяк киемнәре өчен төрле кремнар, щеткалар саклана.
- Сумка, зонтларны элеп куяр өчен стенага элмәкләр ябыштырылган.
- Кухняга керә торган коридор томаланган. Анда зал аша керәсе. Шуңа күрә коридор озын һәм сыйдырышлыга әйләнгән.







Кухня

■ Почмакта ясалган шкаф күп урын алмый. Әмма күпме әйбер куярга урын бар! Шкаф астына телевизор беркетелгән.

■ Тәрәзә төбе өстәл булып дәвам итә. Бу – эш зонасы арту дигән сүз.

■ Бер ягы озынча түгәрәк (урын тар җирдә, почмакларга бәрелмәс өчен!), икенче ягы стенага беркетелгән өстәл махсус кыек итеп ясалган. Өстәл белән кухня шкафлары арасын киңәйтү өчен бу. Болай итеп эшләү газ миче йә табак-савыт юу машинасының ишеген ачарга мөмкинлек бирә.

■ Һәр «хрущёвка» кухнясының тәрәзә астында «салкын шкаф» бар. «Безнеке, башка фатирларныкы белән чагыштырганда, ике тапкыр зуррак. Стенаны җылыту өчен тыгып калдырган бөтен чүп-чарны алдым да, заманча материаллар белән җылыттым, ЛДСП белән эчләдем», – ди алтын куллы хуҗа.

■ Кухняның күп өлешен биләп торган суыткычны күрмәдегезме? Ул кухняга керә торган коридорга куелган, шунлыктан стена белән бер яссылыкта тора.



Зал

■ Шулай ук стенага кертеп ясалган шкаф. Моның өчен кухняга керә торган томаланган коридор файдаланган.

■ Стеналар акка буялган. Ак төс мәйданны зурайтып күрсәтә.

■ «Хатирәләр дивары». Стенага махсус җепләр тарттырып, анда кер каптыргычлары ярдәмендә төрле фотолар эленгән. «Сәяхәт итәргә яратабыз. Бу фотоларга карап үзебез барган илләрне искә алабыз», – ди фатир хуҗасы. Шунда ук балаларның төрле яштә төшкән фотоларын да элергә була. Хатирәләр түшәмдә дә. Анда да җепкә фотолар тезелгән.

■ Ак залга шарм өстәп, уртада фуксия төсендәге зур диван тора. Янында кечкенә өстәл. Бу – хуҗаларның ял зонасы.

■ Зал белән кухня арасында – шудырмалы ишек. Ябык вакытта суыткыч белән стена арасында ул. Берничек тә комачауламый.

■ Гомумән, фатирда ишекләр шудырмалы йә җыелмалы. Мәйданны «саклап калу» өчен тагын бер лайфхак бу.

Балалар бүлмәсе

■ Зал аша керә торган бүлмә икегә бүленгән: балалар бүлмәсе һәм хуҗаның кабинеты.

■ Кечкенә фатирда һәр метр кадерле. Спорт белән шөгыльләнергә яраткан малайларының скейтбордларын, чаңгыларын саклау урыны – түшәм! Әйе, әйе, түшәмгә баулар тарттырылып, шунда спорт җиһазлары урнаштырылган.

■ Бүлмәдә дә тәрәзә төбе өстәл булып дәвам итә. Бу – кабат эш зонасы арта дигән сүз.





Юыну бүлмәсе

■ Юыну бүлмәсен көзгеләр ярдәмендә зурайтырга мөмкин. Ванна янында эленгән зур көзге дә мәйдан өсти.

■ Ваннаның астын капламау – юыну бүлмәсен зуррак күрсәтә.

■ Кер юу машинасы да стенага кертелеп ясалгач (монда да кабат кухняга бара торган томаланган коридор ярдәмгә килгән), бүлмәдә урын арткан. Дөрес, каршы якка канализация һәм сууткәргеч сузарга туры килгән.



Осетин бәлеше



Камыр өчен кирәк

(бер бәлеш ясау өчен)

- 200 г югары сортлы бодай оны;
- 1 йомырка;
- 100 г сөт;
- 100 г су;
- 30 г үсемлек мае;
- 5 г коры чүпрә;
- 1 г тоз;
- 2 г шикәр комы.

Эчлек өчен

- 100 г тавык түше;
- 80 г шампиньон гөмбәсе;
- 270 г сыр (моцарелла яисә «Российский»)
- 30 г атланмай;
- 20 г помидор (без черри помидоры кулландык, башкасы да мөмкин);
- 20 г шпинат.

«Аш-су» рубрикасының бүгенге кунагы – Руслан ӘШРАФҖАНОВ. Әнисе Мөслимә ханым кебек, кечкенәдән аш-су остасы булырга хыялланган ул. Балачактан күңелендә калган мизгелләрнең берсе – әнисенең эшенә барып, аның эшләгәнен күзәтү. Тугызынчыда укыганда ук инде беренче тапкыр утын мичендә коймак пешереп карый. Камырын да үзе изә, мичен дә үзе яга. Каз маен эретеп, каз канаты белән майлый аларны... Кукмара аграр колледжында повар-кондитер һөнәрен үзләштерүе – әлеге өлкәгә аяк басуының тәүге адымнары. Тәҗрибә узар өчен Казанга килгән егетне башкала инде үзеннән җибәрми. Юныс Әхмәтҗанов нигез салган «Татар ашлары йорты»нда эшләгән елларын осталык чарлау чоры иде, дип искә ала Руслан. Кайнар цехта эшләүнең бар нечкәлекләренә төшенә биредә. Хәзер исә татарныкы гына түгел, Европа, Италия, Испания кухнялары белән дә эшли. «Татар кухнясы күтәрелеш чорын кичерә, – ди ул. – Шәһәребезгә килгән кунакларга безнең өчпочмак, кияү пилмәне, зур бәлештән авыз итү бик ошый». Бүгенге көндә Руслан тантаналар, бәйрәмнәр оештыру белән мәшгуль. Яңа гына кафе яки ресторан ачкан дусларына менюлар һәм яңа төрле рецептлар уйлап чыгарырга булыша. Бүген укучыларыбызга тәкъдим иткән осетин бәлешенең рецептын да ул үзе камилләштергән. Аның сере ингредиентларда гына түгел, камырны басу рәвешендә дә.

Мастер-классны үткәрүдә күрсәткән ярдәмнәре өчен «Из печи. Пицца&Пироги» пекарнясына рәхмәтебезне белдерәбез.

Эш барышы

■ Камырга ингредиентлар билгеле бер тәртиптә генә салынырга тиеш. Он өстенә йомырка сытып, сөт салабыз һәм йомшак кына итеп туглыйбыз. Аннары су өстәп, шикәр комы һәм тоз сибәбез.

■ Камыр әле сыеграк булганда чүпрә салабыз, сыек май агызабыз һәм калган он белән үзләнгәнче басабыз. Хәрәкәтләр җиңелчә генә булырга тиеш. Болай басканда камыр кислородка туена, йомшак һәм бик күперенке була.

■ Басып бетергәннән соң, кулларны онлап, камырны йомрылап җыябыз. Өстен полиэтилен элпә белән каплап, 2 сәгатькә җылы урынга кабарырга куябыз.

■ Тавык түшен ярылардан һәм майлардан арындырып, саламлап турыйбыз һәм 15 г үсемлек мае салынган эссе табада 2 минут кыздырабыз.

■ Гөмбәне телемләп турап, ит янына кушабыз. Барысын бергә тагын 5 минут кыздырабыз. Әледән-әле болгаткалап алабыз. Тоз, борыч, базилик сибәбез (сез үзегез яраткан тәмләткечләр куллана аласыз).



■ Черри помидорларын шакмаклап турап, аларны да гөмбә янына салабыз. Һәм тагын 3 минуттан табаны сүндереп, эчлекнең суынганын көтәбез.

■ Ул суынган арада сырны эре угычтан уып, шпинатны саламлап турыйбыз.

■ Сырны, шпинатны һәм бүлмәдә торып йомшарган атланмайны суынган эчлеккә салып, барысын бергә яхшылап катнаштырабыз, кул белән әвәләп зур йомарламга җыябыз.

■ Камырны куна тактасына төшереп, кул белән генә җиңелчә баскалап җәябез. Җәемнең диаметры 25–30 см, ә калынлыгы 1 см булырга тиеш.

■ Йомарланган эчлекне җәем уртасына куеп, камырның кырыйларын өскә таба күтәреп, бөрәбез. Аннары бәлешнең астын өскә әйләндереп салып, кул белән баскалап тагын бер кат җәябез, уртасын тишәбез.

■ Бәлешне атланмай белән майланган табага күчереп, 180–200 градус кайнарлыктагы мичтә 5–7 минут тирәсе пешерәбез.

■ Утын мичендә пешерсәгез, ул аеруча тәмле һәм йомшак була.

■ Мичтән алган бәлешне эретелгән атланмай белән майлап, кайнар килеш табынга бирәбез.



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.

ЛИМФОДРЕНАЖЛЫ МАССАЖ



Матурлык лимфа системасының эшчәнлегенә дә бәйле. Ул организмнан җыелган токсиннарны чыгару өчен җаваплы. Лимфа системасының эшчәнлеге бозылу аз хәрәкәтләнүдән, дөрес тукланмаудан, аз су эчүдән һәм авырулардан килеп чыгарга мөмкин. Иртән көзгедән битнең шешенгәнен, күз төпләрендә «капчык»лар күрәсез икән, димәк, лимфодренажлы массаж – сезнең өчен. Әлеге техника лимфа агымнарын, активлаштырып, тукымалардан артык суны куа, төрле авырулар килеп чыгудан, вакытыннан алда картаюдан саклый. Массажист Гөлназ ХӘБИБУЛЛИНА белән әлеге массажны ясау серләренә өйрәнәбез. Аны һәр көнне иртән эшләргә кирәк.



1 нче ЭТАП
Биткә массаж ясый башлаганчы, лимфа әйләнешен эшләтеп җибәрәбез.







- кечкенә тупны табан астына куеп, алга-артка, уңга-сулга тәгәрәтәбез;
- бармак очларын идәннән аермыйча, 40–100 тапкыр сикергәләп торабыз.

Күкрәк мускулларын эшләтәбез. Бит аска төшмәсен өчен бу бик мөһим.

- күкрәк сөяге уртасыннан җилкәгә таба тирене чеметкәли-чеметкәли барабыз. Моны уң якка да, сул якка да, муенга таба да 10–15 шәр тапкыр эшлибез;
- кулларны күкрәк сөяге уртасына куеп, башны артка җибәрәбез. Аннары уң кулны бер якка куеп, башны сул якка тартабыз һәм киресенчә башкарабыз;
- муенны чеметкәлибез, уч табанының кырые белән ышкыйбыз.



2 нче ЭТАП
Кулга бит кремы йә май тидерәбез. Күнегүләрне унар тапкыр, битнең ике ягына да ясыйбыз.













✓ сул кул белән иякне тотып, уң кулны астан-өскә бит буйлап йөртәбез;
✓ сул кул белән иякне тотып, уң кулның баш бармагы белән ияк астыннан колакка таба сыпырабыз. Баш бармакны яңак сөягенең астына куеп, чигәгә таба массажлап менәбез;
✓ авызны ачып, чәйнәү мускулларын массажлыйбыз;
✓ борын канатларын һәм мускулларын өскә таба түгәрәк хәрәкәтләр белән массажлыйбыз;
✓ каш арасын һәм каш өстен массажлап, каш арасын баш һәм имән бармаклары белән кысып тотып торабыз;
✓ бармак очлары белән тирене дерелдәтеп, маңгай мускулларын йомшартабыз;
✓ соңгы күнегүдә битне сыпырып, лимфаны «төшерәбез»: ияктән – колакка кадәр, маңгайдан – колакка. Колак артындагы лимфа төеннәрен әкрен генә массажлап, муенны сыпырабыз.



Күнегүләрне, QR-код аша кереп, видеодан да карый аласыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.

Үгезбозау хатын-кыз

Үгезбозауларның стихиясе – җир. Энергияле, практик, максатчан – әлеге йолдызлык астында туган хатын-кызларга хас иң төп сыйфатлар бу. Алар үз көчләрен беләү, үзләренә ышана, читтән ярдәм көтми, барысын да мөстәкыйль хәл итәргә тырыша. Үгезбозау хатын-кыз – эшсөяр, һәр эшне тәм табып, ихластан башкара. Тынычлык – менә аңа хас тагын бер сыйфат. Аны чыгырдан чыгару бик кыен, нинди хәлдә дә үзен кулда тотып кала белә ул.

Мәхәббәт

Аларның энергиясен ир-атлар әллә каян тоеп ала, шуңа да бу йолдызлык астында туучы хатын-кызларга каршы җенеснең игътибары артыгы белән җитәрлек. Ләкин эчке сиземләү һәм рациональ уйлый белү сәләтенә ия Үгезбозаулар үзләренә кем кирәген бик тиз ачыклый. Аларда көнчелек тә юк түгел. Үзенә тиң күргән кешесе өчен ахыргача көрәшәчәк.

Мөнәсәбәтләр

Танышлары арасында Үгезбозау йолдызлыгында туучылар булганнар белә – алар чын дус, беркайчан да авыр вакытта ташламас. Дусларына ярдәм кирәк булса, вакыты белән дә, акчасы белән исәпләшеп тормас. Аның үзен дә күпләр якын дус саный.

Гаилә

Үгезбозау йолдызлыгында туган хатын-кызлар менә дигән хуҗабикә һәм кайгыртучан әни. Гомер юлдашы итеп тә ул үзе шикелле юмарт һәм киң күңелле кешене сайлый. Тормышы туп-тулы касә кебек. Йортына кем килсә дә, ачык йөз һәм тәмле аш белән каршы алачак – аларның табигате шундый.

Йолдызнамә июнь

Кучкар. Тормышны үзгәртәсе килер. Планеталарның тезелүе сезнең файдага – күңелсезләнергә, боегырга туры килмәс. Кызыклы сәяхәтләр, очрашулар көтә сезне. Кемнеңдер эшен алыштырасы килер. Яңа адымнар ясар өчен кулай чор.

Үгезбозау. Өстәмә керем мөмкинлеге барлыкка килер. Бу исә күптәнге хыялыгызны чынга ашырырга юл ачар. Планеталарның энергиясе табышка йөз тота – файдаланып калыгыз.

Игезәкләр. Үзгәрешләр көтелә. Барысы да ниндидер яңа идеядән башланачак. Тынычлап ял итәргә җаегыз булмас, мөгаен. Яңа эш, яңа танышлар бөтен дөньягызны биләр. Үзегезгә нәрсәнең мөһимрәк булуын ачыкларга тырышыгыз.

Кысла. Ыгы-зыгылардан ялыккан чагыгыз. Җаныгызны тыңласагыз, барысы да икенче планга күчкән кебек тоелыр. Планнарны дөрес корыр өчен үзеңне аңлау кирәк. Бу сезне максатыгызга якынайтачак.

Арыслан. Кояш активлыгының йогынтысы зур. Бу күтәренкелек социаль өлкәдә генә түгел, хезмәт даирәсендә дә сизелә. Тормышыгызга яңалыклар ыргылып керер. Ниятләрне чын итәр өчен кулай чор.

Сөмбелә. Комфорттан беразга чыгып торырга туры килер. Көчләрегезне бер йодрыкка туплап, үз урыныгызны тәгаенләргә кирәк булыр. Тырышлыгыгыз бушка китмәс, тиешле әҗерен алырсыз.

Бизмән. Кичектергесез эшләр чыгар, баштанаяк эшкә чумарсыз. Дәүләт оешмаларында булырга, документлар белән мәшәкатьләнергә туры килүе ихтимал. Көчегезгә ышаныгыз, бу тырышлыкның ахыры уңышлы тәмамланыр.

Чаян. Көчегезне элеккеге элемтәләрне ныгытуга багышлагыз. Сак булыгыз, хисләрегезне чыгармаска тырышыгыз. Хезмәт даирәсендә сәләтегезне күрсәтү мөмкинлеге бик зур.

Укчы. Зур үзгәрешләр якынлаша. Кызыксынучанлыгыгыз, аралашучанлыгыгыз нәкъ менә хәзер кирәк. Иң отышлысы: вакытыгызны һәм көчегезне яңа проектка сарыф итү. Курыкмагыз, уңыш сезнең якта булыр.

Кәҗәмөгез. Ияләнгән гадәтләрдән баш тартып, яңача яши башларга туры килер. Һава энергиясе көчле вакыт, ә сезнең энергия – җирнеке. Үзегезне җайсыз хис итәрсез, ләкин бу тиз үтәр. Сез тырыш, ә тырышларны язмыш бүләкли.


Сукояр. Яшәү энергиягез тулыланачак, көчегезнең артканын тоячаксыз. Яңа эш башлау яисә яңа һөнәр үзләштерү өчен кулай чор. Хәзер артык көч түкмичә дә зуррак уңышларга ирешә аласыз, моннан файдаланып калыгыз.

Балыклар. Шәхси тормышыгызга игътибарны арттырыгыз. Көчегезне гаиләгә сарыф итү отышлырак. Көтелмәгән очрашу ихтималы зур. Моңа кадәр кагылырга куркып торган ниндидер проблема калкып чыгарга мөмкин.

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Лилия ГӘРӘЕВА, Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА әзерләде.







ҺӘР ХИСНЕҢ – ҮЗ ТӨСЕ

Уфада яшәп иҗат итүче Башкортстанның атказанган рәссамы Вәгыйзь Шәйхетдинов кайчан да булса Бөек Җиңү бәйрәменә багышлап ифрат дәрәҗәдә матур һәм якты картина язмыйча калмас иде! Чөнки әти-әнисе өчен Җиңү бәйрәменең никадәр шатлыклы көн булуын ул балачактан бирле күреп үскән. «Әтиебез Бөек Ватан сугышын армия хезмәтендә Эстониядә каршылый. Пулемётчы була, Сталинград өчен барган канкойгыч бәрелешләрдә каты яраланып, тугыз ай буе хәрби госпитальдә дәвалана... Әтиебез Гайнелгыйлем Нургали улы һәм әниебез Суфия Муллакамал кызы – җиде бала үстергән мөхтәрәм затлар! Гомер-гомергә тормышны, кешеләрне, туган ягыбыз табигатен яраттылар, ул сыйфатлар безгә дә күчте. Мин башта Башкортстан дәүләт педагогика институтының физика-математика факультетына укырга кердем. Институтта сынлы сәнгать-графика факультеты ачылгач, шунда күчтем», – ди ул үзе турында.

Танылган татар рәссамы 1955 елның 8 мартында Башкорстанның Бүздәк районы Кәпәй-Кобау авылында туа. Институт тәмамлауга, Октябрьскида берничә ел дизайнер булып эшли, 1989–1995 елларда РСФСР Сынлы сәнгать фондының Башкортстан бүлегендә рәссам-монументалист буларак иҗат итә. Күргәзмәләрдә катнашу кимендә биш дистәдән артык. Алар арасында ике дистәсе – шәхси күргәзмәләр. Шуларның берсе – Төньяк Кипрның Төрек Республикасы башкаласы Никосиядә уза. Эшләре хәтта ЮНЕСКОның Париждагы штабында, башка чит ил коллекционерларының шәхси тупланмаларында саклана.

Татар халкының телен, мәдәниятен үстерүдә, гореф-гадәтләрен саклап калуда башкарган зур эшләре өчен аңа 2008 елда Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының Рәхмәт хаты тапшырыла.

Рәссам иҗатындагы төп юнәлешләр – портретлар, натюрмортлар, пейзажлар, тематик картиналар. Ул кышкы пейзажларны аеруча яратып яза. «Армиягә баргач, Бакуга эләккән идем. Анда хезмәт итеп кайту мөмкинлегем булса да, салкын якларга җибәрүләрен сорадым. Мурманск өлкәсенең Гремиха бистәсендә радиолокация станциясе начальнигы булып хезмәт иттем, – ди әңгәмәдәшем. – Бүген дә иҗатымда ачык төсләр палитрасына өстенлек бирәм, кышкы сурәтләргә ешрак игътибар итәм». Аның пейзажлары кемне генә сокландырмас! Билгеле, алар арасында көз һәм җәй күренешләре дә җитәрлек. Аларда үзенә бер яктылык, табигатьнең сизелер-сизелмәс үзгәрешләре, төсләрдәге төгәллек... Рәссам үзе дә шундый фикергә килгән: «Һәр хиснең үз төсе бар. Аларны тасвирлау өчен сәләт һәм сынлы сәнгатьтәге академик реализм кануннарын яхшы белү таләп ителә. Яңа мотивлар өчен төрле пленэрларда катнашу да зарур».

Вәгыйзь Шәйхетдинов иҗат иткән портретлар да кызыклы. Төньяк Кипрның Төрек Республикасында урнашкан Якын Көнчыгыш университеты ректоры, миллиардер Суәт бәй Гүнсәл портреты, дөньякүләм мәшһүр балет остасы Рудольф Нуриев портреты, газиз әти-әнисе сурәтләре... Һәммәсе зур осталык белән язылган! «Әнием портреты» исә аеруча ихлас, тормышчан килеп чыккан.

Талантлы татар рәссамы Вәгыйзь Гайнелгыйлем улының «Җиңү бәйрәме» картинасына күз салыйк. Бу картинада дәһшәтле сугышның, ниһаять, тәмамлануы тулысынча якты бәйрәм рухында тасвирланган.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА







вәгыйзь шәйхетдинов

2021 

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ



Ирина ОКУНЕВА, Кама Тамагы районы Мордва Каратае авылы клубы мөдире, «Мордовские узоры» фольклор ансамбле җитәкчесе

Без, мордва-каратайлар, гомер-гомергә татарлар белән бергә яшәгән халык. Авылыбызда башлангыч мәктәпне тәмамлагач, урта белемне күршедәге рус мәктәбендә алдык. Ләкин бер районда көн күргәч, татар теле, әдәбияты, мәдәнияте дә ят түгел безгә. Эшем буенча да, ансамблебез белән дә Татарстанның күп почмакларында булырга туры килә. Татарлар белән гел аралашып торабыз. Телне белү әллә нинди капкаларны да ачарга ярдәм итә. Кайсыдыр бер телне өйрәнгәч, аның кирәксезлеген тойган кешене белмим. Татарстанда яшәгәч, без татарча да, русча да яхшы белергә тиеш. Бер үк вакытта үз телебезне дә онытырга хакыбыз юк. Аны онытсак, безне күкрәк сөте имезеп үстергән әниләребезнең рухы рәнҗеп ятар. Илебездә яшәгән төрле-төрле халыклар, аларның телләре – болындагы чәчәкләр кебек. Әгәр анда бары бер генә төрдәге үсемлек үссә, кызык булыр идемени?



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.

